

# Әхмәт Исхак



# Күңелле сәхифәләр





КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-6
И 84

Төзүчесе *Рафис Корбан*

**Исхак Әхмәт**

И 84 Күңелле сәхифәләр: Юмористик хикәяләр, шигырьләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 159 б.

Әхмәт Исхакның тууына 100 ел тулу уңаеннан чыгарыла торган бу китапка аның иң яхшы юмористик әсәрләре туплап бирелә.

ISBN 5-298-0-04093-4

©Татарстан китап нәшрияты, 2005

# КЫЧЫТМАГАН БАШКА — ТИМЕР ТАРАК

(*Скетч*)

Яңа йорттагы квартираның бик шәп жиһазландырылган бер бүлмәсе. Г а л и м ә ә б и өстәлгә бер кешелек иртәнге аш хәзерләп йөри. Үзе авыз эченнән нәрсәдер укына. Йокы бүлмәсеннән затлы халат кигән Р о з а  х а н ы м килеп чыга һәм бик тәмле итеп исни.

Р о з а. Әни, Альфред шалтыратмадымы?

Г а л и м ә. Фәритне әйтәсеңме? Юк, кызым, шалтыратмады.

Р о з а. Ни генә булгандыр инде!

Г а л и м ә. Йа Раббым, хәлфәләре алдында тел ачкычы гына бирә күр инде үзенә! Бирәсе җавапларын колагына фәрештәләр әйтеп торсыннар иде.

Р о з а. Юкны сөйләмә әле, әни. Ул бит имтиханга китмәде. Анысыннан, Аллага шөкер, котылды. Ул инде назначение алырга китте. Комиссиягә.

Г а л и м ә. Хәлфәләр алдында булмаса, комиссия алдында тел ачкычы бирсен. Фәрештәләр шул комиссия дигәненең күңеленә «Шушы баланы ата-анасы янында, Казанда гына калдырыйк» дигән фикерне салсыннар иде.

Р о з а. Шулай диген, ичмасам. «Хәлфәләр алдында», имеш. Кая, ашарга әзерме? Булмаса, капкалап алыйм да ательега барып кайтыйм. Бәлки, эч пошуларым басылып китәр...

Г а л и м ә. Әзер, кызым, әзер. Хәзер күфиеңне генә кертәм. (*Чыгып китә.*)

Р о з а (*аш савытларын рәтли-рәтли*). Ай бала, бала! Шул бала турында уйланып, башларым чатнап бетте инде. Төне буе йоклый алмый чыктым. Искәндәрнең эшкә киткәнен дә сизми калганмын.

Әллә кая Бөгелмәгә йә башка берәр җәһәннәм астына җибәреп куймасалар гына ярар иде. Чит-ят җирләрдә берьялгызы нишләр ул, балакай! (*Галимә кофе кертә.*) Атасы да бигрәк бозау шул!..

Г а л и м ә. И, кызым Разия! Һаман шул кияүгә тел тиермә инде. Теләсә кем булдыра алмый торган эшләрне башкара торган шундый зур кешене бозау дип әйтергә ничек телең бара!..

Р о з а. Бозау булмыйчы, нәрсә булсын ул тагы! Берд әнбер баласының язмышы турында уйлап та караганы юк бит аның.

Г а л и м ә. Кияүнең үз эшләре дә үзенә бик җиткән, кызым. Иртә китә, кич кайта дигәндәй, җүнләп өйдә дә торганы юк бит аның.

Р о з а. И, ачуымны китермәсәнә! Миңа аның өйдә булуының пычагыма да кирәге юк. Тегесенә бер сүз әйтсә, монысына бер шалтыратса, — аңардан шул җиткән. Ә ул бу турыда уйлап та карамый. Янәсе, малай бик способный. Имеш, үзе дә ерып чыгар. Чыгар, пычагым! Моңарчы бөтенесен үзем эшләп килдем бит. Кирәк вакытта отметкаларын рәтләттем, классыннан күчерттем. Вузына керер вакыт җиткәч, үзем йөреп вузына керттем. Артыннан әнисе йөргәч, способный булмый нишләсен! И, әни, әгәр минем артымнан да сез шулай тырышып йөргән булсагыз, бу башым белән техникум гына түгел, әллә ничә вуз бетергән булыр идем инде. Валлаһи, дип әйтәм, бетергән булыр идем! Бүгенге көнне кеше арасында наданлыгым өчен кимсенеп йөрмәс идем... (*Елый.*)

Г а л и м ә. И, кызым, бер дә уйлап сөйләмисең инде. Сезнең кебек кыланырга безнең хәлебез бар идемени соң? Аннары синең белән техникум бетергән кызлар әллә кайчан министр булып беттеләр инде. Барысы да үзеңнең ялкаулыгыңнан булды. Атаң мәрхүм Донбасста эшләгән чакта... (*Телефон шалтырый.*)

Р о з а. Ай, телефон! (*Телефонга бара.*) Алло! Альфредмы? Йә, нихәл, улым? Яхшы? Назначение алдың? Үз специальностең буенча? Кая, кая дисең? «Арктикнефть»кә? Кайчан? Анысын министерствода әйтәчәкләр? Хәзер шунда барасың? Тагын бер иптәшне шунда билгеләделәр? Кем соң ул? Саша? Берәр сәгатьтән? Алло! Алло! Альфред! Фәрит!.. Өзделәр, каһәр төпкерләре! (*Трубканы куя да хәлдән тайган кыяфәт белән басып тора.*)

Г а л и м ә. Бик еракка билгеләгәннәр мәллә, кызым?

Р о з а (*диванга килеп ава*). Җәһәннәм астына, әни! Даже ан-

нан да арырак. Арктикага! Төньяк котыпка! Бозлар, аюлар арасына! Бетерделәр бит баламның башын!.. (*Елый.*)

Г а л и м ә. Кызым Разия, тукта, алай чәбәләнмә әле. Бөтенләй кеше тормый торган җиргә җибәрмәгәннәрдер бит. Атаң мәрхүм белән без кайларда гына булмадык! Уралында да, Донбассында да дигәндәй, бар җирдә дә булдык. Сабыр ит әле, нәрсәседер билгеле түгел, дип әйтте түгелме соң? Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте бик киң...

Р о з а. Куй әле, әни, зинһар, шул Аллаңны! Эш хәзер Алладан узган инде. Монда хәзер начальникның үзе кирәк. (*Кинәт башына ниндидер уй килә.*) Әйе, начальникның үзе! Һай, атасы бик бозау шул! Әйттем мин аңа: «Начальник белән арагыз бик яхшы. Алдан сөйләшеп куй», — дидем. «Синең сүзеңне тыңлар. Кирәк булса, замминистре белән дә, министре белән дә сөйләшер», — дидем. Имеш, килешә торган эш түгел. Менә хәзер килешер инде... Нигә алданрак үзем чарасын күрмәдем икән? Софья Николаевнадан үтенеп караган булсам, акылым алтын буласы икән. Әллә хәзер үк сөйләшеп карыйм микән? Юк! Мин генә йөз суымны түкмим әле. Бердәнбер улы өчен ул да түгеп карасын. Сөйләшсен начальнигы белән. Ә мин, үз чиратымда, Софья Николаевнага барып ялынырмын. Сүземне аяк астына салмас әле. Иренә шалтыратып карар. (*Телефоннан номер җыя.*) Алло! Управление? Исәнмесез, Антонина Яковлевна! Сезне Роза борчый. Әйе, Роза Алиевна. Мөмкин булса, мине Александр Максимович белән тоташтырыгыз әле. Бер минутка гына. Рәхмәт!.. Искәндәр, бу синме? Янында беркем дә юкмы? Юк? Алайса, бозау син, Искәндәр. Менә шул! Бердәнбер малаеңны харап иттең! Арктикага җибәрәләр үзен. Ни әйттем мин сиңа: сөйләшеп куй алдан начальнигың белән, дидем. Ниткән килешмәгән инде ул! Бердәнбер улың анда бозлар арасында катып үлгәндә... (*Елый.*) И Ходаем!.. Юк, мин болай калдыра алмыйм! Син сөйләшмисең икән, начальнигың янына үзем барам. Минем сөйләшүем килешмәсә, алайса, үзең сөйләш. Уйлап кына кара: Арктикага бит! Арктикага! Исемен генә ишеткәндә дә җаннарың боз була. Юк, сөйләшеп карармын гына түгел, ныклап сөйләш! Ялын! Үтен! Куркыт! Китәм мин бу эштән, диген! Теләсәң нишлә, ләкин Альфредны Казанга билгеләтмичә, күземә дә күренмә! Казанда нефть юк, дисеңме? Анда минем эшем юк. Бөтен җирдә

нефть табалар бит. Казанда да тапсыннар. Кирәк икән, җир астыннан труба белән китерсеннәр. Мин Альфредны беркая да җибәрмим, һич югында, әнә Бөгелмәгә җибәрсеннәр. Менә шул! (*Ачу белән трубканы куя. Аннан, сикереп торып, йокы бүлмәсенә кереп, киенеп чыга.*) Әни, мин хәзер Софья Николаевнага, начальникның хатыны янына киттем. Альфред кайтса, беркая да чыкмасын. Мин хәзер кайтып җитәрмен. (*Чыгып китә.*)

Галимә. Кылануның тәмам чигенә җиттеләр инде. Йа Раббым, үзең мәрхәмәтеңнән ташлама! (*Бер тумбочка астыннан ниндидер китап ала.*) Булмаса, үзем догаларымны укып карыйм әле. Бәлки, берәр файдасы тиеп куяр. (*Күзлеген киеп, догаларын укырга тотына. Шул вакыт звонок шалтырый. Галимә ишек ачарга чыгып китә. Бераздан соңгы мода белән киенгән бер кыз килеп керә.*) Әйдә, Сәкинә кызым, түрдән уз!

Матильда. Минем исемем Матильда хәзер, әбекәй. Миңа моннан ары шулай дип дәшегез.

Галимә. Әстәгъфирулла! Анысы нинди исем тагын? Әле күптән түгел генә Суния дип йөртә идең түгелме соң? Бу Мәтилдә дигәнен каян таптың тагын?

Матильда. Суния түгел, әбекәй, ә Соня иде. Шулай ук Мәтилдә дә түгел, ә Матильда. Ударениесе «и»дә. «Ма»сы — «а» белән, ә «да»сы — «а»га якын «ы» белән Ма-тиль-да! Французча исем. «Красное и черное» картинаны караганнан соң, иптәшләрем шулай куштылар. Характерың да, төсең дә Матильдага бик охшый, диделәр.

Галимә. Алайса, Мәтилдә кызым, сиңа охшагач, бик матур нәрсәдер инде ул!

Матильда. Искиткеч матур, әбекәй! Даже миннән дә матуррак. Шуның өстенә бик самостоятельная! (*Тагын звонок шалтырый. Галимә чыгып китә. Бераздан бик шәп киенгән Альфред килеп керә.*)

Альфред. О, Матильда! Вот әйбәт булган! Мин сезгә звонить иткән идем, әле генә институтка китте, диделәр.

Матильда. Институтка барырга иртәрәк иде. Синең хәлеңне беләсем килде. Ну, успехлар ничек?

Альфред. Успехлар — во! «Арктикнефть»нең проектлар бю-

росына назначение алдым. Инженер-проектировщик. Москвада эшләргә!

М а т и л ь д а. Ой, нинди молодец син, Альфред! (*Альфредның кочагына атыла.*) К чорту, болай булгач, экзаменнары! К чорту, болай булгач, институты! Москвага, Альфред, Москвага! Мин настоящая Матильда! Мин синеке, Альфред! Ничек ди әле кинодагы Матильда? Әйе: «Мин — синең колың!» Син мине менә хәзер үк теләсәң нишләт, Альфред! Мин — синең колың!

А л ь ф р е д. Син минеке, Матильда!

М а т и л ь д а. Мин бүген үк Москвага, әтигә звонить итәм. Ул анда безгә со всеми удобствами квартира устроить итәчәк. Без анда шундый обстановка булдырырбыз, мактанчык Валя көнләшүеннән шартлар! Без анда көн саен кунаклар кабул итәрбез. Без анда көн саен танцы организовать итәрбез. Москвага, Альфред, Москвага!

А л ь ф р е д. Но, Матильда, минем зарплатам...

М а т и л ь д а. Зарплата? Ха-ха-ха! Ерунда ул синең зарплатаң! Минем әти, әгәр дә сорасам, миңа ай саен өч мең биреп торачак. Ә синең әтиең? Неужели үзенең улына аена өч мең бирмәс?

А л ь ф р е д. Анысын әни устроить итәр, конечно...

М а т и л ь д а (*тагын Альфредның кочагына ташлана*). Әйттем бит, Альфред, молодец син! (*Тагын звонок шалтырый. Яшьләр аерылышалар. Бераздан, берәүдән нindidер төргәкләр күтәртеп, Роза ханым килеп керә. Ул, төргәкне диванга куйдырып, теге кешегә акча түли дә яшьләрне күрә.*)

Р о з а. Балаларым минем! Харап иттеләр бит сезнең киләчәк тормышыгызны!

А л ь ф р е д. Нәрсә булды, әнкәй?

М а т и л ь д а. Ни булды, Роза Алиевна?

Р о з а. Бердәнбер улымны — Арктикага! Бозлар һәм аюлар арасына! Миннән башка ничек яшәрсең син анда, балакай? Ничек син, акылсыз малай, шундый ерак җиргә китәргә ризалык бирдең? Ничек син бердәнбер әниеңне ялгызын Казанда калдырып китәргә риза булдың? Нинди йөрәк белән син Матильдаңны ташлап китәрсең? Кая гына бит әле! Арктикага! Бозлар, аюлар арасына!..

А л ь ф р е д. Нинди Арктика турында сөйлисең син, әни?

Р о з а. Соң, үзең әйттең ич инде: Арктикага җибәрәләр, дидең.

А л ь ф р е д. Минем алай дип әйткәнем юк ич, әни. Мин бит, «Арктикнефть»кә назначать иттеләр, дидем.

Р о з а. Ә синеңчә, ул Арктикада булмыйча, Москвадамыни?

А л ь ф р е д. Конечно, Москвада. Мин шунда проектлар бюросында инженер булып эшләячәкмен!

Р о з а (*хәлсезләнеп, диванга утыра*). Москвада?!

А л ь ф р е д. Әйе, Москвада.

М а т и л ь д а. Әйе, Москвада, Роза Алиевна. Мин әтидән по телефону шалтыратып, специально үтенгән идем һәм ул моны эшләгән.

А л ь ф р е д. Әйе, моның өчен без Галим Алимовичка бурычлы.

М а т и л ь д а. Ул безгә Москвада со всеми удобствами квартира устроить итәчәк.

Р о з а (*назланып кына*). Ә мин?

А л ь ф р е д. Әни, без сине үз яныбызга алырбыз.

Р о з а. Ә әтиең?

М а т и л ь д а. Әгәр мин әтидән сорасам, ул аны да Москвага устроить итә ала, конечно.

Р о з а (*күкрәген тотып, диван аркасына сөялә*). Ой, Москва! Москва! Минем хыялым! Москва! (*Кинәт сикереп тора.*) Ха-ха-ха! Ә мин бит, балалар, нинди глупость эшләдем бүген! Альфред Арктикага китә, дип, бөтен комиссионныйларны әйләнеп, җылы киемнәр эзләп йөрдем. Саша да шунда билгеләнде, дигәч, аның әнисе белеп өлгергәнче алып калыйм, дип, комиссионныйлардагы барлык җылы киемнәрне җыеп йөрдем. (*Төргәкләрне сүтеп, төрле җиргә сибә башлый.*) Менә монысы гага мамыгыннан эшләнгән куртка. Менә монысы җылы унтылар. Менә арктика өчен махсус эшләнгән бельелар. Менә носкилар. Менә бияләйләр... Уф, аякларым бер дә калмады... Уф, нинди дурочка мин! (*Диванга барып утыра.*) Мин Искәндәргә шалтыратып, начальнигына керергә куштым. Софья Николаевнага барып, иреннән үтенүен сорадым. Имеш, мин аны Казаннан бер адым да читкә җибәрмим!

А л ь ф р е д (*куркынып*). Син нәрсә эшләдең, әни?!

Р о з а. Әйттем ич: дурочка мин, улым. Ду-роч-ка!

М а т и л ь д а. Әгәр дә алар, сезнең үтенүегезне тыңлап, Альфредны Казанда калдыртсалар?

Р о з а (*кинәт куркуга төшеп*). Ой! Туктагыз, балалар! Чынлап та! Әгәр дә алар моны эшләсәләр?

М а т и л ь д а. Роза Алиевна, тизрәк шалтыратырга кирәк үзләренә!

Р о з а. Ой, нишләдем мин? Әгәр дә тагын шушы Казанда калдырырга булсалар? (*Көч-хәл белән барып, телефоннан номер җыя.*) Алло! Управление? Ант... Ант... Антонина Яковлевна? Зинһар, Александр Максимовичны бирегез әле! Ә? Ничек? Начальник янына кереп китте? Көтәнме? Ой, нишләдем мин? Антонина Яковлевна, бәгърем, зинһар, начальник яныннан чыккач та Александр Максимович миңа шалтырата күрсен. Зинһар! Үтенәм сездән! (*Трубканы куя да яңадан номер җыя.*) Алло! Софья Николаевнаны мөмкинме? Әйе, Роза Алиевна. Ничек? Мин киткәч тә? Телефон буенча Альфред турында сөйләште дә? Кая киткәнен әйтмәде? Тиз кайтмам, диде? Ой! (*Трубканы куя.*) Ой! Су бирегез миңа! Су! (*Альфред су китерә.*)

А л ь ф р е д. Әни, тынычлан!

Г а л и м ә кереп карап тора.

М а т и л ь д а. Үзегезне кулга алыгыз, Роза Алиевна!

А л ь ф р е д. Әти начальник янына, бәлки, башка йомыш белән кергәндер?

М а т и л ь д а. Бәлки, начальник берни дә эшләп өлгермәгәндер әле.

Р о з а. Юк инде, юк! Барысы да бетте! Үз бәхетемә үзем балта чаптым! Үз баламны үзем харап иттем!

Г а л и м ә. Тагын нәрсә булды, кызым Разия?

Р о з а. Әни, зинһар, дип әйтәм, уйларга мишәйт итмә әле! Әгәр дә тагын шушы Казанда калдырсалар? Ой, нишләрмен мин ул вакытта?

Г а л и м ә. Тукта, кызым, алай чәбәләнмә әле. Аллаһы Тәгалә...

Р о з а. Әни, зинһар, дим, шул Аллаң белән кысылып йөрмә

әле! Эш Алла кулында түгел, начальник кулында хәзер.

Г а л и м ә. Әстәгъфирулла! Тфү! Тфү!

Шул вакыт телефон шалтырый. Барысы да телефонга омтылалар.

Р о з а. Туктагыз, үзем! (*Трубканы ала.*) Әйе, мин, Искәндәр. Ә? Ничек? Әле генә начальниктан чыктың? Тизрәк әйт: нишләргә булдылар? Москва белән сөйләште? Үзе? Кая билгеләделәр дисең? Мин үзем сораган җиргә? Бөгелмәгә? Ой! Харап булдык! (*Трубканы куеп катып кала.*) Бө-гел-мәгә!

Г а л и м ә (*Матильдага карап*). Менә сиңа кирәк булса, кычытмаган башка — тимер тарак!

Барысы да берничә секунд катып торалар. Роза ханым кинәт «Ah!» дип кычкырып, диванга ава, Матильда белән Альфред аның янына йөгерәләр.

Пәрдә төшә.

*1956*

(А.Николаевның «Арктические страсти»
дигән шигыре буенча эшләнде.)

# ӘЛФЕ НӘҺАР ВӘ НӘҺАР, ЯГЪНИ МЕҢ ДӘ БЕР КӨНДЕЗ ЯХУД ШӘҺӘРЗАДӘ МӨХӘММӘТҖАНОВА БЕЛӘН «СӨРЕМСИНДИКАТ»-НЫ ТАЗАРТУ КОМИССИЯСЕ ХИКӘЯСЕ

## Беренче көн

Матур-матур хикәяләр язучылар һәм төрле-төрле җыр вә бәетләр иҗат итеп, шул җырларын вә бәетләрен урам буенча гаһ акырып, гаһ бакырып, укып йөрүче шагыйрьләр шундаен вә мондаен риваять кылырлар кем, бер шәһәрдә «Сөремсиндикат» исемле учреждение бар иде. Бу шәһәрдәге барлык учреждениеләрдә аппаратны тазарту үткәрелеп вә һәр каюсында моның өчен махсус комиссияләр оештырылып, ул учреждениеләрдәге чит элементларны куып чыгарырлар иде. РКИнең* рөхсәте беләнме яки онытылыпмы, ни сәбәптәндер югарыда әйтелгән «Сөремсиндикат»та гына шундый тазарту үткәрелмәгәнлектән, синдикатның төрле вә төрле кавемнәрдән торган хезмәткәрләре, Ходайга мең-мең шөкерләр әйтеп, гамьсез вә борчусыз гомер итәрләр иде. Ахырыләмер, синдикатның каю бер хезмәткәрләре тәшвишкә төшеп: «Мондаен хәл мәңгегә бармас, югары оешмалар беркөнне сизеп алырлар да барыбер тазарту үткәрерләр, лучше үзебез үткәреп калыйк», — дип уйлап, биш кемсәдән гыйбарәт махсус комиссия сайладылар. Комиссиянең составына синдикатның баш бухгалтеры Халатҗановны, бер җаваплы секретарьны, бер регистраторшаны, бер эш йөртүчене вә бер счетоводны керттеләр. Болар барысы да бер ата вә бер ана балалары булып, һәрвакыт бер-берсе белән карендәшлек мөнәсәбәтләре саклап, элекке заманнарда сәүдәгәр аталары вакытында булган тормышларын сагынып гомер итәрләр иде.

Сайланган комиссия эшне озакка сузмастан, тиз генә җыелыш җыеп, синдикатның барлык хезмәткәрләренә бер-берсенең җитешсез якларын күрсәтергә боерды. Шул рәвешчә, җитешсезлекләрне үзара гына бетерергә мөмкин икәнлекне бәйнә вә бәйнә аңлатты.

Ошбу синдикатта Шәһәрзадә Мөхәммәтҗанова исемле бик зирәк вә тапкыр кыз бар иде. Ул күп еллардан бирле иң зур началь-

* Р К И — Эшче-крестьян инспекциясе.

никның личный секретаре булып эшли иде. Комиссия членнары шул кыздан киңәш сорадылар. Шәһәрзадә туташ бу хакта ишеткәч, моның ахыры бик үк күңелле булмаячагын, үзенең элекке жандарм кызы булуының да фаш ителәчәген күз алдына китереп, уен төбе чынга китүдән куркып, тазарту җыелышын ничек итеп булса да соңга калдырырга карар бирде. Шул ният белән ул, сүз алып, комиссия членнарына әйтте:

— Тазарту комиссиясенең хөрмәтле рәисе Халатҗанов иптәш һәм комиссиянең кадерле членнары! Сезгә мәгълүм булсын ки, тазарту аркасында кайю бер кешеләрне урыннарыннан чыгарырга туры киләчәк. Бу эш исә бик зур куркынычлар белән бәйләнгән. Нитәккем, «Комтрест» дигән бер учреждение бер курьерын югалту аркасында гына да гаять зур бәлаларгә дучар булган иде, — диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, комиссия членнары Шәһәрзадә туташтан ул гыйбрәтле вакыйганы сөйләп бирүен үтенделәр.

Шуны гына көткән Шәһәрзадә туташ, кулындагы сумкасыннан төрле хушбуй исләре аңкып торган ефәк кулъяулыгын чыгарып, борынын «лышт» иттереп бер сеңгердектән соңра, тутый кошыдай татлы тел белән хикәяне сөйләргә кереште.

## Хикәя

Моннан күп еллар элек бер шәһәрдә «Комтрест» исемле бер учреждение бар иде. Бу учреждениедә хөрмә талыдай зифа буйлы, кояш тик нурлы йөзле бер егет курьер булып хезмәт итәр иде. Егет Җамалетдин Күкбүрек исемле булып, «Комтрест»ның барлык боерык вә фәрманнарын бер учреждениедән икенчесенә ташу белән мәшгуль иде. Бу егет шулкадәр матур иде ки, төрле учреждениеләрдә личный секретарь булып эшләүче чибәр кызлар бер күрүдә аңа дерүн вә делдин гашыйк булырлар вә:

— Капки бу екет бер җаваплы хезмәткәр булсачы вә мин аның личный секретаре булсамчы! — дип, ошбу бәетне әйтерләр иде:

**Бәет**

Бу екет — гүзәллектә Йосыф пәйгамбәр, —
Булсачы кашки бер җаваплы хезмәткәр;
Булсачы ул күңел багымның бер талы
Вә мин дә аның личный секретаре!

Шулай дип алар аһ вә зарларын җиде кат күккә ашырырлар вә, көзгегә карап, борын өстләрен пудралап алырлар иде.

Ләкин, һай, бу фани дөнья!..

Шул сүзләрне әйтдектән соңра, Шәһәрзадә туташ, хушбуйлы яулыгы белән күзләрен сөртеп алып, хикәяне дәвам иттерде.

— Көннәрдән бер көнне Җамалетдин Күкбүрек ни сәбәптәндер эшкә килмәде һәм шул килүдән бөтенләй юкка чыкты. Бу хәбәр тиз заманда эш башкаручыга ишетелеп, ул да егетнең өенә кешеләр җибәртте. Шул ук вакытта төрле учреждениеләргә ашыгыч чапкыннар күндерелде. Ләкин Җамалетдин Күкбүректән бернинди хәбәр булмады. Йөртергә кеше булмаганлыктан, «Комтрест»ның барлык боерык вә фәрманнары өелеп ятыр иде. Җамалетдин Күкбүрекнең югалуына ике тәүлек дигәндә, өелгән кәгазьләрнең саны чиктән ашып китте вә бүлмәләргә сыймас булды. Ахырыләмер, хезмәткәрләр, каты кайгыга төшеп, кәгазьләрдән өелгән тауларга карап, күз яшьләрен түкдектән соңра, екетне тапкан кешегә зур бүләкләр вәгъдә итеп, шәһәргә игъланнар тараттылар. Екет һаман табылмады, ә кәгазьләр, бүлмәләргә сыймыйча, тәрәзәләрдән урамга агылыр иде. Җамалетдин Күкбүрекнең, югалуына бер ай дигәндә, таратылмый яткан хатлар, фәрманнар вә циркулярлар тәрәзәләрдән ташып чыгып, бөтен урамны бастылар. Шәһәр халкы урамнан зур җәфалар белән генә үтәрләр вә «Комтрест»ның башлыкларыннан кәгазь язуны туктатуларын үтенерләр иде. Трестның башлыклары исә, кәгазь язмыйча эшләп булмавына чын күңелдән инанганлыктан, көннән-көн яңадан-яңа кәгазьләр язарлар вә ул кәгазьләр урамдагы түбәнге ятажларны басарлар иде. Бу хәлне күреп, якын-тирәдәге урамнарда яшәүче халыклар шәһәр янындагы тау башына күчә башладылар. Ниһаять, кәгазь ташкыны, башка урамнарга да җәелә башлап, ахыр чиктә «Комтрест» урнашкан урамны бөтенләй каплап, трест би-

насы барлык хезмәткәрләре белән ташкын астында калып, һәлак булды.

Шул җиргә җиткәч, Шәһәрзадә туташ Мөхәммәтҗанова бу хикәядән тәэсирләнеп, күзләреннән кайнар яшьләрен агызучы комиссия членнарына мөрәҗәгать итеп, түбәндәге сүзләрне әйтте:

— Хөрмәтле тазарту комиссиясе членнары! Менә «Комтрест» белән нindәен гыйбрәтле вакыйга булды. Ләкин бу вакыйга «Домстрой»ның командировкага киткән баш инженеры вакыйгасы янында сукыр бер тиенгә дә тормый, — диде.

Комиссия членнары: «Йә, Шәһәрзадә туташ, ул вакыйганы да сөйлә! Ишетик!» — диделәр. Ләкин Шәһәрзадә, сәгатьнең көндезге өч ярымны сукканын ишетеп, сөйләүдән туктады һәм ул вакыйганы иртәгесен сөйләргә вәгъдә бирде. Шуннан соң комиссия членнары өйләренә таралдылар.

## Икенче көн

Икенче көнне комиссия членнары, нәкъ сәгать тугызга «Сөремсиндикат»ның бинасына җыелып, Шәһәрзадә Мөхәммәтҗанованың килүен көтмәктә иделәр кем, бер биш-ун минут үтәр-үтмәс, синдикатның барлык ишекләре бердән ачылып китте һәм бер ишектән Шәһәрзадә туташның айдай нурлы йөзе күренде. Аның килүен тәкать вә сабырсызлык белән көткән комиссия членнары, аягүрә басып, олугладылар һәм «Домстрой»ның командировкага киткән баш инженеры вакыйгасын сөйләвен үтенделәр. Шәһәрзадә Мөхәммәтҗанова алар белән исәнләштектән соңра, көзге алдына барып, күргән кешеләрнең һүшен алырлык ап-ак йөзен дәхи бер кәррә пудралап, тагын да күбрәк гүзәллеккә чумды һәм «иртәрәк булмагае» дип, сәгатькә карап алганнан соң, сәгатьнең инде унынчы ярты булып килгәнен күреп, былбылдай гүзәл тавыш белән хикәягә кереште.

## Хикәя

Борын-борын заманда көнчыгыш белән көнбатыш арасындагы бер шәһәрдә «Домстрой» исемле бер оешма бар иде. Бу оешма шәһәр өчен төрле биналар салу белән мәшгуль иде. «Домстрой»ның

Җанваров исемле баш инженеры булып, үзенең булдыклылыгы белән мәшһүр иде һәм шәһәрнең бер кырыеннан икенче кырыена кадәр булган бөтен территориядә аны мактап сөйләрләр иде.

Хөрмәтле комиссия членнарына мәгълүм булсын ки, көннәрдән бер көнне, югары оешмаларның күрсәтүе буенча, ошбу инженер ниндидер йомыш белән башкалага алты айга командировкага китеп барды. Бу оешмада эшләүче төрле хезмәткәрләр төрле профессияләр буенча бик зур белгечләр булсалар да, төзү эшләре белән бер дә таныш булмаганлыктан, тирән кайгыга төштеләр. Алар барысы да бергә җыелып: «Аһ, безнең хәлемез! Ваһ, безнең хәлемез! Баш инженердан башка без нәрсә эшләрбез?» — дип, күзләреннән ачы яшьләрен түкәрләр иде. Ләкин алар төзү эшләре белән таныш булмасалар да, бер-берсе белән бик танышлар вә дуслар һәм хәтта кардәшләр дә булганлыктан, бер-берсенең кайгысын уртаклашырлар вә ярдәм итешерләр иде. Ләкин алар күпме генә җыелып уйлашсалар да, бернинди кискен карарга килә алмадылар. Ә шәһәрдәге төрле учреждениеләр «Домстрой»га вәкилләрен җибәреп, кайсы хезмәт сарае, кайсы тулай торак вә кайсы гади йорт салуын үтенерләр иде.

Бу учреждениедә минем кебек личный секретарь булып эшләүче, бик гүзәл һәм белемле бер кыз бар иде. «Домстрой»ны бу бәладән коткаруны шул кыз үз өстенә алды. Ягъни, аның бу учреждениедән тыштa да бик күп таныш екетләре булып, алар барысы да кызга чын күңелдән гашыйклар иде. Шуларның берничәсе, төзү эшләре буенча инженерлык итә алмасалар да, кайчандыр төрле төзү әртилләрендә подрәдчик булып эшләгәннәр иде. Гүзәл кыз шуларны исенә төшереп, «Неужели бишесе бер инженерга тормас!» дип уйлап, шуларны үз янына чакырып алды вә аларны «Домстрой»га инженер булып керергә димли башлады. Тегеләр исә, мондый эшкә керүдән бик курыксалар да, кызның гүзәллеге алдында көчсез калып, ризалык бирделәр вә тиз көндә эшкә дә керештеләр.

Екетләрнең берсе Шелтәев исемле булып, аңа эшчеләр районында алты ятажлы хезмәт сарае салу эше йөкләнде. Икенчесе Салганов исемле булып, аңа шәһәрнең уртасында биш ятажлы клуб салу эше йөкләнде. Вә дәхи берсе Стаканов исемле булып, аңа

үзәк урамнарның берсендә алты катлы зур бер йорт янындагы бер катлы агач өйне сүтеп, аның урынына өч катлы торак йорты салу эше тапшырылды. Вә калган башкаларына да төрле биналар төзү эше тапшырылды.

Шул җиргә җиткәч, Шәһәрзадә туташ: «Эш вакыты үтмәде микән?» — дип, нурлы йөзен сәгатькә төшереп алганнан соңра, вакыт иртә икәнен күреп, хикәяне дәвам итте.

Эш шул килеш кызу темплар белән алып барылу аркасында, тиешле барлык биналар төзелеп беттеләр вә «Домстрой»ның баш инженеры Җанваров та, озак сроклы командировкадан кайтып, төзү эшләренә заказ биргән оешмаларның вәкилләре килеп, биналарны кабул итүгә керештеләр.

Алар, иң элек Шелтәев тарафыннан салынган алты катлы хезмәт сараена барып, кулларына китаплар тотып торган мәрмәр арысланнар куелган баскычлар буенча менеп, әйләнмәле зур ишектән сарайның эченә кереп, төрле рәсемнәр белән бизәлгән һәм меңәрләгән кандилләр асылган зур-зур залларда йөреп, төзү эшләренең гүзәллегенә хәйран калдылар. Бу сарай тикшерүдә катнашкан барлык кешеләрнең һушләренә килеп, сарайны салдыручы Шелтәевкә мең вә мең рәхмәтләр әйтеп, тышкарыга чыктылар. Тик урамга чыккач кына, сарайның ниндидер сәбәпләр буенча бөтенләй тәрәзәсез икәнлеген күреп, телсез калдылар. Беркадәр вакыт шулай телсез калып торганнан соңра, җыелышып РКИгә юл тоттылар. РКИ вәкилләре килеп тикшергәннән соң, Шелтәевнең аңа тәрәзәләр ясатырга онытканлыгы мәгълүм булды.

Шуннан соң алар «Домстрой» салдырган барлык биналарга тикшерү үткәрделәр. Нәтиҗәдә, Салганов төзегән зур клубның тышкы яктан бик матур итеп ясалган булса да, эчкәре керү өчен бер генә ишеге дә юк икәнлеге мәгълүм булды. Комиссия членнары зур баскычлар ярдәме белән тәрәзәләрдән кереп, бинаның түшәм вә идәннәре дә юк икәнлеген күреп белделәр.

Стаканов исә, бер катлы агач йортны сүтәсе урынга, янындагы алты катлы йортны сүтеп, аның урынына ике катлы итеп, өсте таш вә асты агач йорт салып куйган булып чыкты.

Башка йортларның да кайсының берәр стенасы, кайсының түбәсе юк икәнлеге, кайсына пар белән җылыту өчен көпшәләр үт-

кәрелсә дә, пар казанының куелмаганлыгы вә гайре вә гайре кимчелекләре мәгълүм булды.

Шушы тикшерү нәтиҗәсендә, РКИ «Домстрой»ның бөтен аппаратын яңадан карап чыгыш, бу оешмага төзү эше белән таныш булмаган җыен булдыксызлар тулганлыгы мәгълүм булды. Шуннан соң «Домстрой»ның аппараты баштанаяк яңартылып, җитәкчеләре җәзага тартылып, оешманың эшләре җайга салынды.

Хикәяне тәмам иттектән соңра, Шәһәрзадә туташ, тазарту комиссиясе членнарына карап, түбәндәге сүзләрне әйтте:

— Кадерле иптәшләр! Менә үзегез дә күрдегез: бер баш инженерның командировкага китүе аркасында гына да бөтен бер учреждение халык алдында рисвай булды. Ә сез монда тазарту ясап, ничә вә ничә кешене хезмәттән чыгаруга сәбәпче булырга җыенасыз, — диде.

Комиссиянең рәисе Халатҗанов шунда аягүрә басып:

— Соң, кадерле Шәһәрзадә туташ, «Домстрой» бер инженерның командировкага китүе аркасында түгел, ә бәлки хезмәткәрләре үз эшләрен белмәү аркасында һәлак булган бит! — диде вә ошбу бәетне укыды:

**Бәет**

Булмаса оешмада булдыклы беркем дә,
Вәйран булыр ул оешма бер көндә!

Шәһәрзадә Мөхәммәтҗанова аптырап калмады:

— Алай булса, эш белмәү турында мин сезгә шундаен хикәяләр сөйли алам ки, мин хәзергә кадәр сөйләгән вакыйгалар алар алдында фил янындагы чебен кебек кенә булып калачаклар! — диде.

Шәһәрзадәнең бу сүзләрен ишеткәч, комиссия членнары, тагын аңа мөрәҗәгать итеп, шул вакыйгаларның берәрсен сөйләвен үтенделәр. Шәһәрзадә туташ, комиссия членнарын шулай мавыктыра алуына вә моның тазарту эшләрен шактый вакытка кичектерергә сәбәп булачагына бик шатланып, сәгатькә карап алганнан соң, сәгатьнең инде дүртенче ярты икәнлеген күреп, аларны иртәгә сөйләячәген белдерде. Комиссия членнары һәм моңа риза булып өйләренә кайтып киттеләр.

А в т о р д а н  б е р н и ч ә  с ү з:

Хөрмәтле укучылар Шәһәрзадә туташның: «Һай, бу фани дөнья!» — дигән сүзләрен хәтерли торганнардыр. Һәм без дә шуны кабатлап әйтергә тиешбез ки, бу фани дөньяда мәңгелек нәрсә бик аздыр кем, Шәһәрзадә туташка да бу хикәяләрен дәвам иттерергә насыйп булмады: өченче көнне үк тиешле оешмалар «Сөремсиндикат»ка да күз салып, анда чын тазарту комиссиясе төзеделәр һәм синдикатның күп кенә җаваплы вә җавапсыз хезмәткәрләрен, шул җөмләдән Шәһәрзадә туташны да, «эштән» азат итеп, аны ошбу хәйләсен туктатырга мәҗбүр иттеләр. Без дә мең көнгә исәпләп башлаган вә шунлыктан «Әлфе нәһар вә нәһар, ягъни мең дә бер көндез» дип аталган ошбу әсәребезне туктатып, каләмебезне бер читкә куеп торырга мәҗбүр булдык.

*1930*

# СЫНАТТЫ

Мин үзем алай бик зур язучы түгел. Үзебезнең фабрикадан газеталарга хәбәрләр язып торам. Ә менә минем танышым Габдулла Сәлимҗанов — ул инде зур язучы, һәм бик көчле язучы. Дөрес, аның әллә ни зур әсәрләре дә юк. Ләкин шулай да бер язарга тотынса, ни җитте генә итеп язмый инде ул. Син аңа, кайчан гына килеп, нәрсә турында гына язарга кушма, шунда ук кулына каләм тотып утыра да, шартлатып язып та ташлый, һәм кулыңа да тоттырып җибәрә. Янәсе, укы рәхәтләнеп абзаң язган нәрсәне һәм үзең дә шулай язарга өйрән. Ә аның язган нәрсәсеннән нинди генә оста редакторлар да, нинди генә бәйләнчек тәнкыйтьчеләр дә бернинди кимчелек таба алмыйлар инде. Мактамаган кеше юк үзен. Шундый итеп яза, прәме күз алдына җанлы итеп китереп бастыра. Әйтик, ул Чемберлен турында бер шигырь язса, шигырьдә бернинди әшәке сүзләр булмауга карамастан, ул әйткән Чемберленнең тәки авызына бер менеп төшәсең килә. Йә булмаса, шунда ук бөтен капитал дөньясының астын өскә китерәсең килә! Бер сүз белән әйткәндә, коточкыч көчле язучы ул минем танышым Габдулла Сәлимҗанов.

Ләкин шулай булуга карамастан Габдулла иптәш Сәлимҗанов бер тапкыр бик нык сынатты. Бәлки, ул моның өчен үзе дә әле дә булса үкенә торгандыр. Ләкин, ни генә булмасын, ул, бая әйткәнчә, бик нык сынатты.

Ә вакыйга «Язучылар, производствога йөз белән!» дигән лозунг чыкканнан соң булды. Шул чорда аны безнең фабрикага җибәрделәр, ягъни Габдулла Сәлимҗанов иптәшнең йөзен безнең производствога таба бордылар.

Башта ул, ягъни фабрикага килеп керү белән, беркадәр вакыт аптырап йөрде. Анда барып бәрелде, монда килеп сугылды, әмма җүнле бернәрсә дә яза алмады. Шунда без аңа киңәш бирергә булдык.

— Син, Габдулла иптәш, аерым эшчеләрне өйрән, аларның эшләрен күзәт, шунда хикмәтнең нәрсәдә икәнен үзең дә аңларсың, — дидек.

Һәм ул шулай итте дә. Икенче көнне үк кыру цехына кереп,

анда эшләүче Гыймади янында әйләнә башлады. Бер алдына чыкты Гыймадиның, бер артына чыкты, исемен сорашты, рәсемен төшереп алды, аннан соң бергәләп кайтыш та киттеләр. Соңыннан билгеле булганча, ул аның хәтта өйдәге тормышы белән дә танышкан икән.

Ул үзе, фабрикадан киткәндә, миңа очрап рәхмәт тә әйтте:

— Киңәшегез өчен рәхмәт, иптәшләр! Шулкадәр күп материал тупладым, полный бер очерклык!

Көндезге аш вакытында мине иптәшләр сырып алдылар. Габдулланың кем икәнен сораштылар.

— Бик зур язучы ул, — дидем мин аларга.

— Ну кешесен дә тапкан! — диде иптәшләремнән берсе. — Гыймадины әйтәм. Үзен бер эт итеп гәзиткә язсын әле шул исерекбашның! Рәхмәт бу язучыларга!

Чөнки безнең язучыбыз өйрәнгән кеше бөтен цехның мазасына тигән коточкыч бер исерек прогульщик иде.

Бер араны Гыймади үзе дә миннән килеп сорады:

— Нинди нәстә соң бу каләм тотыш йөргәнегез? Берәр инспектор-мазар мәллә?

Мин аңа мәсхәрәләп кенә карадым.

— Күп прогул ясап йөрсәң, менә шулай була ул. Иртәгә газетада күрерсең әле!

Ул миңа бер сүз дә әйтмәде. Җилкәсен җыерды да янымнан китеп барды.

Иртәгесен үзебезнең цехка барыш керсәм, Гыймади авызын ерыш миңа каршы килә.

— Нәрсә син эшкә алай соңга калыш киләсең? Үзең хәбәрче әле, җитмәсә! Абзаңнан үрнәк алырга тырыш син, энем, — ди бу миңа.

«Тагын салыш килгән икән инде бу исерекбаш!» — дип уйлап куйдым мин. Ә үзе, дөресен әйтергә кирәк, бер дә эчкән кешегә охшамаган.

— Җүнле кеше булгач, әнә гәзиткә дә мактап язганнар абзаңны, — ди бу. — Синең кебек салам сыйракларга Гыймади абзаңнан үрнәк алырга кушканнар. Мә, тишек борын, укып җибәр.

Ул арада безнең янга башка иптәшләр дә килеп җиттеләр, минем кулга Гыймади сузган газетага күзләрен текиләр.

Ә газетаның икенче битендә башына зур хәрефләр белән «Көрәшче йөрәкләр» дип язылган зур очерк җәелеп ята. Урта бер җирендә Гыймадиның рәсемен дә урнаштырганнар һәм астына «Карт эшче-ударник Гыймади иптәш Мөхәммәтҗанов» дип язып куйганнар. Очерк Габдулла Сәлимҗанов имзасы белән чыккан.

Очеркны укып карагач, башларым әйләнеп китте.

Ул, минсиңайтим, безнең прогульщик Гыймадины шундый итеп мактаган, — әгәр дә очеркны ахырына кадәр укып чыксаң, — Гыймади абзаңны берәр пивнойдан эзләп табып булса да кочаклап үбәрсең!

«Без, дигән, бөек көрәшләрдә батыр көрәшчеләр белән һәрвакыт җиңеп чыгарбыз... Шул батыр көрәшчеләр арасында Гыймади абзый беренче сафта бара... Ул үзенең станогы янында бөтен көчен куеп...»

Кыскасы, үтереп мактаган инде үзен.

Без, ягъни эшчеләр, көләргә дә, еларга да белмәдек. Гыймади абзый газетаны бик әйбәтләп төреп, куен кесәсенә салды да станогы янына барып басты.

— Даваегыз, егетләр, анда бозау имезеп тормагыз. Эшкә тотыныгыз! — диде ул безгә, ачы елмаю белән карап.

* * *

Минем Габдулла Сәлимҗановны шуннан бирле күргәнем юк. Безнең фабрикага аяк та басмый ул хәзер.

Ә менә Гыймади абзый турында шуны әйтергә була: ул безнең цехта иң алдынгы бер эшче булып китте. Танымассың да хәзер үзен.

*1931*

## МИН ӘНИНЕ САЙЛЫЙМ!

Гайнулла сайлау җыелышына барырга җыена иде.

Һәрвакыт «мин дә барам!» дип бәйләнә торган улы — кечкенә Җәүдәт — бу юлы да җыелышка барырга теләвен белдерде.

Гайнулла театрга яки кунакка барганда гына бәйли торган галстугын бик әйбәтләп бәйләде дә кечкенә Җәүдәтнең башыннан сыйпады.

— Сиңа барырга ярамый шул анда, улым, — диде ул, бик ягымлы гына итеп.

Җәүдәт һәрвакыттагы гадәтенчә кап-кара күзләрен чытырдатып йомып алды да:

— Ә нигә ярамый? — дип сорады.

Гайнулла аңа бик җитди итеп җавап бирде:

— Кечкенә кешеләрне кертмиләр анда!

Җәүдәт кара күзләрен тагын бер чытырдатып йомып алды.

— Ә нигә кертмиләр?

— Анда Советка сайлау була. Кечкенәләрне шуңа күрә кертмиләр.

Җәүдәт күзләрен тагын чытырдатып йомып алды.

— Ә Совет нәрсә ул?

Гайнулла аңа Советның нәрсә икәнен бик гади итеп аңлатырга тырышса да, кечкенә Җәүдәт, билгеле, бернәрсә дә аңламады, тик күзләрен генә чытырдатып тагын бер йомып алды:

— Ә зурмы соң ул Совет?

— Совет бик зур ул, улым, — диде Гайнулла, тагын бик гади итеп аңлатырга тырышып. — Менә без тора торган дөнья бар бит. Менә шул дөньяның алтыдан бере кадәр.

Җәүдәт тагын күзләрен йомып алды.

— Ә нигә бөтенләе кадәр түгел?

Гайнулла улының мондый соравына елмаеп җавап бирде:

— Бөтен дөньяда Совет сезнең заманда булыр инде анысы, улым, — диде ул, тагын Җәүдәтнең башыннан сыйпап.

— Ә кайчан? — диде Җәүдәт, тагын да зуррак кызыксыну белән.

— Син зур үскәч.

— Ә зур үскәч, мине Советка сайларлармы соң?

Бу сорауга Гайнулланың бигрәк тә кәефе килде.

— Әгәр дә яхшы булсаң, сине дә сайларлар.

— Ә анда яхшы кешеләрне генә сайлыйлармыни?

Гайнулла аның янына ук килеп утырды:

— Әйе, улым, яхшыларны гына сайлыйлар. Кем дә кем эшен әйбәт итеп эшләсә, бөтен нәрсәне белергә тырышса, үзенең белгәнен бүтәннәр белән уртаклашса, усал булмаса, һәрвакыт мыш-мыш йоклап йөрмәсә, шундый кешеләрне сайлыйлар.

Җәүдәт тагын күзләрен чытырдатып йомып алды.

— Ә мыш-мыш йоклаган кешеләрне сайламыйлармы?

— Әйе, — диде Гайнулла. — Анда ударникларны гына, көнетөне тырышып эшләп йөргәннәрне генә сайлыйлар...

Гайнулланың күзе кинәт сәгатькә төште. Ул Җәүдәтнең башыннан тагын бер сыйпап алды да торып китте.

Аның белән бергә Җәүдәт тә бүрегенә барыпябышты.

— Мин дә барам!

— Ә син анда нишләрсең соң, улым? — диде Гайнулла елмаеп.

— Сайлармын!

Гайнулла аның җитди кыяфәтен күреп, көлеп үк җибәрде:

— Кемне сайларсың соң син, улым?

Җәүдәт тагын күзләрен четердәтте:

— Әнине сайлармын. Ул бит көне-төне эшли. Көндез заводта, ә кичен өйдә эшли.

Гайнулланың күңеле бөтенләй йомшарып китте. Ул Җәүдәтне күтәреп үк алды.

— Ә мине нигә сайламыйсың, улым? — диде ул, балаларча үпкәләгән тавыш белән.

Җәүдәт аңа шулай ук моңаеп карады.

— Анда сине сайларга ярамый. Син кайтасың да мыш-мыш йоклыйсың...

Гайнулла Җәүдәтне кинәт шып! итеп идәнгә куйды да ишеккә юнәлде.

— Мәгърифә! Әнә малаеңны кара.

Кечкенә Җәүдәт, шап! итеп ябылган ишеккә карап, бүреген кулга тоткан килеш, идән уртасында басып калды.

*1931*

# ШУЛШАЛЫ БӘЛЕШ МАГНИТСТРОЕ

Обыватель — чыкылдап торган иң гади обыватель — беренче «Пәтилитке»нең үтәлүен дүрт күз белән көтеп торды.

— Җарапшый Ходаем, үзең генә булышлык итә күр инде. «Пәтилитке» дигән нәстәләре хәере белән дүрт елда түгел, өч елда үтәлә күрсен иде инде! — дип көтеп торды.

— Тизрәк үтеп китсен иде инде! — дип, сабырсызланып көтте.

Үзе ул аңа дошман да түгел. Бишьеллык «Пәтилитке» булмагае, меңьеллык «Пәтилитке» төзсәләр дә, ул аңа да каршы киләчәк түгел. Чөнки, аныңча, «Пәтилитке» ул — коммунистларның саф үз эшләре. Теләсәләр, мәңгелек «Пәтилитке» төзсеннәр!

— Хөкүмәт үз кулларында булгач, теләсәләр нишлиләр шул инде! — дип карады ул.

Рас башлаганнар икән, бернишләп булмый — көтәргә туры килә. Чөнки:

— Карагыз әле, тауаришлар, бик кыенга килә бит, ә! Берәр елга гына, бераз ыгый төшкәнгәчә генә кичектереп торасыз мәллә ул «Пәтилитке» дигән нәстәгезне? — дип барып әйтеп булмый бит инде.

Иң яхшысы, бер Алланың үзенә тапшыр да сабыр гына көтеп тор инде аны.

Шуның өчен ул «язганны күрербез» дип көтәргә булды. Көтте. Сабырсызлык белән көтте. Кайбер вакытларны хәтта бераз исәбен дә чуалта башлады:

— Кая соң, үзләре дүрт елда тутырабыз, дип шапырынганнар ие, инде өч ел да үтеп бара, бер дә тулганы күренми ләбаса! — дип тәшвишкә дә төшкәләде.

Шулай да көтте. Көтсә дә, көтмәсә дә көтте.

* * *

— Ә ул «Пәтилитке» үтәлгәч, нәрсә булачак соң? — дип сорасаң, моңа ул ачык итеп:

— Иң әүвәле, менә фәлән нәстә булачак, аннары соң төгән нәстә булачак, аннан килеп инде мондыйлары булачак, шуннан соң

инде тегендиләре булачак, — дип, бармак белән санап, җавап бирә алмый иде. Ләкин аның көндәлек фикерләренә, уйларына, сүзләренә, аһ-зарларына карап, аның «Пәтилитке»сенең нәтиҗәсен беркадәр чамалап була иде.

Ул, үзенең җәмгыятьтә тоткан урынына һәм шул җәмгыятькә эшләгән эшенә карап бирелә торган «ризык»ны алу өчен ипи кибетендә чират көтеп торганда, шүрлекләрдә өелеп торган икмәкләргә карап, тирән фикергә тала иде:

— Кара син бу хикмәтне, ә? Тәмне генә итеп ашый башлаган идек бит, ә? Күмәч кенә биргәннәренә дә риза түгел идек бит, ә? Бу күмәчләре белән тәмам төчеләнеп беттек инде, дип сукрана торган идек бит, ә? Булган икән заманнар, малай, ә?.. Бу «Пәтилитке» дигән нәстәләре үтәлсә, шәт, ак күмәч тә бирә башларлар әле, ә?

Икенче класс мунчага барып, билеткә түләгән акчасының бәясе чыксын өчен, ләүкәнең иң түренә менеп утырып, искереп беткән каен себеркесе белән җиде ташкыр рәттән чабынып, чөгендер төсле кып-кызыл булып өйгә кайтканнан соң: «Мунча артыннан чәйне әче нәрсә белән эчсәң, бик җилле була», — дип, «малин» чәенә суган турап, «мунча чәе» эчкәндә дә сүзне шул «Пәтилитке» тирәсендәрәк йөртә башлый иде:

— Бервахытны мунчадан кайта торган иең, минсиңайтим. Илаһым бер лимунлап чәй эчеп җиешәрә торган иең. Прәме аяк бармакларына кадәр төшә торган ие. Каян гына килеп чыкты соң бу «Пәтилитке» дигән нәмәстәкәйләре!

— Бу нәстәләр тормышның рәтен беләләрмени соң! Аларга шул, тиле таш җыяр дигәндәй, завут та фабрик булсын! Ичмасам, шул нәстәләре тизрәк үтәлсә... Кая, катын, булмаса, тагын шул суганыңны турап бир әле! — дип, аяк бөкләп утырып, чәй эчүен дәвам иттерә иде.

Аннан-моннан җүнәтеп, кодаларын кунакка чакыргач, үзенең «шундый хәлгә» төшүенә бик уңайсызланып, гомер буе болай «коргаксып» тормаганын, заманында бик шәп итеп кунакка йөрешә белгәнен аңлата башлый иде:

— Аның шул, чолан тулы бодай оның булса, өялдыңда тушлап-тушлап сарык итең торса, майны карыннан гына алып тотсаң, дөньяның кызыгы шунда инде аның!..

— Бу «Пәтилитке» дигәннәре!.. — дип өстәп куя торган иде ул аннары, авыр гына сулап.

* * *

Болардан, «Пәтилитке» үтәлсә, нәрсәләр булачак икәнлеге турында обывательнең ничек күз алдына китерүен беркадәр чамалап була.

Ягъни, «Пәтилитке» үтәлсә, пирвыйм дулгым, дөнья тулы ак күмәч була.

Мунчадан кайткач, чәй эчәргә лимун була.

Базар тулы төрле ризык: капчык-капчык нүләвәй он, тушлап-тушлап сарык ите, карын-карын туңмай, яшнек-яшнек такта чәй, шүрлек-шүрлек башлы шикәр, каздыр, үрдәктер, баш-аяктыр дисеңме, барысы да, барысы да берьюлы пәйда була.

Шулардан:

Иртәнге чәйгә кайнар пәрәмәч пешерелә.

Аш арты чәйгә бик әйбәтеннән генә симез ат картасы пешерелә.

Җомга көннәрне шулпалы бәлеш пешерелә.

Кодалар белән кунакка йөрешелә.

Җиләк вакытында 7–8 банкы варенье кайнатыла.

Ял көннәрендә төрле коры-сары пешерттереп, хатынына җефәк шәлен бөркәндереп, ике баласын җитәкләп, Арча кырына менелә. Анда самавыр куйдырттырып чәй эчелә. Самавырга, хуш ис чыксын өчен, дәхи дә лимун кабыгы салына. Әгәр дә, бик кәефенә килсә, күршеләре белән җыелышып, такта арбага төялеп, дөгесен, маен, итен, чәен, мәен алып, самавырны кочаклап утырып, фирмегә яки Бакалтайга, Мәлихә куаклыгына барыла яисә Осланга чыгыла. Ял көне «кәефле» үтсен өчен, кимендә бер кәрҗин сыра да алына. «Кызып-китеп» җитми башласа дип, запаска бер-ике бутыйлкы гына «әчесе» дә кыстырыла.

Җыен җиткәч, төрле кәнфит һәм прәннекләр алып, авылга кайтып киленә.

Кеше күз алдына чыкканда «затлырак» күренер өчен, хатынына сак тектереп, үзенә кәзәкигә заказ бирелә. Айга бер мәртәбә

гармун һәм эскерипкә белән, махсус бал куйдырып, җырлы, «дикламацияле» «вичер» үткәрелә...

Бер сүз белән әйткәндә, дөньяда нинди «иң яхшы» тормыш булса, шундый тормыш корып җибәрелә.

Чөнки, обывательнең уенча, «Пәтилитке»нең үтәлүе белән, хәтта икенче көнне үк менә шуларның барысын да эшләргә мөмкинлек туа.

* * *

Ә инде «разный төзелеш-мазар»га килгәндә, обыватель өчен аларның әһәмияте юк. Синең әллә нинди гигант завод-фабрикаларыңда, әллә нинди автомобиль, трактор һәм комбайннарыңда, прокат станнарыңда һәм блумингләреңдә, домна һәм мартеннарыңда, электр станцияләреңдә һәм текстиль машиналарыңда, бер сүз белән әйткәндә, бишьеллык планга кадәр бездә бик аз булган һәм шуның нәтиҗәсендә үсеп чыгачак нәрсәләрдә аның эше юк.

— Сәвит дигәнең машина җыярга мачтыр инде ул! — дип карый ул аларга.

Аның өчен экономикаң ни дә, политикаң ни, чит илләргә бәйлелегең ни дә, бәйсезлегең ни, оборона куәтең ни дә, халыкара әһәмиятең ни, социализмың ни дә, сыйныфсыз җәмгыятең ни!

— Анысы инде, агайне, безнең эш түгел! — дип карый ул.

— Җиңел индустрия дигәннәре, анысы болай ничава инде. Җиңел тек җиңел. Кесәгә ул кадәр керми. Аның менә авыр индустрия дигәне авыррак. Кесәгә шунысы бик нык керә аның! — ди иде ул, «политика»га бик бирелеп киткән чакларда.

Аны хәтта җәмәгать туклануының үсүе, фабрика-кухняләр, икмәк заводлары, ашханәләрнең көннән-көнгә артуы да кызыксындырмады.

— Аш пешерер өчен нинди фабрик кирәк булсын ди ул! Дирбиясе генә булсын аның! Дирбиясе булса, ничек пешерергә икәнен үзебез карар идек әле! Базарда барысы да тулып ятканда, җегерме пар кунак өчен уникешәр төрле ашны «ыһ» та итмичә, күз ачып йомганчы әзерләп өлгерә торган иек әле! — дип, кулын гына селтәде.

Әгәр дә син аңа Казгрэсне күрсәтеп:

— Йә, бу турыда нәрсә әйтәсең? — дип сорасаң, шаккатып:

— А!.. Менә кая икән ул «Пәтилитке»!.. — дип куя ул.

Ләкин сез моңа карап, «Тәки төшенде бит» дип куанырга ашыкмагыз. Сез аны тагын да тыңлап карагыз. Сезгә артык куанырга ул үзе дә ирек бирмәс:

— Менә шунда киткән икән инде ул акчалар! — дип, мәгънәле генә итеп күзеңә карап куяр.

Әгәр дә син аңа Магнитстрой, Кузнецкстрой, Сталинград һәм Харьков трактор заводлары, Горький автозаводы һәм башкалар кебек гигантларны күрсәтсәң, аның тәмам акылдан язуы мөмкин.

Ул бу гигантларга үзе ашарга тиешле булган күпме бодай оны, ничә вә ничә мең капчык дөге, ничәмә кәрҗин кура җиләге, никадәр үрдәк баш-аягы, күпме сары май, күпме шикәр һәм күпме катык киткәнен, бу гигантларның турыдан-туры аның авызыннан тартып алып, күпме пәрәмәчлек сум итеп йотканлыгын уйлап, һуштан язачак.

Ул бит, үзенең уенча, шул гигантларны төзүгә киткән «ризык»ка күпме кунак чакырган булыр иде... Ул аңа — дүр-р-рәк! — ничәмә табын мәҗлес үткәргән булыр иде!..

* * *

Ул, әйтик, Магнитстрой янына килеп баса. Бик мәгънәле итеп карый. Ләкин шушы кадәр зур заводның нәрсәләр генә эшләп чыгарачагын күз алдына да китерә алмый:

— Ай-яй-яй-яй-яй!.. Нәмәстә генә эшләп чыгара микән шушы хәтле зур завуд, ә? — дип уйлый ул.

— Какуй нибуйт чуен өчен генә шушындый нәмәстә кормаслар. Чуен гына түгелдер, малай! Берәр хикмәте бардыр моның. Җә мылтык эшли торганнардыр. Җә булмаса, сәмәлүт-мазар ясый торганнардыр...

Ул артык уйлый алмый. Аның зиһене чуала башлый. Күз алдына тагын шул ук итләр, майлар һәм дөгеләр, тагын шул ук туйлар, мәҗлесләр һәм шулпалы бәлешләр килә башлый.

— Вәт, ичмасам, шулпалы бәлеш эшләп чыгара торган булса ие бу завут, ә? — дип куя ул.

Аның күз алдыннан, Магнитогорскийда пешеп чыккан һәм озын конвейерга тезелеп, бер-бер артлы агылып торган исәпсез-хисапсыз шулпалы бәлешләр уза.

Домналардан, мартен мичләреннән яңа гына чыккан бәлешләрнең парлары куе булып күккә күтәрелә.

Обывательнең авызына сулар килә...

*1933*

## ҺАМАН ШУЛ БЕР ЯРЛЫГА!

— Ни килсә дә һаман шул бер ярлыга килә инде! — ди торган иде Субуе Фәхри. Әйтерлеге дә бар иде шул мескеннең! Нинди генә нужалар күрмәде ул шул ярлы чагында! Корылыгы да, ачлыгы да, бозы да, саранчасы да, үләте дә, сырхавы да дигәндәй, — барысы да, барысы да килде аның башына. Ярлыдан хәерчегә әйләнде бичаракай.

Ул вакытларны Фәхринең ишегалдында юан тал башына ояла-ган өч семьялы каргадан башка, — кош-корт дип әйтикме инде шунда, — бер генә җан иясе дә юк иде. Хәллерәк кешеләрнеке шикелле абзарда пошкырып торган ала бияне күз алдына китерү кая инде ул! Сыер түгел, кәҗәсе дә юк иде аның. Буп-буш иде Фәхринең ишегалды. Өендә чебен борынын кытыкларлык аш-су исе дә булмаганлыктан, бүтәннәрнең тәрәзәләрен ватардай булып ажгырып йөргән чебен дә күренми иде хәтта. Әгәр дә берәр чебеннән: «Нигә сез Фәхринең ишегалдына гына булса да кереп карамыйсыз?» — дип сорасаң, алар, һичшиксез: «Ул ач хәерченең иснәрлек нәрсәсе дә юк бит. Үзе дә кеше өстендә туеныш тора ул!» — дип җавап бирерләр иде.

Фәхри менә шундый дәрәҗәдәге ярлы иде.

Бәлки, ул гомерен дә шул килеш уздырган булыр иде, тик колхоз дигән нәрсә килеп чыгып кына Фәхрине кеше итте. Аның ишегалдына да, сирәк-мирәк кенә булса да, күршеләренең чебеннәре кергәли башладылар. Кеше балаларының авыз-борын тирәләренә кунган чебеннәргә хәтле кызыгып гомер иткән Фәхринең үз малайларының авыз тирәләренә дә чебеннәр кунгалый башлады.

Фәхринең ишегалды да күзгә күренеп үзгәрә башлады.

Иң әүвәл, беренче терлек сыйфатында, аның ишегалдына, кәкре мөгезләрен торгызып, сакалларын селкетеп, мәһабәт адымнар белән атлап, ап-ак бер кәҗә килеп керде. Моңа кадәр бернинди каралтысы булмаган ишегалдында япнек хәтле генә булса да «кәҗә сарае» барлыкка килде. Аннары, берән-сәрән генә булса да, тавык-чебеш тә күренә башлады. Үзен колхоздан төрле атлы йомышларга йөртә башлагач, йомыш белән кайткан араларда гына булса да, ат та керә башлады. Бераздан ул берничә сарыклы да булды.

Вакыт үтү белән малайлары да эшкә ярый башладылар. Әле район үзәгендә булып, әле Казанга барып, докторлардан дәвалата башлагач, берәр тапкыр Казан янындагы санатури дигән җирдә дә булып кайткач, озак вакытлар биләнкә булып яткан хатыны Фахирә дә эшкә чыкты. Кыскасы, Фәхринең тормышы яхшырганнан-яхшырды. Ул инде ялгыз чагындагы хәерче түгел иде.

Ләкин, аңа карап, Фәхри теге:

— Һаман шул бер ярлыга инде! — дигән сүзен ташламады.

Көтелмәгәндәрәк берәр эшкә кушсалар да, ашап утырган җиреннән, ашын бүлдереп, берәр йомышка җибәрсәләр дә, эштән арып-талып кайтып, «инде ятам!» дип торганда гына җыелыш-мазарга чакырсалар да, ул һәрвакыт:

— Һаман шул бер ярлыга инде! — дип зарланмый калмый иде.

Ә вакыт үтте дә үтте. Печән чаптылар, урак урдылар, ашлык суктылар, бәрәңге казыдылар, кәбестә җыйдылар, чәчү чәчтеләр, туңга сөрделәр дигәндәй, Фәхрине һәрвакыт эшкә җигеп кенә тордылар. Хатынын да онытмадылар, малайларын да әйдәделәр, нәни кызларына да эш таптылар — кырдан башак җыйдырттылар. Хәтта ничә еллар буе мич башыннан төшмичә, «менә үләм, менә үләм!» дип яткан, ләкин һаман үлә алмыйча, тормыш белән бергә яшәрә башлаган әни карчыгына да эш табылды — ашлык ташуның бик кызган көннәрендә капчык яматтылар.

Фәхри бу эшләрнең берсеннән дә баш тартмады. Башкаларны да эшкә чыгармый калмады. Ләкин һаман теге сүзне кабатлады.

— Һаман шул бер ярлыга инде! Бүтәннәр әнә... — диде ул бик ачуы килгән чакларда.

— Соң, кем, ни, Фәхерттин, күп эшләсәң — хезмәт көнен дә күп алырсың! — диделәр аңа. — Күреп торасың — эш көче житенкерәми бит...

Анысына Фәхри үзе дә җавап кайтармады. Шыпырт кына кайта да семья членнарының хезмәт көннәрен чутлап карый һәм үзенә ышанмыйча: «Ялгыш чутламыйм микән?» — дип, башын кашый иде.

Ничәмә йөз пот ашлык тия. Әллә нихәтле бәрәңге тия. Балымае дигәндәй, анысы тия, монысы тия. Чутлап бетерерлек түгел!

«Ул тикле бирмәсләр. Чутлый белмимдер...» — дип уйлый иде ул андый чакларда.

Ул шулай уйлап йөргәндә, беркөнне тоттылар да Фәхринең кечкенә генә ишегалдына тау-тау итеп төялгән олаулар белән әллә нихәтле ашлыкны китерделәр дә аудардылар.

— Дабай, тизрәк бушат! Капчыклары кирәк! — диделәр.

— Туктагыз әле! — диде Фәхри, аптырауга төшеп. — Бу тикле нәрсәне кая куйыйм мин? Минем бит келәтем дә юк...

Аның ай-ваена колак та салмадылар:

— Дабай тизрәк! Капчыклары кирәк! — дигән сүзне генә кабатладылар.

— Бераз гына мөһләт бирегез инде! — дип ялынып та карады Фәхри. Файдасы тимәде. Җәярлек нинди нәрсәсе бар, шуның барысын да ишегалды уртасына җәйдереп, ашлыкны шунда бушаттылар да чыгып та киттеләр.

Алай уйлап карады Фәхри, болай уйлап карады, ләкин китерелгән ашлык кая гына тутырсаң да сыярлык булып чыкмады. Аптырагач, күршеләренә дә кереп ялынып карады. Алар да кулларын гына селкеделәр. «Үзебезнекен дә кая куярга аптыраган әле!» — дип кенә җавап кайтардылар.

Тирләп бетте, миңгерәп чыкты Фәхри. Өйгә тутырды, очырмага тутырды, идән астына тутырды. «Кәҗә сарае»на да өлеш чыкты. Иләк калмады, чиләк калмады дигәндәй, өйдә ашлык салмаган савыт-саба калмады. Мендәр тышларына кадәр эшкә җигелде. Утырырга урын, ятарга урын-җир калмады.

Фәхри агай шуларны көч-хәл белән урнаштырып бетергәннән соң, тәмам хәлдән таеп, идән уртасында калган буш урынга килеп басты да, кулын селкеп, идәнгә бер төкереп куйды.

— Һаман шул бер ярлыга! — диде ул, ишек төбендә басып, өйдәге ашлыкка хәйран булып торган хатыны Фахирәгә карап. — Һаман шул бер ярлыга!.. Болай булса, бер келәт шикелле нәрсә оештырмый булмас, ахры, карчык! — дип өстәп куйды ул аннары, тәмәкесен төрә-төрә.

Ә уенда келәт кенә түгел иде инде...

*1933*

## ХӘЗРӘТ АГИТАЦИЯСЕ

Җәйнең бик матур көне иде.

Миңа, узып барышлый, Чалканъяр авылында бер кичкә тукталырга туры килде.

— Бу авылны күрми китмә. Син бит язучы кеше. Сәер хәлләр булгалый биредә. Бигрәк тә кичләрен. Әллә ни соңга калмассың әле! — диделәр миңа таныш хәбәрчеләр.

Һәм чынлап та шул ук кичне сәер бер вакыйгага очрадым мин.

Мин, караңгы төшкәчрәк, «Тукта, кырдан кайтканнардыр инде» дип, колхоз идарәсенә таба киттем. Ләкин озак барырга туры килмәде, урамның бер ягында ниндидер кешеләр сөйләшкән тавыш ишетеп һәм бер капка төбендә җыелып торган 7–8ләп кешене күреп, шулар янына барып тукталдым.

Капка төбендәге төркем ниндидер бер хәзрәтнең сөйләгәнен тыңлап тора иде. Хәзрәт, өстендәге чапанының киң җиңнәрен җилфердәтә-җилфердәтә, кулларын бутап, ашыга-ашыга нидер сөйләнә һәм, капкадан берәрсе килеп чыкмагае дигән шикелле, кинәт артка карап-карап куя иде.

Мин, үземне бик үк күрсәтмәскә тырышып, шыпырт кына төркемнең куерак җиренә килеп, берсенең артына постым.

«Тыңлап карыйк әле, нинди хикмәт бар икән монда?» — дип уйладым мин.

Хәзрәт мине күрмәде булырга кирәк, як-ягына каранып, сүзен дәвам иттерде:

— Иң әүвәле сезнең активлык кирәк, туганнар. Колхоз председателен бер көн дә тотарга ярамый. Ул безнең файдага эшли торган кеше түгел. Үз ягын гына кайгыртa ул. Үзегез беләсез инде...

Мин ачыктан-ачык алып барылган кулак агитациясеннән бигрәк, аны тыңлап торган төркемнең составына хәйран калдым: аларның күпчелеге яшьләр иде.

Шуның өстенә, кулак ялчысы булырга кирәк, берсе өстәп куйды:

— Эшен тизрәк карарга кирәк аның...

— Иртәгедән калдырырга һич тә ярамый, — диде тагын берсе.

Минем маңгайга салкын тирләр бәреп чыкты.

«Юк, моңа мөмкинлек бирергә ярамый. Тизрәк идарәгә барып әйтергә кирәк. Берәр ашыгыч чара күрсеннәр», — дип уйлап, мин тиз генә китмәкче булдым.

Ләкин хәзрәтнең тагын сөйли башлавы мине торган җиремнән кузгалмаска мәҗбүр итте. Ул тагын артына борылып карады да, гаҗәпкә каршы, шактый кычкырып сөйли башлады:

— Барыгыз, эшегезне бетерегез дә сәгать унга минем янга килегез. Мин монда бераз маташтырып чыгам да, шунда үзем барырмын. Бүтәннәргә дә әйтегез. Ләкин карагыз аны, бик шапылдап йөрмәгез.

Бу сүзләрдән мин тагын эсселе-суыклы булып киттем. «Контрларның оясы икән бу!» — дип уйлап, тагын идарә ягына таймакчы булдым. Чөнки шикләнерлек урын калмаган иде инде.

Шунда ишегалдыннан, капканың артыннан гына:

— Гыймади! Хәзрәт? Кая китте инде тагын? — дигән юан тавыш ишетелде һәм капкадан тавышы кебек үк юан бер егет килеп чыкты.

— Әйдә инде, баядан бирле сине эзлибез, ә син монда ятасың икән. Эзләмәгән җирне калдырмадык, ролеңне ташлагансың да чыгып киткәнсең, — диде ул.

Хәзрәт кабаланды.

— Ә, хәзер, ни, без монда Гайфи мәсьәләсен генә нитә идек. Без бүген җыелып, ниһаять, аны алып төшерү мәсьәләсен карамакчы булдык. Югыйсә тәмам эшне чуалтты бит, — диде ул, җитди генә итеп.

— Шул булыр инде синең. Һәрвакыт, берәр йомыш табып, репетицияне ташлап чыгасың, иртәгә спектакль бит, — диде теге юан егет.

Хәзрәт аны култыклап алды:

— Син ачуланма инде, туган. Партком секретаре булгач, нишләтәсең инде. Минем өчен бүтән кеше җыймас бит партия членнарын... Син менә үзең дә сәгать унга минем янга кил. Җыелыш үткәреп алырбыз...

Ул теге юан егетне капкадан алып кереп китте. Төркем шунда ук таралды. Мин дә үз юлыма киттем.

*1934*

## ДЕЛЕГАТ

Өйгә кайтып җиткәндә, Сибгатулланың бөтенләй рәте калмаган иде инде. Ул туп-туры караватка барып ятты. Хатыны Рабига бераз капкалап алырга тәкъдим иткәч тә кулын гына селекте.

— Башым авырта... — диде ул, чыраен сытып кына.

Алты яшьлек улы Равил тагын кайгыга төште. Чөнки соңгы вакытларда әтисенең болай авырып кайтуы бигрәк тә ешаеп киткән иде.

— Әтигә нәрсә булган? — дип сорады ул әнисеннән.

Рабига аның башыннан сыйпады.

— Бар, улым, ят инде. Күрәсең ич, тагын авырып кайткан...

Равил, үзенең дә күрше малае Галәви кебек ятим калуыннан куркып, әтисенең ыңгырашуын тыңлый-тыңлый йоклап китте.

Сибгатулла исә бу төнне бигрәк тә каты ыңгырашты. Ул башының авыртуына чыдый алмый иде. Шуның өстенә бүген аның белән булган күңелсез бер вакыйга йокысын качырган иде.

Ә бүген Сибгатулла эшли торган артельдә атаклылар съездына делегатлар сайладылар. Барлыгы биш кеше сайланды. Ә Сибгатулланы бөтенләй телгә дә алмадылар. Әллә нинди малай-шалайларны, артельгә әле быел гына диярлек кергән апайларны сайладылар. Ә ун ел буена диярлек шушы артельдә эшләп, шуның өчен бөтен көчен биргән Сибгатулланы телгә дә алмадылар.

— Башың авырта, димисең, кәефең юк, димисең, иртән киләсең, кич китәсең... ә алар синең барлыгыңны да күрмиләр... — дип уйлады ул җыелышта утырганда. Үпкә белдереп, президиумга язу да биреп карамакчы булды ул. «Бәлки, берәрсе минем кандидатурамны күрсәтмәсме әле», — дип көтеп тә карады ул. Ләкин һаман аны искә алучы булмады.

Сибгатулла артык түзә алмады, җыелышның ахырын да көтеп тормыйча, башын тотып, җыелыш барган идарә бүлмәсеннән чыгып китте.

— Искә алырсыз әле Сибгатулла абзагызны! — дип уйлады ул чыгып киткәндә. — Искә алырсыз...

* * *

Сибгатулла бүген артельгә көндәгедән соңгарак калып барды. Ул барып кергәндә, идарә бүлмәсендә тагын ниндидер җыелыш бара иде.

— Иртә таңнан нинди җыелыш соң бу? — дип уйлады ул ишектән килеп кергәндә. Президиум председателе салмак кына итеп сөйли иде.

— Шулай, иптәшләр. Сибгатулла абзыйны кичә бик нык җәберләгәнбез без. Эшне үзе килгәнче төзәтеп куярга кирәк. Бәлки, үзе ул авырып ята торгандыр. Аннан да дастуйный кешене каян табасың.

— Шулай! Шулай! Аннан да дастуйный кеше юк инде, — диделәр бүлмәдә утыручылар.

— Яныбызда утыра торып, кичә ничек оныткан быз соң без аны? — дип куйды президиум членнарыннан берсе.

— Йә, тавышка куябыз алайса: кем дә кем Сибгатулла абзыйны атаклылар съездына сайлыйк, ди, шулар кулларын күтәрәләр...

Бөтен бүлмә бердән кул күтәрде.

Ул ара да булмады, президиум председателе сикереп төште дә, Сибгатулланы урамга җитәкләп алып чыгып та китте.

— Менә Совнаркомнан килгән машина. Шуңа утыр да съездга бар һәм туп-туры президиумга кереп утыр. Анда сине президиумга сайлаганнар, — диде ул, Сибгатулланы ялтырап торган өр-яңа машинага утыртып.

— Әһә, курыктыгызмыни? — дип уйлады Сибгатулла Совнарком машинасына утырып барганда. — Димәк, әле дә үзегез сизенмәгәнсез. Димәк, Совнаркомнан әйткәч кенә кабалана башлагансыз. Эх, сез, эшләпәләр!..

* * *

Сибгатулла залга барып кергәндә, съезд инде ачылган һәм анда котлаулар бара иде. Аның барып керүе булды, залда:

— Сибгат килде! Сибгатуллин килде! — дигән тавышлар яңгырады. Бөтен зал артка таба борылды һәм, Сибгатуллага карап, кул чаба башлады. Оркестр ниндидер бик җиңел көй уйнап җибәрде.

— Сибгатнең иң яраткан көе «Әйттер, җаный!»... — диде залда утырган билгесез бер ханым.

Ул арада Сибгатулланы җитәкләп президиумга алып менеп утырттылар. Алдына чәчәкләр китереп куйдылар. Залда тагын кул чапкан һәм «ура!» кычкырган тавышлар яңгырады.

Делегатлар арасыннан берсе:

— Сибгатулла иптәш берәр сүз әйтсен! — дип кычкырды.

— Әйтсен, әйтсен! — диде бөтен зал, аның тәкъдименә кушылып.

Залның көчле алкышлары астында Сибгатулла трибунага чыгып басты.

— Агай-энеләр! Кардәшләрем! — диде ул залга карап.

— Җаныйларым! — дип өстәп куйды ул, бераз уйлап торгач.

Шунда ук кинәт башы әйләнеп киткәндәй булып, башын тотып, уйланып торды.

Аның уйланып торуы озакка китте бугай, президиум членнарыннан иң кырыйда утырган берсе аның кабыргасына төртте:

— Тизрәк бул. Сәгать җиденче булып килә бит инде!..

Сибгатулла, кулын башыннан алып, аптырап аңа карады.

— Нинди җиденче?

Президиум члены тагын аның кабыргасына төртте:

— Нинди җиденче булсын? Иртәнге җиденче! Әйдә, тор да, тизрәк ашап, әртиленә чап! Соңга каласың...

Сибгатулла күзен ачыбрак караса, аңа төртүче президиум члены түгел, бәлки хатыны Рабига иде.

Сибгатулла башын мендәрдән күтәрмәкче булды. Ләкин күтәрә алмады. Шундый авырта! Шундый авыр! Әйтерсең эченә кургашын тутырганнар!

— Эшкә бармыйм, — диде ул, коры гына итеп.

Рабига еларга ук тотынды:

— И Ходаем! Көне-төне эчеп йөри дә, аннары «башым авырта» дип ыңгырашып ята. Исерекбаш!

*1934*

## «ЧАЯН» ТЕЛЕВИЗОРЫ

Яңа ел җитү уңае белән без телевизорыбызда кайбер капиталистик илләрнең бу яңа елны ничек һәм нииндирәк шартларда каршы алуларын күрсәтергә булдык.

Экранда — Көнбатыш Европа.

Зур бер зал. Залдагы өстәлләр тирәсендә кайсы гражданский кием, кайсы эсэсчылар формасы кигән исерекләр утыра. Президиум өстәленә төрле закускалар һәм аракы шешәләре тезелгән. Өстәл артында нәкъ Гитлер заманындагыча полный формага киенгән эсэсчы генераллар утыра. Аларның да йөзләре һәм күзләре нәкъ залдагы исерекләрнеке кебек кып-кызыл. Залдагылар да, президиумдагылар да йодрыклары белән өстәлләрне төя-төя, итек үкчәләре белән идәнгә тибә-тибә, ямьсез тавыш белән акырып җырлыйлар. Ара-тирә җырның: «Без ул француз дигәннәрен өчкә бөкләп ташларбыз!», «Без барабыз Англиягә, Англиягә походка!», «Германнардан өстен раса бөтен Җир шарында юк!», «Үч алырга, үч алырга!» — дигән аерым сүзләре генә ишетелеп китә.

Залның бер башында урындыкка менеп баскан бер генерал кызып-кызып речь сөйли. Акыру-бакыру, дөбердәү-шатырдау тавышлары арасында аның карлыгып чыккан сүзләре ишетелә: «Безнең Почта күгәрченнәрен сөючеләр җәмгыятен тыярга кемнең хакы бар?.. Ы-э... Аденауэр безнең яклы!.. Полиция безнең яклы!.. Эре промышленниклар безнең яклы!.. Янкилар безнең яклы!.. Ы-э... Көнчыгышка поход!.. Көнбатышка поход!.. Африкага!.. Австрал... Ы-э...»

Исерек генерал речен бетерергә өлгерми, зал ишекләре кинәт ачылып китә дә демонстрацияче эшчеләр килеп керәләр. Аларның кулларындагы плакатларда «Бөтен дөньяда тынычлык өчен!», «Бетсен Гитлер калдыклары!» дигән сүзләр ялкынлана. Дәһшәтле бу ташкынны күреп, залдагылар агарынып китәләр һәм беркадәр вакытка катып калалар. Ләкин бу күренеш озакка бармый, демонстрантлар: «Ах, сез, кабер казучылар! Ах, сез, Освенцим козгыннары! Бетсен үтерүчеләр!» — дигән тавышлар белән аларның өсләренә ташланалар һәм кайсын тәрәзәләргә, кайсын ишекләргә өстери башлыйлар. Зал берничә минут эчендә бушап кала.

Ишекләр тагын ачылып китә һәм кулларына резин таяклар белән газ бомбалары тоткан, ашыгып чабудан тыннары кысылган полицейскийлар атылып керәләр. Ләкин соң инде — зал буп-буш!..

Без телевизорыбызның объективын Германия Федераль республикасының Изерлон шәһәрендәге иң зур заллардан берсе булган «Александрхее»дан Кече Азия ярымутравына күчерәбез.

Экранда — зур шәһәрнең үзәк урамнарыннан берсе. Анда европача киенгән кешеләр дә, көнчыгышча чуар итеп киенгән кешеләр дә, ялан тәнгә ниндидер сәләмәләр ябынган яланаяклы кешеләр дә туктаусыз агылып тора. Әнә урамның кибетләр, рестораннар һәм кафелар тезелеп киткән ягыннан европача итеп бик фырт киенгән бер әфәнде үтеп бара. Узучылар аңа сокланып карап: «Депутат Шөкри әфәнде. Муниципалитет утырышына китте», — дип пышылдашып калалар. Менә ул «Миссури» дигән зур вывескалы ресторан турыннан узып бара. Әнә ишектән хәрби формадагы дүрт янки килеп чыга. Янкилар, бик нык төшергән булсалар кирәк, аякларында чак басып торалар. Әнә аларның берсе, алпан-тилпән килгән арада, европача киенгән әфәндегә килеп бәрелә. Әфәнде бик нык ачуланып артына борыла һәм... кинәт елмаеп, баш ия-ия чигенә башлый. Тик ул ерак китәргә өлгерми, янкиларның икенчесе аның якасыннан эләктереп ала да бәйләнә башлый.

— Стоп! — ди ул, чәйнәп барган резинкасын әфәнденең битенә төкереп. — Беләсеңме син, хайван, кемгә бәрелгәнеңне? Нигә гафу үтенмисең?

Әфәнде елмаюында дәвам итә:

— Әвәт, әфәндем! Әфү үденерез! Әфү үденерез!..

— Менә шулай! — ди янкиларның өченчесе һәм бик оста боксерча, җилле генә итеп, әфәнденең корсагына төртеп ала. Әфәнде эчен тотып, елмаюлы караш белән гафу үтенүдә дәвам итә:

— Әфү үденерез! Әфү үденерез!..

Мәсьәлә ачык — бу соңгы вакытта АКШның ярым колониясенә әйләнгән Төркия икән...

Без объективны Ерак Көнчыгышка юнәлдерәбез.

Экранда — Көньяк Кореяның башкаласы Сеул шәһәрендә бик зиннәтле итеп бизәлгән ниндидер сарайның бер бүлмәсе. Бүлмәнең бер кырыендагы йомшак креслода Америка генералы утыра.

Аның каршында, идән уртасына куелган радиомикрофон алдында, кыйммәтле халат кигән, соргылт чәчләре коела башлаган, ыржайган сары тешле берәү басып тора.

— Башладык! — ди генерал, ыржаючының халатына камчы белән сугып. — Мин әйткәннәрне кабатлый бар: «Без, намуслы кореялылар, коммунистлар белән бернинди килешүне дә танымыйбыз!» Кабатла!..

Халатлы аның сүзләрен кабатларга тотына:

— Башладык! Мин әйткәннәрне кабатлый бар: «Без, намуслы кореялылар...»

— Тукта, болван!

Генерал, сикереп торып, халатлының аркасына берне сыптыра.

— Алары — минем сүз. Сиңа аларны әйтергә кирәкми. «Без, намуслы кореялылар...» дигән сүздән башлап әйт!

Халатлы, «тагын ялгышмасам ярар иде» дигәндәй, куркып кына кабатлый:

— Без, намуслы кореялылар, коммунистлар белән бернинди килешүне дә танымыйбыз!..

Генерал яңадан креслога утыра һәм репетицияне дәвам иттерә:

— Без Кореяның төньяк өлешен корал көче белән үзебезгә кушарга тиешбез!

Халатлы бу сүзләрне дә микрофонга карап акыра.

— Безнең бөек союзнигыбыз Америка безгә бу эштә ярдәм итәргә тиеш! — ди генерал.

Халатлы бу сүзләрне дә кабатлый.

— Дөрес лыгырдыйсың, болван! — ди генерал. — Менә һәрвакыт шулай кабатла!..

Халатлы дәртләнеп китә һәм, әтәчләнеп, микрофонга кычкыра:

— Дөрес лыгырдыйсың, болван! Менә һәрвакыт шулай кабатла!..

Генерал, ачуланып, тагын сикереп тора.

— Ах, болван! — ди ул.

«Болван» дигәне — Ли Сын Ман икән...

Шушы урында без телевизорыбызны ябып торабыз, чөнки генералның Ли Сын Манны ничек итеп «мунча кертүе» безнең өчен кызык түгел.

*1954*

# КИСКЕНЧАРА

— Юк, болай булмый! — диде һөнәр училищесының тулай торагында комендант булып эшләүче Борһанетдин Галләмов, эш өстәлендәге кәгазьләр өемен кулы белән читкә этәреп. — Бер ел түздем инде, артык бер минут та түзә алмыйм. Йә бүген үк бу йорттан чыгып качам, йә булмаса, берәр маҗара тудырып, теге бюрократны да, үземне дә бөтен халык алдында хур итәм!..

Аның күз алдына иң элек тулай торакның өлгеләре фанера кисәкләре белән томаланган, ә кайберләре, пыялалары булмаса да, көн яктысы төшсен өчен ачык калдырылган бердәнбер тәрәзәле, караңгы, озын коридоры килеп басты...

Өченче көн генә әле ул, көзге салкын җил уйнап торган шушы шыксыз туннель буйлап кашпана-кашпана барганда, черегән сайгакка басып, аягы астында кинәт җир убылган шикелле, нindидер төпсезлеккә убылып егылган һәм тубыгын каймыктырган иде.

Тубык каймыктыру — анысы, әлбәттә, бик зур бәла түгел. Каймыгыр да бетәр. Шуның өстенә, егылган вакытта да, соңыннан үз бүлмәсенә кергәч тә, ул авырту сизмәде. Авырту берничә сәгатьтән, уку бинасына барырга чыкмакчы булып, идәнгә баскач кына сизелә башлады. Ләкин аның йөрәген иң әрнеткән нәрсә — бу авырту түгел, бәлки, үзенең озын гәүдәсе белән лап итеп идәнгә барып төшкәч, гөнаһ шомлыгына каршы, шул караңгы коридорда булган бер төркем укучы малайларның бөтен коридорны яңгыратып, шаркылдап көлеп җибәрүләре һәм кайсыдыр явызының юан тавыш белән:

— Комендант абый үзе ич бу! Бик шәп булды. Хәзер безнең хәлне аңлар инде! — дип кычкыруы булды.

— Кайсы юньсезе ул анда? Авызыгызны ерып торганчы, шырпы сызыгыз! — дип кычкырды комендант, сайгак черекләре арасына кысылган аягын тарта-тарта.

— Шырпы кирәкми, хәзер Васьканы чыгарабыз! Бая гына ул шул җирдә егылып, маңгаена бик зур фонарь чыгарган иде. Шуның белән яктыртыр! — диде теге юан тавыш.

— Нәрсәгә Васька? Бер-ике минуттан үз маңгаеңда да менә дигән фонарь кабына ич аның! — диде нечкә генә икенче бер тавыш.

Монысы инде барлык чикләрдән ашып китә иде.

— Менә бит ул — балаларны нинди хәлгә китереп җиткердек! Үзәкләренә үтмәсә, олылар алдында болай оятсызланмаслар иде алар... — дип уйлап алды комендант һәм, кесәсендә шырпысы барлыгы исенә төшеп, кесәләрен капшый башлады. Шунда ул чалбар кесәсеннән бер кап шырпы табып алды да, каударлана-каударлана, шырпының күкертсез башы белән капка ышкый башлады. Шул вакыт аңа шалт-шолт итеп ишекләр ябылганы ишетелде. Шырпы кабынганда, коридорда бер генә җан иясе дә калмаган иде инде.

— Болай булмый! Берәр кискен чара күрергә кирәк! — дигән карарга ул нәкъ менә шул вакытта килгән иде.

Бу кискен чараның нинди булырга тиешлеге турында ул өч көн һәм өч төн уйланды.

Әллә тулай торактагы тәрбиячененң барлык таләшләрен бергә туплап, директорга соңгы тапкыр докладной язып карарга мы? Әлләмондый шартларда артык эшли алмавымны белдереп һәм үземне эштән азат итүен сорап, тагын бер гариза язып карарга мы?..

— Юк! — диде ул, кискен генә итеп. — Докладнойларны һәм гаризаларны бер ел буе яздым инде. Пычагым да файдасы булмады. Аңа карап, янган лампочкалар да алыштырылмады, тәрәзәләргә пыялалар да куелмады. Мичләргә дә ремонт ясалмады.

— Юк! — диде ул бераздан, тагын да кискенрәк итеп. — Управлениегә барып йөрмим. Моңа кадәр йөргәнем өчен дә выговор гына алдым. Нинди дә булса башка берәр чара күрергә кирәк...

Ул, башын кулы белән тотып, терсәкләре белән өстәлгә таянды да күзләрен йомды.

Аның күз алдына тагын тулай торактагы барлык җитешсезлекләр: бүлмәләрдәге бөгелеп һәм сыгылып беткән тимер караватлар, алар өстенә ябылган пычрак җәймәләр һәм одеяллар, аяклары имгәнеп беткән урындыклар, ел буена адәм тавышы да чыгармаган радиорепродукторлар, плитасы җимерелгән кер юу урыны, юыну бүлмәсендәге ватык краннар һәм башка коточкыч күренешләр килеп басты.

Аның колак төбендә җыештыручы Поля түтинең череләдәвек тавышы ишетелгәндәй булды:

— Бер-ике кило гына сабын табыш бирсәң, шул җәймәләрне өемә алып кайтып, үзем юып китерер идем...

— Юк бит, Поля түти! — диде ул, сизмәстән артындагы бушлыкка борылып. — Бер тиен акча бирми бит теге хәерсез!..

Аннары аның икенче колак төбендә тулай торакның тәрбиячесе Зинаида Ивановнаның шелтәле тавышы яңгырады:

— Комендант түгел, балан бәлеше син!..

— Менә үзең минем урында эшләп кара, — диде Галләмов, икенче ягындагы бушлыкка борылып. — Үзең күреп торасың — бер ел азап чигәм бит инде! Бернинди средство бирми бит. Үз квартирасын гына кайгырта ул. Күр, әнә, училище исәбенә нинди шәп обстановка булдырды үз квартирасында! Бу турыда управлениегә үзең дә яздың бит инде. Барыбер мәгънәсе чыкмады. Комиссия килде дә акт төзеп кайтып китте. Барысы да үз кешеләре. Ә син балан бәлеше дә балан бәлеше, дисең! Комиссия хәтле комиссия...

«Комиссия» дигән сүзне әйтүгә, кинәт ул гомер буе эзләгән иң кирәкле нәрсәсен тапкан шикелле, шалт итеп маңгаена сукты да, өч аяклы креслосыннан торып, бүлмә буенча йөрергә тотынды.

— Тукта, тукта... — диде ул, кинәт идән уртасында тукталып. — Комиссия?.. Бик шәп идея бит бу!.. Шулай, шулай... Управлениенең яңа секретаренең фамилиясе ничек әле?.. Чәнчелеп киткере, самый кирәк чакта истән чыга бит!.. Шулай, дөрес! Курчатов!.. Булды!.. Унбиш тиен акча — һәм эшең бетте! Эх, бер биетим әле үзен! Яле, иптәш Җамалиев, биеп карагыз әле. Ә мин, читтән генә карап, кул чабып торыйм!

Галләмов тиз генә вешалка янына барды, кесәсендәге вак акчалар арасыннан унбишәр тиенлек көмеш эзләргә тотынды.

— Өчәү! — диде ул шатланып һәм, шул өч унбиш тиенлекне учына йомарлап, пальтосын да киеп тормыйча, бүлмәсеннән чыгып китте.

Торактан чыккач та ул, ниндидер шикле эшкә барырга җыенган кешедәй, тиз генә як-ягына каранып алды һәм туп-туры чаттагы гастроном кибетенә юнәлде.

— Андагы автомат бик шәп эшли, — дип уйлады ул юлда барышлый, һаман да як-ягына карана-карана. — Директор гына үз кабинетында булсын инде...

Менә ул кибеттә. Менә ул автомат-телефон будкасында. Менә ул номер җыя. Үзе каушамаска тырыша.

— Зарар юк, — ди ул эченнән генә. — Җамалиев үзе дә русчаны бик шәп белми. Минем русчаны бозып сөйләгәнне аера алмас әле. Курчатов та яңа кеше — тавышыбызны да аера алмас. Телемне бераз алгарак куеп сөйләрмен. Ятрак тавыш чыкса ярар шунда...

Менә телефон трубкасыннан таныш тавыш ишетелде:

— Директор Замалиев вас с-слушает...

Галләмов будка ишеген тагын бер тапкыр тартып куйды да, каушамаска тырышып, русча сөйләргә тотынды:

— Исәнмесез, иптәш Замалиев! Сезне управление секретаре борчый. Әйе, Курчатов. Дөрес әйтәсез — яңарак кеше. Сезнең янда кем дә юкмы анда? Әйе, телефон аша әйтә торган йомыш түгел. Бик ашыгыч булганга күрә генә телефоннан файдаланырга булдым. Начальник сезне кисәтеп куярга кушты. Сезнең анда, тулай торакта, тәртипсезлекләр бик күп икән. Анысын, иптәш Замалиев, мин белмим. Барып караганым юк. Мин кушканны гына җиткерәм. Сезнең өстән үзәккә жалоба җибәргәннәр булса кирәк. Дүртбиш көннән махсус комиссия киләчәк. Әйе, әйе, тулай торакларны тикшерергә. Тәртипкә китерәсе нәрсәләрегез булса, тәртипкә китереп куегыз. Ишетегез аны: сезнең өчен начальство кызарырлык булмасын! Ә комиссия турында, начальник әйтте, беркемгә бернәрсә шашылдамасын, диде. Менә шул. Приказны үтәгез һәм доложить итеп тормагыз. Бетте. Хушыгыз!..

Соңгы сүзләрне әйткәндә, Курчатов — Галләмов тәмам кара тиргә баткан иде.

— Ярар, карап карыйк, нишләрсең икән хәзер, иптәш Җамалиев, — диде ул кибеттән чыкканда, Курчатов булып сөйләшкәндәгечә, телен бераз алгарак куеп һәм шунлыктан бераз сакаулана төшеп.

Тулай торак ишеге төбендә аны Поля түти каршы алды:

— Иптәш Галләмов! Әле генә директордан кеше килде. Директор әйткән, кайтуы белән комендант минем янга килсен, дигән. Менә шул!..

— Киттем! — диде Галләмов, торакка да керәп тормыйча һәм Поля түтигә мәгънәле итеп күз кысып.

Поля түти аның артыннан гаҗәпләнеп карап калды.

— Әллә гаризасын канәгатьләндереп, урыныннан чыгаралар инде? Юкса нигә шулкадәр шатлансын иде... — дип уйлады ул һәм, күңелсез генә итеп, шактый кычкырып әйтеп куйды:

— Әйбәт кеше иде, мескен. Юл гына бирмәделәр үзенә...

* * *

Бер атнадан училищеның тулай торагы танымаслык дәрәҗәдә төзекләндерелгән, җиһазландырылган, чистартылган һәм, комендант Галләмовның канәгать йөзе шикелле, ялт итеп балкып тора иде.

*1957*

# СӘЕР ВАКЫЙГА

(*Хикәя*)

Сәлимовны гаҗәпкә калдырган беренче нәрсә — начальникның кабинеты алдындагы бүлмәдә көтеп утыручыларның гадәттән тыш азлыгы булды.

— Әллә мин ялгыш килдемме? Иптәш Саттаровның прием көне түгел мәллә бүген? — дип уйлады ул, түргә узаргамы, юкмы икәнлеген хәл итә алмыйча, ишек төбендә тукталып.

Аның күзе кабинет ишеге төбендәге урындыкларда үзара шыпырт кына нидер сөйләшеп утырган шат кыяфәтле өч гражданинга төште. Бүлмәнең стеналары буйлап тезелеп киткән утызлап урындык бөтенләй буш иде.

— Бернәрсә дә аңламыйм, — диде ул эченнән генә, ишек төбендә басып торган килеш.

Башка вакытларны бит, прием барганда, бүлмә эче алҗыган кыяфәтле ирләр һәм хатын-кызлар белән шыгрым тулы була иде. Приемга чират җиткәнне көтеп утыручыларның кайберләре, терсәкләрен тезләренә куеп, башларын түбән иеп, арыган гәүдәләрен ял иттерәләр, кайберләре, урындык аркасына сөялеп, башларын стенага терәгән хәлдә йокымсырыйлар, ә кайберләре хәтта утырган җирләреннән хырлап та куялар иде. Кайвакытларны бүлмәдә басып торырга да урын булмый иде. Сәлимовның үзенең дә берничә тапкыр инде кабул ителүчеләр исемлегенә язылганнан соң, бүлмәдә урын булмау сәбәпле, коридорга чыгып, стенага терәлеп торганы бар.

— Әллә бик иртә килдемме? — дип уйлады ул, стенадагы зур түгәрәк сәгатькә карап. Юк, иртә килмәгән. Сәгать нәкъ ун тулып тора. Димәк, прием башлануга бер сәгать кенә узган әле.

Ул кабинет ишеге төбендәге өстәл артында нәрсәдер язып утыручы секретарь кызга кыюсызлык белән генә карап, «Иптәш Саттаров бүген кабул итәме?» — дип сорау өчен авызын ачмакчы гына булган иде, кинәт кабинет ишегеннән, башын ия-ия, «Яхшы. Рәхмәт! Рәхмәт!» дип чыгып килүче юан гына бер ханымның арты күренде. Секретарь кыз, алдындагы кәгазьдән башын күтәреп, ишек төбендә утыручыларга карады.

— Кайсыгыз унтугызынчы? Керегез! Сәлимовның гаҗәпләнүе тагын да көчәйде.

— Ничек? Бер сәгать эчендә унсигез кешене кабул итеп өлгергәнме? Моңарчы бит ул прием сәгатьләрендә уннан артык кешене үткәрә алмый иде. Нәрсә булган соң монда? Әллә начальникны алыштырганнармы? — дип уйлап, ул секретарь кыз янына юнәлде. Бу вакытта инде юан ханым, кабинеттан чыгып, күзләрен кулындагы кәгазьгә текәгән хәлдә, бүлмәдән чыгып бара, ә ишек төбендә утырган гражданнарның берсе, галстугын рәтли-рәтли, кабинет ишегеннән кереп бара иде.

— Исемлеккә язылырга мөмкинме? — диде Сәлимов, секретарь кызга инсаф белән генә мөрәҗәгать итеп.

— Язып тормыйм, иптәш Сәлимов. Кеше болай да күп түгел. Утырыгыз.

Сәлимов, җилкәсен гаҗәпләнү белән җыерып, өченче кеше булып урындыкка барып утырганда, бая кереп киткән галстуклы кешенең кабинет ишегендәге тотканы эчтән тоткан килеш, «Юк, юк. Артыгы кирәкми. Хушыгыз!» дигән тавышы ишетелә иде инде.

— Һичшиксез, начальникны алыштырганнар! — дип уйлады Сәлимов, приемның болай тиз баруын күреп.

— Күптән вакыт иде инде ул бюрократны алып ташларга. Кешене санга сала торган нәрсәмени ул. Аңа кеше ни, бүкән ни, барыбер бит! — дип уйлады ул, кулындагы гаризасын тагын бер кабат караштырып.

— Безнең начальникны алыштырганнар мәллә? — дип сорау өчен, ул күршесенә борылган гына иде, кинәт секретарь өстәлендәге телефон шалтырады. Кыз трубканы алды.

— Тоташтыра алмыйм, иптәш Протасов, — диде ул трубкага, йомшак кына итеп. — Прием вакытында ул телефон буенча беркем белән дә сөйләшми. Юк, булмый, иптәш Протасов. Министр кушуы белән булса да тоташтыра алмыйм. Аның прием вакытларын ул үзе раслады бит. Алай бик ашыгыч булса, Николай Иванычка, урынбасарына шалтыратыгыз. Әйе, ул үзендә...

— Мәсьәлә ачык! — диде Сәлимов, секретарь кызның әнис алма кебек матур булып кызарган йөзенә канәгатьләнү белән

карап. — Саттаров стиле түгел бу. Һичшиксез, яңа начальник эшне шулай куйган. Ләкин кем икән соң ул яңа начальник? «Красный металлист» заводының директорын һәр җыелышта үтереп мактыйлар иде. Әллә шуны күтәргәннәрме Саттаров урынына?..

Шомарту станогына кую өчен үзе уйлап чыгарган җайланманың чертежларын сызу белән мавыгып, үзенең бүлмәсендә көне-төне утыра торгач, үзләренең идарәсендә булган шундый зур үзгәрешне сизми калуы өчен ул үзен шелтәләргә кереште:

— Тормыштан аерылган, дип, кайвакыт бик урынлы тәнкыйтьлиләр шул безнең конструктор халкын. Үз кабыгыбызга бикләнеп яшибез шул. Җәмәгать тормышы белән аз кызыксынабыз...

* * *

Аның бу уйларын секретарьның «Иптәш Сәлимов, керегез!» дигән тавышы бүлдерде. Ул тиз генә урындыктан торды һәм, күршеләренең приемга инде кереп чыкканнарын да сизми калуына гаҗәпләнеп, кабинетка кереп китте. Ләкин ул, кабинетка килеп керүгә, башына кемдер нindидер йомшак, әмма бик авыр нәрсә белән китереп суккан һәм шуңардан миңгерәп киткән кеше шикелле булып, баскан урынында катып калды.

Кабинет түрендәге яшел сукно җәелгән өстәлнең артында, ул көткән яңа начальник түгел, ә бәлки идарәнең элекке начальнигы утыра иде. Сәлимов, көтеп тору бүлмәсенә кергән вакыттагыга караганда да зуррак гаҗәпләнү белән басып торганда, аңа Саттаровның ягымлы баритоны ишетелде:

— Узыгыз, иптәш Сәлимов!

Сәлимов, «Күземә ялгыш күренмиме?» дигәндәй, күзләрен берничә тапкыр бик нык йомып һәм ачып алды да, каршында утырган кешенең чынлап та элекке начальник Саттаров икәнлегенә ышанып, аның өстәле янындагы урындыкка барып утырды һәм кулындагы гаризасын аңа сузды.

— Һаман шул, теге җайланма турында инде, — диде ул, үзе-

нең күңеле кайтуын сиздермәскә тырышып. — Өч айдан артык йөрим бит инде, иптәш Саттаров...

— Беләм, беләм, — диде начальник, аның гаризасына күз йөртеп. — Мин сезнең чертежыгызны узган атнада ук карап чыктым. Миңа бик ошады. Зур экономия китерә торган кыю тәкъдим. Мин аны үзебезнең конструкторлар бюросына да җибәрдем. Аннан да яхшы отзыв белән кайтардылар. Шулай ук, үзәк конструкторлар бюросында да яхшы бәя бирделәр. Хәзер ул «Красный металлист»-ның эксперименталь цехында. Менә алардан килгән җавап!

Ул Сәлимовка, юка гына бер папкадан алып, машинкада сугылган бер кәгазь тоттырды.

— Үзегез укып карагыз әнә: сезнең эшегезне алар өч көн эчендә әйләндереп чыгарырга сүз бирәләр. Мәсьәлә белән министр да таныш. Яшерми генә әйткәндә, сезнең тәкъдимне коллегиядә яклауны ул үз өстенә алды.

— Ләкин, — диде ул, кәгазьне Сәлимовның кулыннан кире алгач, — сезнең бу гаризада язган кайбер кискенрәк сүзләрегез миңа бераз урынсызрак күренә. Күрәсез, эш сез уйлаганча ук акрын бармый бит...

— Мин бит, — диде Сәлимов, кинәт уңайсызлана төшеп һәм андый кискен сүзләрне кулланырга үзенең мәҗбүр булганлыгын аңлатырга теләп. — Мин бит өч ай йөрим инде аның артыннан. Ахыр чиктә бит, иптәш Саттаров...

— Юк, юк, — диде начальник, аның сүзен бүлдереп һәм бик ягымлы елмаеп. — Мин сезне һич тә гаепләргә теләмим. Моңа сез түгел, бәлки безнең идарә аппаратында моңарчы яшәп килгән волокита һәм бюрократизм гаепле. Ягъни, без үзебез гаепле. Ярар, анысы калып торсын. Сез өч көннән тагын әйләнегез. Мин сезгә вәгъдә бирәм: сезнең бу җайланмагыз шушы ай эчендә үк тормышка ашырылачак!

Шул сүзләрне әйтеп, ул урыныннан бераз күтәрелә төште һәм өстәл аша конструкторга кулын сузды.

— Менә шул, иптәш Сәлимов. Бүген безнең егерме өче бит әле. Димәк, сез егерме алтысында минем янга килегез. Без шунда бергәләп министр янына керербез...

* * *

— Шулай да бернәрсә дә аңламыйм, — диде Сәлимов, заводка кайтып барганда. — Моңарчы бөтенләй мондый түгел иде бит ул! Янына керә алмый өчәр көн йөри идең. Янына кергәч тә, сиңа күтәрелеп тә карамыйча, яртышар сәгать буена ниндидер кәгазьләр актарып утыра иде. Әйтерсең бүлмәдә ул берүзе генә! Аннан, телефон трубкасын алып, кемгәдер шалтырата, аның белән озаклап сөйләшә иде. Ә кыяфәте — дөнья күләмендәге әллә нинди зур эшне хәл итүче кешенеке төсле була иде. Инде, шул эшләреннән бушап, синең йомышың турында сөйләшә башлаганда гына, кайсыдыр аның үзенә телефон шалтырата, алар трубкадан бер-берсенә акырыша-акырыша, тагын дөнья күләмендә әһәмиятле ниндидер зур мәсьәләне хәл итәргә керешәләр иде. Ул арада, өстәлдәге кырыклап кнопканың берничәсенә берьюлы басып, биш-алты сотрудникгын янына чакырып ала, алар белән чын-чынлап киңәшмә үткәрә башлый, кайсын тирги, кайсын сүгә, бик эре генә кыяфәт белән җаваплы күрсәтмәләр бирә иде. Ә син, бүкән шикелле, шуның барысын да карап һәм тыңлап утыра идең. Инде, ниһаять, моннан да бушап, синең йомышың турында үз фикерен әйтә башлаганда гына, «Иптәш начальник, кул гына куеп бирегез әле!» — дип, ниндидер кәгазь тотып, берәр сотрудникгы килеп керә, ул аны укый, тагын кемгәдер шалтырата, тагын кемнедер чакырта, кайвакыт үзе дә каядыр чыгып керә иде. Инде, моннан да котылып, тагын синең белән сөйләшергә башлагач кына, тагын телефон шалтырый, ул тагын трубканы ала, озак кына сөйләшә һәм, трубканы ачу белән шалт! итеп кире куеп, сикереп тора һәм зарлана-зарлана киенергә тотына иде:

— Шайтан алгырлары! Бер генә дә тынычлап эшләргә ирек бирмиләр! Сез, иптәш Сәлимов, гафу итегез инде. Тагын министр үз янына чакыра. Сез иртәгә килегез инде. Мин секретарьга әйтеп куярмын, ул сезне чиратсыз гына кертер. Мәсьәләне шунда окончательно хәл итәрбез...

— Барлы-юклы бер атна вакыт эчендә тәмам алыштырган шикелле булган бит, — дип уйлады Сәлимов, заводка кайтып, үзләренең конструкторлар бюросына кергәч һәм үзенең өстәле янына барып утыргач.

Бюрода утыручы иптәшләре аның борчулы йөзенә гаҗәпсенеп карап алдылар да үз эшләренә тотындылар. Сәлимов, ике кулы белән башын тотып, терсәкләре белән өстәлгә таянды да тагын уйларга тотынды:

— Приемын гына түгел, бөтен эш стилен үзгәрткән бит! Өч ай буена хәрәкәтсез яткан тәкъдимне бер атна эчендә нинди хәлгә китергән. Бөтенләй Саттаров дип уйларлык түгел. Нәрсә булган соң аңа?..

* * *

Хөрмәтле укучылар! Бәлки, сез дә: «Чынлап та, нәрсә булган соң ул Саттаровка?» — дип баш вата торгансыздыр. Шундый баш ватуга дучар иткәнем өчен гафу итегез инде сез мине. Ә мин сезгә шуны әйтим: Саттаровка берни дә булганы юк. Ул һаман элекке Саттаров һәм аның эш стиле дә һаман шул элекке. Ләкин хикмәт шунда: Сәлимов моны өнендә түгел, бәлки төшендә күрә иде.

Сез аны уята күрмәгез инде, иптәшләр! Йоклап бер ял итеп алсын. Юкса аның йокыдан торгач та Саттаров янына приемга барасы бар.

*1957*

## БАЛЫКЧЫ ГАЗАБЫ

Җамалый абзый кармакларының кайсына суалчан, кайсына бүрттергән солы, ә кайсына сурик кушылган һәм киндер мае белән тачкылган кызыл икмәк эләктереп, яр буена утырткан ике яшьле бәләкәй казыкларына кармак сапларын җилпәзә сыман итеп тезде дә, җилпәзәнең тирә-ягына мул гына итеп җим сибеп, калкавычларыннан күзен алмый гына, тәмәке кабызды һәм сөйләп китте:

— Өч ел! Әйтергә генә ансат ул, энекәш. Ел тәүлеге — унике ай дигәндәй, елына унике тапкыр, ә өч елга — утыз алты тапкыр бардым мин аның янына. Һәр айның беренче дүшәмбесендә, ягъни чираттагы прием көнендә, таң тишегеннән торып, аның приемный бүлмәсенә бара идем һәм, чират торып, янына керә идем. Ул миңа, күтәрелеп тә карамыйча, минем алдан гына приемда булган иптәшнең гаризасына нидер яза-яза, «Пожалысты, рәхим итегез!» дип, ияге белән ымлап, өстәл янындагы урындыкны күрсәтә иде. Мин, урындыкта утырып, аның җылы сүзен көтә идем. Ул теге иптәшнең гаризасын папкага салып куя да миңа карап: «Шулай, иптәш Җапаров! Сез исемлектә бар. Без сезне истә тотабыз. Беренче мөмкинлек булу белән фатир бирәчәкбез. Сез инде килеп борчылып йөрмәгез — бездә сезнең адресыгыз бар — үзебез хәбәр итәрбез...» — ди иде. Ләкин, аның шундый киңәшенә карамастан, мин һәр айның беренче дүшәмбесендә тагын аның янына приемга керә идем һәм, һәр керүемдә шул ук җавапны алып кайтып китә идем.

— Ачуланмый идеме соң үзегезне? — дип сорады аның янында басып һәм зур игътибар белән калкавычларны күзәтеп торган егет.

— Кем ачуланмый идеме?

— Горсовет председателен әйтәм.

— Ә нигә дип ачулансын ул? Ачуланырга аның бернинди сәбәбе юк. Аның бит прием көне. Кешеләр киләләр, чират торып, тәртип белән керәләр, ул аларны кабул итә, зарларын тыныч кына тыңлый, шулай ук тыныч кына җавап бирә — юата, өметләндерә, вәгъдә бирә һәм чыгарып җибәрә. Гомумән, аның кабул итүе үзе дә формальность өчен генә эшләнә бит. Дөресен

әйткәндә, минемчә, аның янына берәү дә әллә ни зур өмет белән керми иде...

— Алайса, һәр айны аның янына нигә дип барадыр идегез соң?

— Ә кая барасың?

Җамалый абзый, күзен бер генә секундка калкавычларыннан алып, егеткә күтәрелеп карады.

— Аңарчы минем булмаган җирем калмады инде, энекәш. Фабкомында да, райжилуправлениесендә дә, райисполкомында да — барысында да булдым. Шулай йөри-йөри шәһәр советына барып чыктым да инде мин. Ә фатир мәсьәләсендә, беләсең килсә, иң югары инстанция — шул шәһәр советы инде. Аннан башка барыр җир юк...

Ул папиросын берничә тапкыр еш-еш суырды, папирос мундштугы эченә мул гына итеп төкереген җибәрде — папиросның утлы башында «чыж-ж» иткән тавыш ишетелде — аны ул кармак саплары куелган казыклар арасына, күлгә атып бәрде дә сүзен дәвам иттерде:

— Шулай өч ел йөри торгач, беркөнне мине шәһәр советына чакырттылар. Син, энекәш, үзең фатир белән интеккән кеше булмагач, минем хәлне аңлый алмассың. Белсәң иде шунда минем ниләр кичергәнне! Үзем шәһәр советына барам, үземнең йөрәгем дөп-дөп кага. Неужели, мин әйтәм, миңа да иркенрәк бер фатир бирерләр икән, дим. Бит, үзең уйлап кара: коридорсыз, кухнясыз, уборныйсыз, уналты квадрат метрлы бер тишектә җиде җан тыгылып торабыз бит. Борылыр хәл юктыр, дисең син. Кая ул борылу — сулыш алыр хәл юк! Шунда — олы малаем, заводтан алып кайтып, чертежлар сыза, килен машина белән нидер тегә, кече малайлар дәрес хәзерлиләр, әни карчык намаз укый, хатын чыра телә, мин гәзит тотып утырам. Утырам, ләкин башыма чуртым да керми. Кечкенә генә бер хәбәрне җидешәр тапкыр укыйм. Бу малайларның, мескеннәрнең, дәресләре башларына ничек керә икән дип, аларны җәллим үзем...

Күзгә төсле тип-тигез су өстендә хәрәкәтсез тынып торган озын, нечкә бер калкавыч кинәт шып итеп су астына кереп китте һәм шунда ук калкып та чыкты. Җамалый абзый шул секундта ук сикереп торып, кармак сабына ябышты һәм тирәсенә чак кына күре-

нерлек бөҗралар ясаган калкавычка карап, аның тагын бер чумганын көтә башлады. Калкавыч тагын бер кыймылдагандай итте, аннары, чак кына сизелерлек итеп, тагын бер кыймылдады һәм тагын шыш иттереп, су астына кереп китте. Җамалый абзый кармак сабын, ничектер бер яккарак кыйшайта төшеп, кинәт югарыга таба күтәрде дә, шактый зур көч белән булса кирәк, тарта башлады. Камыш кармак сабының нечкә очы авырлыктан кәкрәеп бөгелде һәм дырылдарга тотынды. Менә су астыннан шулай ук дырылдыйдырылдый чыгып килә торган озын ак кылның уртарак бер җирендә баягы калкавыч күренде, аннан күп тә үтми, бер карыш зурлыгындагы, яшькелт-көмеш төсле, шактый киң гәүдәле, кәкрәеп килгән бер кызылканат атылып чыкты һәм, судан бер ярты метр чамасы күтәрелгәч, бер-ике җилпенде дә, кармактан ычкынып, шап! итеп суга барып төште. Су өстендә ул тагын бер тапкыр җилпенде дә, төпкә чумып, күздән юк та булды.

— Хәерле фал! — диде Җамалый абзый, кармакны яңадан кулына алып. — Болай булгач, чиртү башлануын көтәргә була. Бер чиртә башласа — чиртә инде ул. Ә менә үткән атнаны көне буе диярлек бер генә чиртеп тә карамады. Ә чиртмәгән балыкны ничек тотасың?..

Ул кармакка тагын кызыл җим утыртып, җайлы гына итеп, нәкъ элекке урынга салды һәм тагын калкавычларына текәлде.

— Нәрсәгә чакырганнар соң, дисеңме? — диде ул бераздан. — Шул, фатир мәсьәләсе буенча, Хәлиуллин үзе чакырган булып чыкты. Мин аның янына кердем. Ни өчен чакырттыгыз, иптәш Хәлиуллин, дим. Берәр очы күренә мәллә минем мәсьәләнең? «Очы гына түгел, койрыгы да күренә, иптәш Җапшаров, — ди ул миңа. — Хәзер үк квартбюрога төшегез дә Данилов белән барып карагыз. Сезгә Воропаев урамында салынган яңа йорттан ике бүлмәле бер фатир бирергә чамалыйбыз. Унөченче фатир булыр. Әгәр шуңа риза булсагыз, ордер бирербез». Әй, минем хәлне белсәң иде шул вакытта! Риза булмаган кая инде ул, иптәш Хәлиуллин, мин әйтәм. Карап та тормыйм. Бүген үк күчәм. Хәзер үк бирегез ордерны, иптәш Хәлиуллин, дим. «Ә сез ашыкмагыз, иптәш Җапшаров, — ди Хәлиуллин миңа. — Әле исполкомның карары юк. Утырыш иртәгә иртән була. Барып карагыз. Соңыннан сүзе булмасын.

Ордерга иртәгә обедтан соң килерсез...» Рәхмәтләр әйтә-әйтә чыгып киттем мин моның яныннан. Шунда ук квартбюрога төштем. Данилов белән бергә барып карадык. Ул бүлмәләре, дурррак! Ул коридоры, дурррак! Ул кухнясе, дурррак! Ул ваннасы, минсиңайтим! Ул җылы уборные!.. Фатир түгел, җәннәт!..

Кинәт тагын бер калкавыч суга чумып алды. Җамалый абзый тагын кармак сабына ябышты һәм калкавычның икенче тапкыр су астына кергәнен көтә башлады. Ләкин калкавыч кабат кыймылдамады.

— Ашап кына китте, ахрысы, хәерсез! — дип, Җамалый абзый кармакны судан алып карады. Суалчан исән-сау иде. Ул аны тагын күлгә салды һәм тагын калкавычка карап тора башлады.

— Икенче көнне бардың инде син тегенең янына...

— Бардым, ләкин фатирны миңа тоттырмадылар, — диде Җамалый абзый, күңелсез генә итеп. «Исполкомның утырышы булды, — диде Хәлиуллин. — Ләкин сезгә дигән фатирны бер аварийный йортта торучы кешегә бирергә туры килде. Ә сез борчылмагыз, без сезгә шундый ук икенче фатир бирербез. Бер өч-дүрт айга түзегез инде...» Мин башта ни әйтергә дә белмәдем. Зиһенем бөтенләй чуалып китте. Бу ничек була инде, иптәш Хәлиуллин, дип мыгырдандым гына мин. «Шулай булып чыкты инде, иптәш Җапшаров», — диде Хәлиуллин һәм, кул сәгатенә карап, урыныннан торды да ишеккә таба бара башлады. Мин, аңыма килеп, аның артыннан юнәлдем. Ул аварийный кешегә минем фатирны биреп булмыймыни соң, иптәш Хәлиуллин, — дидем мин аңа. — Бәлки, аның семьясы зур түгелдер. «О, юк, — диде Хәлиуллин ишектән чыкканда. — Андый кеше түгел ул. Җаваплы работник булып күтәрелгән кеше...» Мин, бер сүз дә әйтә алмый, аның артыннан баскыч буйлап төштем, урамга чыктым һәм машинага утырып киткәнен карап калдым...

— Шуннан соң нишләдең?

— Нишлисең? Карадым да калдым. Ә бераздан, аның җилдәй очып барган кара машинасына карап: «Алла сине балыкчылар газабы белән газапласын!» — дип каргадым...

Бераздан ул борын аша гына «һы!» дигән тавыш чыгарып көлеп куйды:

— Мин үзем болай Алла, каргыш дигән нәрсәләргә ышана торган кеше түгел. Ләкин шулай да чын күңелдән каргадым үзен. Җаным шундый әрнегән иде ул вакытта...

Җамалый абзый, тагын тәмәке алырга теләп булса кирәк, кулын кесәсенә тыккан иде, нәкъ шул вакытта җилпәзәнең сул кыены да моңарчы хәрәкәтсез торган йомры кызыл калкавыч кинәт суга кереп китте дә берәр карыш алдарак калкып та чыкты. Җамалый абзый, яшен тизлеге белән атылып, кармак сабына ябышуга, калкавыч калтыранып-калтыранып йөзә башлады һәм тагын су астына кереп чумды. Җамалый абзый кармак сабын кисәктән тартып җибәрде һәм, ялтырап торган ниндидер балыкны тартып чыгарып, арттагы куаклар арасына атып бәрде. Бу — бик зур алабуга иде.

— Почти минем яшьтәш икән бу, — диде Җамалый абзый, алабуганың зур авызына ике бармагын тыгып, шактый тирән йотылган кармакны каера-каера. — Мондый зур алабуга безнең күлләрдә сирәк очрый ул, энекәш. Сугышка кадәр Кәкре күлдә шундый берсен тоткан идем мин. Шактый карт балык иде...

Ул шундый зур починыннан канәгатьләнү белән кулына алып сачокка салды, сачокны ишләп кенә күлгә батырды һәм, кармагына яңа суалчан куеп, баягы урынына ыргытты.

— Ә балыкчы газабы дигәнем — дөньяда кешеләр кичерә торган газапларның иң күңелсезе, иң аламасы һәм иң үкенечлесе ул, — диде ул, папиросын кабызып, резин итекләрен яңадан ярга салындырып утыргач. — Гомер буена бөтен күңелең белән көтелгән, эзләнгән, ниһаять, беркөнне табылган һәм тормышка тәмам ашам инде дигәндә генә кинәт өзелгән һәм мәңгегә синең кулыңнан ычкынган өмет ул. Шундый газапны мин моннан дүрт ел элек башымнан кичердем. Һәм мин аны әле дә оныта алмыйм... — Ул елны мин бөтен җәйне спиннинг белән үткәрдем, — диде ул, тәмәкесен бик тәмле итеп суырып. — Бу тирәдәге күлләрнең һәммәсен айкап чыктым. Затонда да булдым. Хәтта, ниндидер бер доцент Иделдән спиннинг белән дүрт килолы бер судак тотып кайткан икән, дигәч, Иделенә дә барып чыктым. Ләкин — аллә ни кыра алмадым — бер килолы, кило ярымлы биш-алты чуртан, егермеләп алабуга — җәй буена тоткан бөтен балыгым менә шул булды. Бер мин генә түгел, ул елны барлык балыкчылар зарландылар.

Ә спиннинг дигән нәрсә миңа гомумән ошамады. Беләк буе бер чуртан тотар өчен, көне буе күлне кыйнап йөрисең. Ә кай көннәрне кечкенә бер алабуга да эләкми. Кая инде ул кармак белән тотуга җитү!

Ул нечкә, озын калкавычлы кармагын тагын тартып чыгарды да, җимен алыштырып, тагын салып куйды.

— Юк, энекәш, газап дигәнем анысы түгел. Балык эләкмәү — аны тотарга тагын да зуррак теләк кенә уята ул. Аны, эләкмәгән саен, эләктерәсең генә килә һәм, «Менә эләкмәсме? Менә эләкмәсме?» дип, көн буе күлнең бер кырыеннан икенче кырыена, бер күлдән икенчесенә күчеп йөрисең. Ә самый газаплысы — эләккән балыкны, баягы шикелле кечкенә балыкны түгел, ә зур балыкны ычкындырганда була. Ә теге елны мин ычкындырган балык бер алты килолы булгандыр.

Ул минем отпускымның иң соңгы көнендә, сентябрьнең сигезенче числосында булды. Җитмәсә тагын, кичтән үк карчыкка: «Иртәгә мин биштәге поезд белән кайтып җитәрмен. Син, бер яртыны алып, кичкә баҗайларны чакырып куй», — дип, заказ да биреп киткән идем. Чөнки аннан элекке көнне генә настоящий жор башланган иде: бөтен спиннингчылар ул көнне зур-зур чуртаннар тоттылар. Мин дә кило ярымлы берсен эләктереп кайткан идем. Һәм, чынлап та, минем күлгә килеп җитүем һәм беренче мәртәбә ыргытуым булды, ярты килолы бер чуртанны тартып та чыгардым. Әнә теге куаклар тирәсендә генә. Ә берәр сәгатьтән, минем янда гына йөргән бер егет, кимендә өч килолы булыр — менә шундый бер чуртанны сөйрәп чыгарды. Шуннан соң мин: «Менә зурысы эләгә! Менә зурысы эләгә», — дип, көн буе күлне мәгънәсезгә кыйнап йөрдем. Нинди елтыргычларым булса, һәммәсен дә куеп карадым. Сәгатькә карый-карый: «Монысы актык ыргытуым! Монысы иң соңгы ыргытуым», — дип, бер йөз тапкыр ыргыткканмындыр. Ичмасам, кызык өчен бер балык кабып карасынчы! Шуннан соң соңгы өмет белән: «Монысы чыннан да иң соңгы ыргытуым», — дип, бер илле метр чамасы ераклыкка ыргытып, катушкамны чорный гына башлаган идем, менә берзаманны минем елтыргыч нәрсәгәдер бик каты бәрелгәндәй, бер тапкыр дырк! иттерде дә төртелеп калды һәм авыраеп китте. «Эләкте!» — дидем мин эчемнән генә

һәм катушкамны ашыга-ашыга чорный башладым. Ә күнеккән кул — елтыргычның үләнгәме, тамыргамы эләккәнен, яки зур балыкмы, кечкенә балыкмы эләккәнен шунда ук сизеп ала ул. Бу — һичшиксез, моңа кадәр миңа беркайчан да эләкмәгән бик зур балык иде. Мин аның су астында дулый-дулый тартышуыннан хәтта күләмен дә күз алдыма китердем. Шул вакытта минем урынымда үзе булмаган кеше минем анданиләр кичергәнемне һәм үземне ничек хис иткәнемне үлсә дә аңлый алмас. Кулым гына түгел, бөтен гәүдәм калтырана, йөрәгем күкрәктән чыгардай булып тибә, миннән ерак түгел басып торган балыкчылар миңа нидер кычкыралар — аларның кычкырганнары миңа «А-а! У-у! А-а!» дигән тоташ бер улау булып кына ишетелә. Ул арада судан балыкның коточкыч зур башы килеп чыкты һәм ул, киң итеп сулыш алган шикелле, шап-шап! иттереп, алап хәтле авызын бер ачып, бер ябып, ярга, камышлар арасына таба йөзә башлады. Минем күзем кинәт спиннинг сабына төште: ул дуга шикелле бөгелеп килгән иде. Мин аның сынып китеп бөтен эшне бозуыннан курка башладым. Шунда кинәт кулымның хәле китте һәм мин, бөтен көчемне җыеп, тегеләргә кычкырдым: «Иптәшләр! Көчем җитми! Булышыгыз!..» Алар чытырман баскан бормалы сукмактан, куаклар аша сикерә-сикерә, нидер кычкырып, минем янга йөгерә башладылар. Мин, актык көчемне җыеп, балыкны камыш арасына кертмәскә тырышып, катушкамны чорнавымда дәвам иттем. Бу вакытта инде ул ярга бер дүрт-биш метр гына калган иде һәм мин, аны өстерәп чыгарып, өстенә аварга җыена идем. Шунда минем балыгым, дию пәрие шикелле, бер дулады да, спиннингның кылы кинәт бушап китте һәм мин шап! итеп җиргә утырдым. Ул вакытта нинди хәлдә булганымны мин үзем дә белмим. Моны миңа соңыннан теге балыкчылар сөйләделәр. Минем төсем ап-ак булган, үзем: «Уф, ычкынды бит! Уф, ычкынды бит!» — дип, күкрәгемне тотып утырганмын. Хәтта аларның биргән суларын да эчә алмаганмын. Тешләрем шулкадәр нык шакылдаган. Соңыннан, шул балыкны күз алдыма китереп, өч ел азапландым. Кайчакны ул әле дә төшемә керә...

Менә, энекәш, нинди була ул балыкчы газабы! Андый газапны дусыңа түгел, дошманыңа күрергә язмасын. Дөресен әйткәндә, мин

әле дә булса гаҗәпләнәм: теге вакытта Хәлиуллинны шундый каргыш белән каргарга ничек телем барган икән, дим. Бу бит — «иң теләгән нәрсәң, инде булды дигәндә, булмый калсын» дигән сүз. «Иң зур өметең өзелсен» дигән сүз. Нинди генә җансыз бюрократ булмасын, ул да кеше бит. Хәлиуллинны әйтәм. Аның да әллә нинди өметләре бардыр, зур-зур теләкләре бардыр... Ләкин, нишләтәсең, каргаганмын шул. Ничә еллар буе өмет итеп йөргән һәм инде булды дигән фатирымны башка кешегә биргән өчен җаным бик нык рәнҗегән иде шул үзенә... Ә бу фатирны, дисеңме? Юк, аны Хәлиуллин бирмәде. Мин шуннан соң да ул бюрократка бер ел чамасы йөрдем. Бу фатирны минем олы малайга үзләренең заводларыннан бирделәр. Ул бит, үзең беләсең, заводта эшли...

*1957*

## ХУҖА НАСРЕТДИН ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

### Хуҗа корабта

Хуҗа Насретдин утырып барган кораб, штормга эләгеп, ярга чыга алмый озак вакытлар диңгездә йөри торгач, эчәргә яраклы тозсыз сулары бетеп, бөтен экипаж хәлсезләнеп калган. Шунда Хуҗа үзенең чемоданыннан калын гына бер китап чыгарган да аны югары күтәреп: «Җәмәгать! Котылдык! Мин йөзәргә чыкканда, таныш бер язучым миңа үзенең җыентыгын бүләк иткән иде. Шуны таптым. Бу җыентыктагы әсәрләрнең суы бик күп, ә тозы бер дә юк!» — дип кычкырган, ди.

### Хуҗа редакциядә

Хуҗа бер журнал редакциясенә барып керде. Редакциядәге барлык сотрудниклар телсез иде. Хуҗа, моңа бик гаҗәпләнеп, сәбәбен сорады. Сотрудниклар бер кәгазьгә язып: «Тел белгече булып танылган бер тәнкыйтьче безгә «Язучыларның тел осталыгын күтәрергә» дигән мәкалә язып китергән иде. Шуны укый-укый телләребезне сындырдык, телсез калдык», — дип аңлаттылар. Хуҗа аларга: «Әгәр дә күз белгече булып танылган шундый бер тәнкыйтьче «Язучыларның күзәтүчәнлеген күтәрергә» дигән мәкалә язып китерсә, зинһар, укый күрмәгез. Телсезлегегез өстенә сукыр да калырсыз», — дип чыгып китте.

### Хуҗа — тәнкыйтьче

Беркөнне Хуҗадан:

— Йә, Хуҗа! Син үзең танылган тәнкыйтьче. Нигә Гайнан Шәйхи дигән шагыйрь турында бернәрсә дә язмыйсың? — дип сорадылар, ди.

— Кит аннан? Гайнан Шәйхи үлдеме? Ай-яй-яй! — дип гаҗәпләнде ди Хуҗа.

Ул үлгән шагыйрьләр турында гына язарга ярый дип белә иде, ди.

## Хуҗа — балалар язучысы

Беркөнне Хуҗадан:

— Ник син балалар өчен язылган нәрсәләреңне үз улыңа гына укыйсың? Ник аларны балалар журналына бирмисең? — дип сорагач, Хуҗа:

— Анда бит зурлар утыралар. Минем язганнарымны, «балалар аңламый» дип кире кайтаралар. Лучше мин аларны үземнең өч яшьлек малаема укыйм: ул, ичмасам, аңлый да, ярата да! — дип җавап биргән, имеш.

## Хуҗа — композитор

Хуҗа беркөнне:

— Шагыйрьләр ялкаулыкның чигенә җиттеләр, җыр текстлары язмыйлар, ә без, композиторлар, текстсыз музыка яза алмыйбыз, — дип зарланган, ди.

— Ә нигә соң газет-журналларда һәм җыентыкларда чыккан шигырьләрне укып карамыйсыз? — дип сорагач, Хуҗа:

— Әйтәм ич, шагыйрьләр ялкаулыкның чигенә җиттеләр: текстларын безгә китереп, укып күрсәтергә иренәләр, — дип җавап биргән, ди.

## Хуҗа — прозаик

Хуҗа беркөнне:

— Нигә бу шагыйрьләр шигырь белән озын-озын романнар һәм повестьлар гына язалар? Нигә халыкка кыска поэмалар бирмиләр? — дип сорады, ди.

— Ә син үзен нигә кыска хикәяләр язмыйсың? — дип сорагач, Хуҗа:

— Минем яза башлаган кырык табаклы романым бар. Бер ун елдан шуны язып бетерсәм, кыска хикәяләр дә язармын, — дип җавап бирде, ди.

## Хуҗа һәм язучы

— Йә, Хуҗа, бик күп сөйлисең! Сүзең көмеш булса, тик торуың алтын булыр! — дип әйтте, ди, Хуҗага бер язучы.

Хуҗа моңа каршы:

— Алайса, син үзең һәм сезнең Союздагы язучыларның күбесе шулай тик торып дөнья хәтле алтын җыйгансыздыр инде! — дип җавап бирде, ди.

## Хуҗаның тәнкыйте

— Без яшь язучыларга игътибар итмиләр, газетлар безнең әсәрләрне басмыйлар, журналларга якын да китермиләр, нәшриятның ишеген дә ачмыйлар, — дип зарланды, ди, Хуҗа.

— Син үзең утыз ел инде яшь язучы булып йөрисең, ә менә басып чыгарырлык нинди әсәр язганың бар? — дип сорагач, Хуҗа:

— Бер авыз сүз әйтер хәл юк, хәзер тәнкыйтьне кыса башлыйсыз. Алайса, мин сөйләмим, — дип үпкәләп, трибунадан төшеп киткән, ди.

## Хуҗа һәм Хөрәсән ялкаулары

Хөрәсән шәһәрендә ике ялкау бар иде. Беркөнне шулар бер агач күләгәсендә ятканда, Хуҗа да алар янына килеп ятты.

Ялкаулардан берсе:

— Либретто, пеш, авызыма төш! — диде.

— Иренмичә ничек әйтәсең? — диде икенчесе.

— Бу хәтле такылдарга ничек телләре әйләнә? — дип уйлады Хуҗа эченнән генә. Ул үзе дә опера өчен либретто көтеп йөрүчеләрнең берсе иде.

## Хуҗа белән малае

Хуҗа үзенең ишегалдында кычкырта-кычкырта малаен кыйнап ятканда, узып баручылардан берсе:

— Йә, Хуҗа! Нигә шулхәтле кыйныйсың ул баланы? — дип сорагач, Хуҗа малайны кыйнавында дәвам итеп:

— Өченче сыйныфта укыган җиреннән укуын ташлады, әллә нинди бәетләр яза башлады, берәр редакциягә эшкә керәм дә шагыйрь булам, ди. Ничек кыйнамыйсың ул җүнсез малайны! — дип җавап бирде, ди.

## «ГӨЛСТАН»НАН

*(Иран - таҗик шагыйре Мөшрифетдин Сәгъдинең шул исемдәге әсәреннән өзекләр)*

### Хикәя

Бер дәрвиш үзенең остазына:

— Нишләргә инде миңа? Кешеләр бер дә тынычлык бирмиләр, көне буе яныма килеп торалар, изге эшләр белән шөгыльләнергә комачаулыйлар, — дип зарланган.

Остазы аңа болай дип җавап биргән:

— Әгәр дә ярлы кеше килсә, син аңа бурычка акча биреп тор. Ә инде бай кеше килсә, аның үзеннән бурычка акча сора. Шуннан соң яныңа килүдән туктарлар.

Торса иде ислам явының башында
Бер хәерче, каферләр явы шул чакны
Андый яуның хәер соравыннан куркып
Качар иде Кытай диварына чаклы!

### Хикәя

Акыл иясе бер карт ниндидер тәкәббер һәм тупас бер батырны күргән. Батырның ярсудан авызыннан күбекләр чыккан чак булган. Карт шундагы кешеләрдән:

— Бу батырга ни булды? — дип сораган.

Тегеләр:

— Аны берәү әшәке сүз белән сүккән иде, — дип җавап биргәннәр.

Карт:

— Менә дивана! Бер батман авырлыктагы герне күтәрү аңа берни түгел, ә ниндидер бер сүз әйткәннәр икән, шуны күтәрә алмый! — дигән.

Ахмак булсаң, мактанма кул көчең белән,
Ирлек дәгъва итмә, хатын булмасаң да.
Кулдан килсә, бал сал дусның авызына,
Авыз җимерү — ирлек түгел бу дөньяда.

* * *

Кулың белән фил авызын каерсаң да,
Кешелекле булмасаң, син ир булмассың.
Үз асылың туфрак кебек, тыйнак бул син —
Шунсыз җирдә кеше булып танылмассың!

## Хикәя

Минем ишетүемә караганда, бер акыл иясе:

— Берәү сүз сөйләгәндә, аның сөйләп бетергәнен көтмичә, үзе сөйли башлаган кешедән дә надан кеше дөньяда юк, — дигән.

Һәрбер сүзнең башы бар һәм ахыры бар.
Кеше сүзен һич бүлдермәс — акылы бар.
Кем белемле һәм акыллы саный үзен,
Бөтен кеше тынгач кына башлар сүзен.

## Хикәя

Йолдызларга карап багучылык итүче берәү, өенә кайтып кергәч, хатынының билгесез бер ир белән утырганын күргән. Шунда ул теге кешене тирги һәм әшәке сүзләр белән сүгә башлаган. Аларның арасында сугыш чыгып, тавышка халык җыелган. Бу вакыйганы күреп торган бер акыллы кеше болай дигән:

Йолдызларның ничек белсен ул серләрен,
Кайчан белми үз өенә кем кергәнен!

## Хикәя

Бер галимнән:

— Әгәр дә бер ир кеше бикле бүлмәдә айдай йөзле бер гүзәл белән ялгыз утырса, көндәшләр йоклаган, дәртләр кайнаган, теләкләр җиңүгә омтылган, кыскасы, гарәпләр әйткәнчә, «Хөрмә өлгергән, ә сакчы йоклаган» вакыт булса, ул ир кеше үзенең нәфесен тыю юлы белән шул гүзәлдән котыла алырмы? — дип сораганнар.

Бу сорауга галим:

— Ай йөзле гүзәлдән котыла алса да, усал телләрдән котыла алмас, — дип җавап биргән.

Котылсаң да коткысыннан нәфеснең могҗиза белән,
Өмет итмә — котылмассың кешеләрнең гайбәтеннән.

* * *

Үзеңнең кулда ансы, дус, нәфесне син тыярсың.
Кешеләрнең телен ләкин ничек бәйләп куярсың!

## Хикәя

Бер вәзирнең бик аңгыра улы булган. Вәзир аны бер галимгә биреп:

— Тәрбияләп кара әле, бәлки, акыл керер, — дигән.

Теге галим вәзирнең улын бик озак тәрбияләгән, ләкин бу тәрбия аңа тәэсир итмәгән. Шуннан соң галим баланың атасына кеше җибәреп: «Мине акылдан яздырды, ләкин үзенә акыл кермәде», — дип хәбәр иттергән.

Кабул итсә табигате кешенең,
Калачак тәрбия эзе аңарда,

Тимерне күпме ышкы, ялтырамас.
Шулай ук балкымас — рухы яман да.

Коендырма син этне суда күпме,
Чыгуга пычраныр ул, аунаганда.

Ишәген Мәккәгә илт син Гайсаның,
Ишәк кайтыр ишәк булып һаман да!

## КИЛЕП ҖИТӘР ХИСАП БИРЕР ЧАГЫҢ...

Килеп җитәр хисап бирер чагың,
Басып шунда халык каршына,
Яшермичә, кайчак ни кылганың
Син бирерсең сөйләп барсын да.

Үлчәр халык яхшың һәм яманың,
Тартынмыйча бар да шул чакта.
Син күрерсең үлчәү табагының
Тартканлыгын күбрәк кай якка.

Акладыңмы халык ышанычын? —
Син моны да ачык күрерсең.
Халык сиңа, нинди булса эшең,
Яшермичә әйтер дөресен.

Син бәхетле: риза булса халык
Синең барлык кылган эшеңнән,
Хурлыгыңнан керер өчен ярык
Эзләмәсәң баскан төшеңнән.

Син бәхетле: ишетеп рәхмәт сүзе,
Оялудан калсаң кызарып,
«Дус» дип йөргән ялагайның күзе
Карамаса сиңа кызганып.

Син бәхетсез: башны түбән салып
Агарганны синең күрсәләр.
Һәм: «Кичерик инде, шуннан артык
Ни көтәсең аннан!» — дисәләр.

*1958*

## КУЯН ҺӘМ ПРЕДСЕДАТЕЛЬ

(*Әкият-фельетон*)

«Яшәгәнче гомер буе калтырап,
Аучы кулыннан үлгәнең яхшырак...»

Көннәрдән бер көнне шулай дип уйлап,
Китте Куян урмандагы юл буйлап.

«Очраса да, — диде ул, — кем юлыма,
Барып керәм үзем шуның кулына!»

Йөрсә дә ул озак кына ул көнне,
Очратмады ләкин анда беркемне.

Тик кичкырын, кояш батып барганда,
Күрде Куян: берәү йөри аланда.

Укып шунда белгән барлык догасын,
Китте шуңа тапшырырга үз башын.

Ләкин бөтен эш җайланып килгәндә,
Куян инде барып җиттем дигәндә,

Теге кеше күреп Куян килгәнне,
Чапты-китте, борылды да бер мәлне.

Хәйран калды Куян күреп бу эшне.
«Нигә миннән кача, — диде, — бу кеше?»

«Әй, син, — диде Куян аңа, — куркак җан!
Ник качасың куркып миннән — куяннан!

Тукта бераз, тыңла минем сүземне,
Бүре түгел — ашамам ич үзеңне!»

Ялварып та туктамагач качудан,
«Ах, шулаймы?» — диде Куян ачудан.

Арт тәпиен җиргә дүрт-биш сукты да,
Шыш туктады, каршысына чыкты да.

Катты калды теге мескен аптырап,
Куркуыннан дер-дер килеп, калтырап.

Ә Куянның артты гайрәт һәм көче:
«Ник куркасың, — диде, — миннән син, кеше?

Мин бит тимим беркемгә дә, беләсең!
Мин җен түгел, бүре түгел, күрәсең!»

«Беләм, — диде кеше аңа, — син — Куян,
Чапкан идем мин нәкъ синнән куркудан.

Мин «Кызыл юл» колхозында ничә ел
Председатель булып торам, шуны бел.

Безнең колхоз болай үзе бай гына,
Эшебез дә бара безнең җай гына.

Эш шәп барса, халык эштән туймый бит,
Тормышны гел яхшыртырга уйлый бит.

Алар миңа һаман тынгы бирмиләр:
— Йорт куяны үрчетмибез ник? — диләр.

Ул бит бирә бик күп йон һәм ит, диләр,
АКШ белән ярышабыз бит, диләр.

Мин ялынам: көтегез, дим, аз гына,
Җитешербез акрынлап, дип, барсына.

Минем зарга һич тә колак салмыйлар:
— Без райкомга барабыз, — дип яныйлар.

Тәмам туеп, качып менә шулардан,
Йөреп кайтыйм бераз, диеп, урманнан,

Хәл алырга чыккан идем мин менә,
Килеп чыктың шунда янга син менә.

Ә мин сине йорт куяны дип белдем,
Шуңа күрә синнән качып йөгердем.

Зинһар, миңа бер яхшылык итә күр,
Тизрәк, җаным, минем яннан китә күр!

Колхозчылар килеп чыга күрмәсен,
Синең белән очрашканны белмәсен...»

Хәйран калып шунда Куян бу хәлгә,
Әй тотына эчен тотып көләргә!

«Бар икән, ди, куяннан да куркучы.
Өстәвенә үзе шундый зур кеше!»

Ауный-ауный көлә аның янында.
Арта куркуы тегенең тагын да.

Теге кеше, килеп шунда аңына,
Чабып китә тагын авыл ягына.

Куркудан ул шундый каты сыптыра!
«Тот!» та «Тот!» — дип, Куян арттан кычкыра.

Үзе уйлый: «Барган җирдән үләргә,
Очрадым, — ди, — ничек мин бу юләргә!

Җирдә миннән дә куркаклар булганда,
Ник кимсенеп яшим мин, — ди, — дөньяда?..»

Һәм уфылдап, эчен тоткан көенә,
Эре генә кайтып китә өенә.

*1957*

## НИ УЛТАРА, НИ ПУЛТАРА

*(Фельетон)*

Колхозлар күп районнарда,
Тигез түгел ләкин бар да:
Бар эресе, бар бик вагы,
Баерагы, ярлырагы.
Кайсында шәп орлыкчылык,
Кайсында шәп терлекчелек,
Кайсының шәп җитәкчесе,
Бара шуңа бик шәп эше.
Кайсы — алда, кайсы — артта,
Кайсы сөйри, кайсы тарта...
Җиңел түгел алда бару,
Алдынгылык яулап алу;
Андыйларны гел каулыйлар:
— Молодчина! Шулай! — диләр. —
Бүтәннәргә үрнәк күрсәт,
Арттыр тагы, давай! — диләр.
Биргән саен: — Бир! Бир! — диләр.
Бер минут тынгы бирмиләр.
Ләкин рәхәт ягы да бар:
Районда гел хөрмәт аңар.
Бөтен җирдә ул мактала,
Исеме — кызыл тактада.
Тулы тота келәтне дә,
Кинәндерә дәүләтне дә.
Һәркем әйтә рәхмәт аңа,
Бүләкләнә, байрак ала.
Тирә-якны нурландырып,
Якты маяк булып яна.

Арттагыны тәнкыйтьлиләр:
— Булмый болай, юк-юк! — диләр. —
Күршең күптән маяк булды,
Ә син нәрсә? Оят! — диләр. —
Сөйрәлмә гел артта, — диләр. —

Әйдә, шәбрәк атла! — диләр.
Кыздыралар, пешерәләр,
Салкын тиргә төшерәләр.
Кирәк чакта булышалар,
Күтәрергә тырышалар.
Шулай тәнкыйть итә-итә,
Ниһаять, ул алга китә.
Ул да рәхәт күрә башлый,
Барсын да мул бирә башлый.
Шулай олы юлга чыга,
Нур сибә һәм нурга чума!

Районда бар шундыйлар да:
Калмый артка, бармый алда.
Мавыкмый ул дан белән дә,
Шаккатырмый сан белән дә.
Эшен кора җайлап кына,
«Мөмкинлек»кә карап кына,
«Артык китә күрмәсен!» дип,
Кирәк кадәр санап кына.
Планы да булыр-булмас,
Булганы да тулыр-тулмас.
Маен бирсә, итен бирми,
Итен бирсә, сөтен бирми.
Ватылмый да, тирләми дә,
Макталмый да, тиргәлми дә.
Тактада да күренми ул,
Байракка да үрелми ул.
Яши шулай гел уртада —
Ни ултара, ни пултара!

Юк андыйны борчучы да,
Чынлап торып орышучы да,
Олы юлга чыгарырга,
Күтәрергә тырышучы да.
Риза аннан житәкчеләр:
— Аңардан шул житә, — диләр. —

Ничава ул, ярый, — диләр. —
Бик үк арттa бармый,— диләр. —
Инде безнең план, — диләр, —
Ансыз да бит тулган! — диләр.
(Иттән бигрәк, сөттән бигрәк
Аларга бит план кирәк!)
Ә районны утырталар,
Чынлап баксаң, шул «урта»лар:
Берәү түгел, икәү түгел,
Күпчелек бит әле алар!
Ә карасаң, исемнәре
Нинди генә дисең әле!
«Ватан», «Чулпан», «Ирек», «Маяк»,
Тукай, Чапай, «Кызыл Байрак»!
Исем — матур, исем — бөек,
Эшләр генә ләкин сыек,
Эшләр генә гел уртада —
Ниултара, ни пултара!

Юк, тик тотмыйк без аларны,
Тынлык сөйгән «урталар»ны.
Тирләгәндә алдагылар,
Тиргәлгәндә арттагылар,
Мыек бөтереп, тыныч кына
Ятмасын бер якта болар.
Кирәк икән орышыйк та,
Кирәк чакта булышыйк та,
Бераз гына кытыклыйк та,
Таеп китсә, култыклыйк та,
Тотынышып кулны кулга,
Чыгарыйк чын, олы юлга.
Ятмасыннар гел уртада,
Пыскып кына кыл уртада,
Булып шулай гомер буе
Ни ултара, ни пултара!

*1962*

## ГАЙФИ АГАЙҺӘМ КИБЕРНЕТИКА

Кибернетикага каршы
Председатель Гайфи агай:
— Бу бит кашу гына, — ди ул, —
Кычытмаган җирне, малай!

Күп бит бездә машинаның
Бик акыллы, яхшылары...
Әллә безнең ученыйлар
Бөтенләй үк шаштылармы?

Кирәк, имеш, бүген безгә
Уйлый торган машиналар!
Бөтен эшне кеше төсле,
Имеш, эшли алсын алар!

Әгәр шундый иттерсәләр
Колхозның бар машинасын,
Гомер буе, валлаһи, дим,
Бәлаләрдән чыкмас башың!

Ни эшләрсең, әйтик, алар
Әгәр уйлый башласалар?
Башларына нәрсә килсә,
Шуны эшләп ташласалар?

Әйтик, беркөн ачык кырда
Аунап яткан җирдән килеп
Дау кубарса комбайннар:
— Давай ябык сарай! — диеп,

Куяр өчен бүтәненә,
Алыйм дисәң берәр чәсен,
Алдырмыйча, тракторларың
Агартсалар маңгай чәчең?

Йә булмаса, «газик»ларың
Син әйткәнчә эшләмичә,
Шоферыңны утыртмаса,
Авыз-борнын иснәмичә?

Йә утильгә билгеләнгән
Суккычларың, кызып китеп,
Беркөн тетеп ташласалар
Үзеңне үк утиль итеп?

Техникагыз ни хәлдә, дип,
Берәр вәкил сораганда,
Ни эшләрсең, синнән узып:
«Начар хәл!» — дип торса бар да?

Төзек дигән ургычларың
Җыелышка килеп керсә:
«Төзек түгел, ватык без!» — дип,
Бар хәйләңне ачып бирсә?

Техника бит кеше түгел,
Җансыз бит ул, юк бит аңы:
Куркытып та, өркетеп тә,
Юмалап та булмый аны.

Абруең ни аның өчен,
Керми бит ул синең хәлгә.
Ул бит сине жәлли белми,
Үзен генә аның жәллә!

Яки карар кабул итсә,
Бар техника җыелып бергә:
— Давай моннан китәбез, — дип, —
Кадребезне белгән җиргә?!

Ихтимал бит шундый хәл дә:
Ни эшләрсең, ул нәрсәләр
Беркөн тотып югарыга
Әләк язып җибәрсәләр?

Машинаның бар бит тагы
Бик хәтәр бер шундый ягы:
Ул бит барын күреп тора,
Дәшмәсә дә белеп тора.

Язып барып үз «Победа»ң,
Әйтик, кайда йөргәнеңне,
Сөйләп бирсә карчыгыңа
Кайчан, кая кергәнеңне?

Монсын инде, туганкайлар,
Әйткән чакта кыска гына,
Күрсәтмәсен Ходай үзе
Дуска түгел, дошманыңа!

Менә бит ул нинди хәтәр
Уйлый торган машиналар!..
Ә сезнең ул ученыйлар
Юкка шулай ашыгалар,
Кычытмыйча капыналар!

*1962*

## ДИНСЕЗ ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

*

Булсын дисәң бар халыклар дус һәм иштәш,
Төкер дингә, беркатлы дус, бирим киңәш.
Чөнки Аллаң ул дуслыкка каршы килә:
Дошман күр, ди, кем булмаса сиңа диндәш.

*

Барын бирә, шөкер, миңа Алла, дисең,
Алла биргән ризык минем алда, дисең.
Барын да бит бирә сиңа тырыш хезмәт,
Нигә, агай, үз-үзеңне алдалыйсың?

*

Сөям, дисең син, бабакай, хөрлекне,
Нәләтлисең коллык дигән хурлыкны.
Ник зурлыйсың алайса ул Алланы?
Ул бит яклый шул хурлыклы коллыкны!

*

Ышанасыз, хатын-кызлар, ник сез дингә?
Уйламыйсыз шундый ягын аның нигә?
Ул бит хурлый һәркемнән дә бигрәк сезне,
Рөхсәт итеп дүрт-биш хатын һәрбер иргә!

*

Ник сөйлисең, чалмалы баш, чеп-чи ялган,
Ни буласын белә, диеп, Алла алдан?
Алдан белгәч, ник алайса Коръәненә:
«Кеше күккә менәлмәс!» — дип язган Аллаң?

*

Коръән җирне җәенке, ди, келәм кебек,
Балалар да карый хәзер моңа көлеп.
Калган булса «чарлагыңда» акыл әзрәк,
Бу аятьне укыма син бүген, хәзрәт!

*

Сөйләмә син юкны, мулла, безнең көндә:
Тора, диц, җир бер үгезнең мөгезендә.
Алтмыш ташкыр урап җирне, космонавтлар
Күрмәгән ич ул үгезнең бер эзен дә.

*

Уразаңны үзең генә тот син, Алла.
Күгеңдә син ятасың бит эшсез анда.
«Эшләмәгән — ашамас!» ди җир законы,
Нәкъ үзеңә лаек, димәк, уразаң да!

*

«Яраттым, ди, колларымны төрле итеп,
Берәвен бай, ә берәвен ярлы итеп...»
Шул Алланы гадел дигәч ислам дине,
Гаделсезлек санарга соң инде нине?

*1962*

## МИН ҖӘННӘТНЕ КҮРДЕМ

Мин шундый бер сәер хәлгә тардым,
Өндә түгел, төштә, әлбәттә:
Саташтырып берсе, мин ничектер
Эләккәнмен, имеш, җәннәткә.

Иксез-чиксез бакча, имеш, җәннәт.
Чумган, имеш, бар җир гөлләргә,
Баш өстендә тубый агачлары
Тора, имеш, ясап күләгә.

Сайрый, имеш, гөлләр арасында
Күз күрмәгән җәннәт кошлары;
Йөри, имеш, җырлап бөтен җирдә
Вилданнары һәм хур кызлары.

Теләгәнчә коч һәм сыйпа, имеш,
Ак тәннәрен, нечкә билләрен...
Тик җирдәге төсле түгел, имеш,
Җәннәттәге сөешү дигәнең.

Белми, имеш, кем дә, берне сөеп,
Шул бер өчен яну ләззәтен.
Йөри, имеш, көтү-көтү булып,
Гашыйклары бөтен җәннәтнең.

Хайванлыкка түгел, сөелүгә
Һәм сөюгә шуны исәпләп,
Утыра, имеш, ирләр берьялгызы,
Җитмеш җиде хурны кочаклап.

Ә хатыны, үлеп сөйгән хатыны,
Күрмәгән күк ире барын да,
Җитмеш җиде Вилдан белән үбешеп,
Утыра, имеш, шундук янында.

Яши, имеш, кеше шулай монда,
Уйламыйча берни турында.
Яну да юк, имеш, көнләшү дә,
Үлү дә юк, имеш, туу да.

Онытылганнар, имеш, эзләнүләр,
Омтылулар көн дә яңага,
Ята, имеш, һәркем ашап, эчеп,
Тәсбих әйтеп көн-төн Аллага.

Иҗат та юк, имеш, фән дә монда,
Завод та юк, имеш, төзелеш тә.
Гомер итә, имеш, мәңге шулай
Эшләмичә кеше бер эш тә.

Радио да юк, имеш, газетлар да,
Театр да монда, кино да,
Үткәрәсең, имеш, мәңгелекне
Ни булганын белми дөньяда.

Сүнә, имеш, мәңге йөрәкләрдә
Хыяллар да монда һәм дәрт тә...
Кыска гына итеп әйткән чакта,
Бик күңелсез, имеш, җәннәттә!

Йөрим, имеш, монда килеп ләккән
Кешеләрне эчтән мин жәлләп:
Сорыкортлар өчен генә бары
Ярый икән, диеп, бу җәннәт!

Уйлыйм, имеш, үзем эчтән һаман:
— Ничек итеп соң бу динлеләр
Мәңге рәхәт җире диеп моны
Ышандылар икән, тилеләр?..

Кысыла, имеш, тыным: «Ни эшләрмен
Мәңге калсам», — диеп куркудан...
Газапланып шулай яткан чакта,
Мин уянып киттем йокымнан.

Шулкадәрле төштә курыктым мин,
Киткәчтән дә хәтта уянып,
Озак яттым: «Ярый җәннәтләре
Ялган гына!» — диеп куанып.

*1960*

## АХЫРЗАМАН

Хәзрәт төшкән зур куркуга,
Төшмәскә — эшләр яман:
Якыная көннән-көнгә
Чынлап та ахыр заман!

Ә бит, төптән уйлап баксаң,
Үзе әле күптәнме,
Куркытып шул заман белән,
Имә иде күпләрне!

Хәзер андый әкият белән
Куркытып бак аларны:
Якынайтабыз без, диләр,
Үзебез шул заманны!

Имеш, аның килүенә
Без түгел бер дә каршы:
Ахыры бит ул сезнең өчен,
Ә безнең өчен — башы!

Йоклый алмый ята хәзрәт
Уяна да төннәрдә.
Булмый чөнки кызыктырыш
Инде җәннәт белән дә.

Күктәге ул җәннәткә син
Бар, үзең җыен, диләр.
Без төзибез җирдә аның
Настоящиен, диләр.

Ә үлгәч керәсе җәннәт
Безгә ул нигә, имеш.
Без аңа керәбез, диләр,
Җирдә һәм тере килеш!

Бар әле, диләр, шунысы да:
Ни йөреп күк йөзендә,
Космонавтлар күрмәгәннәр
Ул җәннәтнең эзен дә!..

Юк дөньяда хәзрәт өчен
Ямь дә хәзер, хозур да:
Ычкына аның кулыннан
Иң соңгы бу козырь да.

Аһ-ваһ килә көн-төн, мескен,
Килмәскә — эше яман:
Якыная аның өчен
Чынлап та ахыр заман!

*1962*

## КАРТ СКУЛЬПТОРГА

*(Шаяру)*

Җитмешкә җитәм инде, дип
Күрсәтмә чаллы башың.
Ниндидер алдау бар монда,
Килми һич ышанасым!

Яшеңнең чынын, мөгаен,
Йөрисең син яшереп.
Минемчә, яшәгәнсең син
Мең еллар моннан элек.

Гасырдан ашып гасырга
Һәм күчеп диннән дингә,
Кешеләр турында җирдә
Бер әкият яшәп килә:

Кайчандыр Алла кешенең
Балчыктан ясап сынын,
Җан өргән, имеш, шуңарга.
Без — нәселе, имеш, шуның...

Бу — адәм ышанмый торган
Буш әкият тик, әлбәттә.
Ләкин бит тормыштан алмый
Ясалмый бер әкият тә!

Мин шуннан ясыйм нәтиҗә:
Мең еллар элек моннан
Үзең һәм синең һөнәрең
Дөньяда инде булган.

Балчыктан кеше ясавың
Шул заман халкы күреп,
Тудыргандыр бу әкиятне,
Сине Алла дип белеп!

*1962*

## ГЫЙБРӘТЛЕ ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

*

Мин төш күрдем: имеш, күктә очып йөрим.
Балкый, имеш, мең-мең йолдыз тирә-якта...
Уяндым да уйлап ятам: «Юләр син, — дим, —
Очканы бар кемнең ятып... караватта!»

*

Эх, булсачы, дисең, минем канатларым!..
Кош түгел бит — канат сиңа нигә кирәк?
Җитәм дигән җиргә кеше җитә барып
Шуышып та... Булсын гына бары теләк!

*

Җирнең нигә асты өскә килеп бетми,
Йоклый бирә ул, бернигә исе китми.
Кермидер күк борчулы бер төш тә аңа...
Кирәк түгел! Кызыкмыйм мин һич тә аңа!

*

Оныттыңмы, сеңлем, шундый көннәреңне:
Бу икмәкнең валчыгын да бүлгәнеңне?
Оялмыйча, шундый газиз нәрсә белән
Туйдырасың ничек тавык-үрдәгеңне?

*

Язмышыңа, имән, синең кызыкмыйм мин,
Зурлыгыңнан, ныклыгыңнан нинди файда?
Тамырларың белән җиргә бәйләнеп син,
Торасың ич бер урында мәңге бәйдә!

*

Зарланма син, күңел, эшем күп, дип,
Шундый туйдым, түзәр хәлем юк, дип.
Уйла чит илдәге туганнарның
Эшсезлектән ничек туйганнарын!

*

Ярый әле яралмаган җирдә кеше
Машина күк сүтә-җыя торган итеп:
Ятар идең, эләксәң бер бюрократка,
Лапасында аның запас частьлар көтеп!

*

— Ничек чыккан илле биштән пенсиягә? —
Диш, аны сез әрлисез бит юкка гына:
Чыкса да ул, өйдә эшсез тик ятмый бит —
Көне буе массаж ясый... корсагына!

*1962*

## МИН КУРЫКМЫЙМ ШЕЛТӘДӘН

Бар бездә шундый кешеләр —
Шелтәдән куркып яшиләр.

Ә мин күпме шелтә алдым
Үземнең гомеремдә!
Аңа карап миңа ләкин
Килмәде зыян бер дә.

Мин хәтерлим: яшьлегемдә
Эшләдем мин бер артельдә.

Тузгытып шул артель малын,
Мин беркөнне тотылдым.
Ни булды шуннан дисезме?
Шелтә белән котылдым!

Завмаг булып эшләгәндә,
Мин куркып тормадым бер дә:

Итәк астыннан озаттым
Дефицит товарларны.
Тотылгач, моның өчен дә
Мин шелтә алдым бары!

Бездә кайбер куркак бәндә
Курка хәтта эчүдән дә.

Трестта мин завхоз чагымда
Йөрдем көн саен салыш.
Котылып калдым монда да
Бары тик шелтә алыш!

Ә райфода эшләгәндә,
Кыйнадым хатынны көн дә.

Аерып җибәргәч аны,
«Ай-яй начар!» диделәр.
Моның өчен дә бары тик
Шелтә генә бирделәр!

Завстоловой чакта мине
Берсе тәнкыйть иткән иде.
Моның өчен ул юньсезне
Мин хезмәттән чыгардым.
Ул алты ай эшсез йөрде,
Ә мин тик шелтә алдым!

Ә бездә бик күп тилеләр,
Шелтә, дип, куркып йөриләр.

*1956*

## МИНЕМ ДУСТЫМ — ЗУР ГАЛИМ

(*Беранже буенча түгел*)

Юк, алдарга уйламыйм,
Минем дустым — чын галим!

Безнең фәнни институтта
Утырмый ул ун ел юкка.
Монда аны зурлыйлар:
— Бик зур талант ул! — диләр.
Аның фәнни хезмәтләре —
Кыюлыкның үрнәкләре.
Аз дигәндә өч киштә,
Һәр киштәдә — өч дистә!

Юк, мактарга уйламыйм,
Ул чыннан да зур галим!

Кукурузың аңа нигә?
Борчакка ул төкерми дә:
— Кирәк, — ди ул, — карарга
Кимендә йөз ел алга!
Өйрәнә ул комлы чүлдә
Кит балыгы үрчетергә.
— Имезүче бит ул, — ди, —
Сөтне бирер бик мул! — ди.
Әзерләнә үстерергә
Котып артында ак гөмбә,
Үрчетергә Марста
Шалкан ялгап арышка.
Шундый кыю булгангамы,
Аңламыйлар күпләр аны.
Даһилыгын күрмиләр,
«Буш куык!» дип тиргиләр.

Юк, мактарга уйламыйм,
Ул искиткеч зур галим!

*1962*

## ҖИҢГИНЕҢ ЧИРЕ

*(Казакъчадан)*

Аптырый җиңги,
Нишләргә белми.

Менә иренеп
Урыннан торды,
Әрле дә бирле
Өй буйлап йөрде.

Өйдәге эшкә
Кул бармый һич тә.

Шулай аптырап
Йөргәч бик озак,
Ятты ул арып,
Диванга барып.

Ятып та бераз,
Аннан да туйгач,
Алып телефон,
Чакырды врач.

Врач тиз килде:
— Ни булды? — диде.

Ыңраша җиңги:
— Чирләдем мин! — ди.

Тыңлап күкрәген,
Тыңлап аркасын,
Тикшергәч врач,
Чайкады башын:

— Чирлисез икән
Күптәннән бирле.
Тик гади дару
Җиңмәс бу чирне.

Эшләп карагыз
Сез моннан ары.
Дәвасы аның
Шул гына бары!

— Юк! — диде җиңги,
Бу сүзгә күнми. —
Бу даруга мин
Риза булалмыйм.

Эшләп гомергә
Чиккәнче иза,
Тик кенә ятып
Үләргә риза!

*1963*

## БЕРКАТЛЫЛЫК КОРБАННАРЫ

Йомшап китеп
Сарыкларның
        Күңеле,
Алганнар, ди,
Порукага...
        Бүрене!

Төзәлмәсме,
Диш, Тавыклар
        Беркөнне
Алганнар, ди,
Тәрбиягә...
        Төлкене!

Биш ел инде
Эчмим дигәч
        Аракы,
Куйганнар, ди,
Главвинога...
Биш ел буе
Ятып чыккан
        Каракны!

*1963*

## ФИЛ, БҮРЕ ҺӘМ ТАШБАКА

(*Халык мәзәге буенча*)

Белмим, чынмы, ялганмы,
Булмаганмы, булганмы,
Тик сөйлиләр шул хакта:
Фил, Бүре һәм Ташбака
Кайсыдыр бер бәйрәмдә
(Сәбәп белән һәрхәлдә!)
Теләгәннәр эчәргә
Бер яртыны өчәүгә.

Телисең икән теләк,
Аны үтәргә кирәк.
Ләкин юк бит урманда
Ларек та, ресторан да.
Шулай булгач, аларга
«Теге»не ничек табарга?

— Бар, — дигән Бүрегә Фил, —
Син авылга барыш кил.
Барыр идем үзем дә,
Авыр түгел бу бер дә,
Мондый гәүдәм белән мин
Кибеткә бит керәлмим!

Бүре әйткән: — Шту син!
Ике башлы мәллә мин,
Курыкмыйча авылга
Көпә-көндез барырга?
Ул авылда бит, җаный,
Мине һәрбер эт таный!..

Бүрегә ярамагач,
Фил дә бара алмагач,
Туры килгән авылга
Ташбакага барырга.

Ул да каршы килмәгән,
Бармыйм-фәлән димәгән,

Берәр сәгать җыенып,
Чыгып киткән киенеп.

Авыз суларын сөртеп,
Калган тегеләр көтеп.

Көткәннәр дә көткәннәр,
Тәмам арып беткәннәр.
(Ташбаканың тизлеге
Һәркемгә бит билгеле!)

— Эх, — дигән шунда Бүре, —
Батты бит, чәнчелгере!

Фил әйткән: — Тыңлап сүзем,
Барасың калган үзең.
Белә идең бит аның
Ничек кыймылдаганын.
Үзебез шул шыр тиле,
Хәзер бер ел көт инде!..

Ишек артында шулчак
Нидер куйган кыштырдап.
Һәм ташбаканың шуннан
Тавышы килгән болдырдан:

— Нәрсә тагы анда сез
Җыелып мине сүгәсез?
Тукта, тизрәк барыйм, дип,
Иптәшләргә ярыйм, дип,
Йөри торгач йөгереп,
Чак төшмәдем егылып.
Кадерен белмичә шуның,
Китерсәгез ачуым, —
Дигән ул, ачуланып, —
Йөрмәм дә әле барып!..

Аның бары болдырдан
Төшеп барышы булган!

*1963*

## ТУГРЫ ДУС

(*Украин халык мәзәге буенча*)

Семен шактый еш эчә,
Тик эчми ул кешечә:
Ике чокыр ала да,
Йөзәр грамм сала да,
Эчә, икәү эчкән кебек,
Бер-берсенә чәкештереп.

Моны күргән кешеләр:
— Ни эшләвең бу? — диләр.
— Бүлгәлисең ник? — диләр.
— Тәме бердер бит? — диләр.

— Мин бит, — ди ул, — эчәм берсен
Ерактагы дустым өчен.
Ул үзе океанда,
Эчәргә юк, ди, анда!..

Тик Семен соңгы вакытта
Үзен никтер сәер тота:
Эчә тик бер чокыр алып,
Шуңарга йөз грамм салып.

Буфеттагы кешеләр:
— Ни булды, Семен? — диләр.
Әллә дустың кайттымы,
Йә булмаса баттымы?

— Юк, — ди Семен, — дустым исән!
Мин бит шуның өчен эчәм.
Үзем ташладым ич мин:
Өч ай бар инде — эчмим!

*1963*

## ҖИДЕ ЕГЕТ*

Җиде егет булганнар,
Җидесе дә уңганнар,
Җидесенә җиде җирдән
Алтын чәчле җиде кыз
Алып кайтмак булганнар.

Җитмеш чакрым үткәннәр,
Җиде авылга җиткәннәр,
Җиде колхозның эченнән
Алтын чәчле бер кыз да
Таба алмый киткәннәр.

Колхозларның кызлары,
Кояш кебек йөзләре,
Бар да уңган, бар да булган,
Кая гына куйсаң да,
Сокланырлык эшләре.
Колхозларның кырлары,
Якты икән юллары.
Чәче алтын булмаса да,
Колхоздагы кызларның
Алтын икән куллары.

Егетләр шаккатканнар,
Бер-берсенә бакканнар,
Җидесенә җиде җирдән
Алтын куллы җиде кыз
Ябыштырып кайтканнар.

*1950*

* Н.Җиһановның «Намус» операсыннан Нарспи җыры.

## ӨЧЕГЕТ

Ай-һай, дуслар, безнең Гөлсем
Бигрәк чуар күңелле!
Сайлый алмау өчтән берсен —
Шул чуарлык түгелме?

Ул бит, дисез, үз эшендә
Төпле генә кыз кебек!..
Алай булгач, тирәсендә
Нигә йөртә өч егет?

Шулай сайлап булмаслыклар
Кемнәр алар дисеңме?
Берсе — Газиз, берсе — Батыр,
Берсе — Камил исемле.

Берсе кайткан Будапешттан,
Берсе — Берлин яныннан.
Өченчесе — күптән түгел
Тын океан ярыннан.

Барсының да күкрәгендә
Бишәр, алтышар йолдыз.
Кайсысына караса да,
Чуалып кала бит кыз!

— Сайла инде берсен, — дидек
Хатын белән аңарга,
Өчесеннән ләкин Гөлсем
Белми кайсын сайларга.

— Уйлап кара: кайсы уңган,
Кайсы бик матур? — дидек. —
Кайсы акылга бик камил,
Кайсы бик батыр? — дидек. —

Араларында аерма
Бардыр, — дидек, — әзерәк.
Арада, — дидек, — җаныңа
Кайсы соң газизерәк?

— Өчесе дә бик уңганнар,
Өчесе дә матур, — ди. —
Газизе дә, Камиле дә,
Батыры да батыр, — ди. —

Үзем дә бик аптырадым,
Аерудан гаҗиз, — ди. —
Батыры да, Камиле дә,
Газизе дә газиз, — ди. —

Кайсы акылга бик камил,
Аерып әйтә алмыйм, — ди. —
Батыры да, Газизе дә,
Камиле дә камил, — ди.

Хатын белән уйлый-уйлый
Аптырап беттек инде.
Инде, дибез, тизрәк берсен
Сайласа ярар иде.

Ә кайсысын? Үзебез дә
Әйтә алмыйбыз кисеп:
Өчесе дә бик ягымлы,
Аерып аласың ничек?

Нигә соң, дим, болар шулай
Өчесе дә уңганнар?
Хатын әйтә: — Алар шул, — ди, —
Армиядә булганнар!..

Уйлыйм-уйлыйм да хатынга:
— Үзебез уңмаган, — дим. —
Өчесенә шунда өч кыз
Үстереп булмаган! — дим.

*1946*

## САБИР

Дүрт ел йөреп кайтты Сабир
Сугышка киткән җирдән,
Җиңү яулап Туган илгә,
Герой булып Берлиннан.

Шау-гөр килде бөтен авыл,
Аның кайтканын белгәч,
Күкрәгендә янып торган
Алтын йолдызны күргәч.

Ут булды күзе кызларның:
— Аһ, ул нинди! — диделәр. —
Ләкин безнең авылда ул
Калмас инде, — диделәр.

Сызланды күпме йөрәкләр:
— Әрәм китә, — дип, — Сабир!..
Тик ул китми беркая да,
Булып калды бригадир.

Ныгыту өчен колхозын
Эшләде батыр егет
Көн-төн дими, ялны белми,
Нәкъ фронттагы кебек.

Күп тә үтми, авылдашлар
Тагын шау-гөр килделәр:
Аның тагын бер йолдызны
Алганлыгын белделәр!

Тагын кызлар, аңа карап:
— Аһ, ул нинди! — диделәр. —
Бу юлы, шиксез, авылда
Калмас инде, — диделәр.

Өстәп куйды шунда берсе:
— Нишләп калсын ул монда!
Аның урыны хәзер инде
Үзәктә йә районда!

Сызланды тагын йөрәкләр:
— Әрәм китә, — диш, — Сабир!
Ләкин китми, авылында
Тагын калды бригадир.

Хәзер инде җай килгәндә,
Шаян телләр сөйлиләр:
— Аның тагын бер йолдызга
Чамасы бардыр, — диләр. —

Хәзер инде бүтән йолдыз
Кирәк аңарга, — диләр, —
Лаеклы берәр йолдызны
Кирәк табарга, — диләр.

Шуннан бирле эш өстендә
Башын вата бик күп кыз:
— Кайсыбыз булыр икән, — диш, —
Батырга лаек йолдыз?!

*1948*

## КИЧКЕ ҖИЛӘС ҖИЛ ИСӘ...

— Кичке җиләс җил исә,
Йөрәкне сагыш кисә.
Көтеп тордым таңгача,
Нигә чыкмадың кичә?
Офык нурлангач кына,
Йолдыз югалгач кына,
Кайтып киттем моңаеп,
Картлар уянгач кына...

— Дөрес булса көткәнең,
Нигә хәбәр итмәдең?
Көткәнеңне белдереп,
Ник тәрәзә чиртмәдең?
Әгәр дә булсаң егет,
Икенче йөрмә җебеп.
Кыз баланы көттермә,
Кичә көттергән кебек!

*1946*

## КАЛА ЕГЕТЛӘРЕ

Килделәр безнең авылга
Шул кала егетләре,
Шул кала егетләренең
Нәкъ ялкын кебекләре.

Килделәр дә, чыбык тотып,
Өйдән өйгә йөрделәр,
Бөтен авылны яктыртып,
Электр үткәрделәр.

Кичен җырлап, гармун уйнап,
Урам буйлап үттеләр;
Яшь йөрәктә сүнми торган
Ут кабызып киттеләр.

Киткән чакта бер чибәре
Карады күзләремә.
Мәңге сүнмәс ут кабынды
Шунда яшь йөрәгемә.

Юлларыннан күзем алмыйм
Шулар киткәннән бирле,
Тынгы тапмый яшь йөрәгем,
Белмим нишләргә инде?

*1947*

## МИЛӘШ

Иркәм мине үпкән иде
Миләш күләгәсендә.
Иркәм миңа сәлам язган,
Торган вәгадәсендә.

Суга барсам, тукталамын
Шул миләш төпләренә.
Сагынып хатлар язамын
Туган ил чикләренә.

Борыламын да карыймын
Су юлы миләшенә.
Көтәрмен, бәгърем, карамый
Ятларның киңәшенә.

Миләш чәчәге коела
Чиләкле суларыма.
Чәчәкләр сибеп куярмын
Кайтасы юлларыңа!

*1947*

## ИКЕ ЯРА

Яраланган иде күкрәк сугышта,
Ала алмый идем юньләп сулыш та.
— Төзәлмәс тиз яраң, — диде дәвачы, —
Фәкать сабрың, — диде, — барлык дәвасы.
Озак үтми ләкин тордым яңадан:
Йомылды, калмады эз дә ярадан!..

Кара инде йөрәккә, әй, кара күз!
Яра салдың аңа, әйтеп авыр сүз.
Диделәр: — Тиз төзәлә мондый яра...
Шуңа йөрдем ышаныш мин, бичара.
Гомер үтте, ярам ләкин төзәлми,
Һаман әрним, авыртуга түзәлми.

*1946*

## КӨЗГЕ

(*Шаяру*)

Яктыртыш тирә-ягымны,
Зур көзге тора залда.
Күрәм мин картайганымны
Тик шуңа караганда.

Ә йөргән, эшләгән чакта,
Сөйгәндә, кайгырганда, —
Яшьме мин, картмы? Бу хакта
Уйламыйм бер заман да.

Гел сабый тоям үземне,
Ә кайчак — егет төсле...
Алыгыз шайтан көзгене,
Шул боза бөтен эшне!

*1963*

## ШАЯН СОНЕТЛАР

*

Без яшибез шундый заманда:
Җиңеп кеше җирнең тарту көчен,
Юллар салыш нурдан үзе өчен,
Очып йөри чиксез галәмдә.
Туктаталмый бернинди көч аны,
Күтәрелеп ул Җир шарыннан,
Аркасыннан сыйпап үтә айны,
Җырлап үтә кояш янынннан.
Илтер бу юл тиздән, мин ышанам,
Ерак йолдызларга кешене...
Тик мин генә җиңә алмыйм һаман,
Синең, бәгърем, тарту көчеңне.
Ул бик көчле, димәк. Шуңа мин
Орбитаңнан синең чыгалмыйм!

*

Чыга алмыйм һаман орбитаңнан...
Ни булды соң миңа, гүзәлем?
Әйләнергә шунда мәңге калсам,
Бу бушлыкта ничек түзәрем?
Рәхәт тә күк кайчак бу хәл миңа:
Карашыңнан җылы нур алыш,
Өметләнеп бер көн кавышуга,
Гел тирәңдә йөрим уралыш.
Якыныңа килә алмавымның
Бик әрнетә ләкин газабы...
Белмим инде, мондый әйләнүнең
Нәрсә белән бетәр азагы?!
Ерак китсәм — куркам сүнүдән,
Якын килсәм — янып үлүдән!

*1962*

## АТОМ ГАСЫРЫ ЛИРИКАСЫ

Минем хатын шундый хатын ул,
Хатын түгел, просто атом ул!

Әгәр дә шуның өстенә
Эшең булса кыек та,
Котылыш булмый арага
Бетон койма коеп та!

Инде үзеңне аклыйм дип
Дәшеп куйсаң каршы да,
Шундый шартлый, алай булмас
Водород бомбасы да!

Ә инде үзең шәп йөрсәң,
Чыкмаса сиңа җене,
Шундый гөрли, әйтерсең лә
Тынычлык күгәрчене!

Куллана тик тынычлыкка
Ул чак энергиясен:
Атом коралын тыярга
Пакт төзгәнбез диярсең!

Ни булса да булсын әнә,
Водородмы, атоммы,
Ләкин гадел ул. Шуңа да
Яратам мин хатынны!

*1958*

## АЛКА ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Сигезенче Март көнне
Бүләклим, дип, хатынны,
Җиткәч быел март башы,
Алдым колак алкасы.
Йөз илле тәңкә түләп!
Вәт, мин әйтәм, шәп бүләк!
Бер куансын хатын, дим,
Гел сүкмәсен картын, дим.
Юкса һаман тирги бит,
Игътибарсыз ир син, дип,
Һәр Сигезенче Мартны
Тондыра бит колакны:
— Син мине сөймисең, — ди, —
Хатын дип белмисең, — ди, —
Кеше ирләре кебек,
Бүләк тә бирмисең, — ди...

Килеп тә җитте бәйрәм.
Иртән хатынга әйтәм:
— Кара әле, хатын, — дим, —
Нәрсә алып кайттым, — дим.

Минем бүләкне күргәч,
Нәрсә икәнен белгәч,
Хатын әйтте аптырап:
— Эх, син, сукыр! Эх, дурак!
Нинди бүләк тапкан бит!
Алка алып кайткан бит!
Унбиш ел торыш бергә,
Күрмәгән икән бер дә!
Менә нинди пешмәгән:
Колагым бит тишмәгән!..

*1958*

# ОКТЯБРЬ ӘЛИФБАСЫ

Алпавыт юкка чыкты,
Акгвардия тончыкты.

Буржуйлар белән бергә
Богаулар керде гүргә.

Вакытлы хөкүмәт шиңде,
Властька эшче халык килде.

Гүләгәч «Аврора» тубы,
Гүзәл яңа тормыш туды.

Деникин «Мин!» дип масайды,
Дүрт аяклап чак-чак тайды.

Елмая җирдә халыклар:
Елдан-ел ныгый Советлар!

Җәлләрлек буржуйның эше:
«Жаркой»ны сагына теше.

«Заман ахры җитте!» диеп
Зар елый буржуй, яшь коеп.

Интервент, тот хәтереңдә:
Исән китми бездән кем дә!

Керенский премьер булды,
Көчкә юбка киеп шылды.

Лорд килде алырга үчен,
Ләкин качты, тотыш эчен.

Меньшевик — буржуй лакее,
Мәет булды тере көе.

Николай күпме кан эчте,
Ниһаять, барысын да косты.

Октябрь сугышта туды,
Онытма, агрессор, моны!

Пролетарий яуда ишле:
Пыр туздырды интервентны.

Ракета үтә тиз йөри,
Россия тынычлык тели.

Советлар курыкмый көчтән.
Сенатор, чыгарма истән!

Тарихны борам дип кире,
Тапты үлем күпме тиле!

Уйнаса ут белән беркем,
Утта янар үзе беркөн!

Фаш ителде Аденауэр:
Фашист Гитлер белән ул бер!

Хасанның бик хәтәр яры:
Хур булды сугыш чукмары.

Чан Кай-ши ятып Тайваньда,
Чиный һәм улый һаман да.

Шаулап килгән иде Гитлер,
Шыш-шышырт дөмекте никтер!

Ырылдый һәм ялган сибә,
Ышанмагыз Би-би-сигә!

Эсер дигән шакшылар
Эт үлемен таптылар.

Юкка яный безгә мистер,
Юк аннан куркучы һичбер!

Ятканчы буш хыял корып,
Ятла, мистер, боларны нык!

*1957*

## КЕМ НӘРСӘ УЙЛЫЙ?

(*Айга юл ачылу перспективасы уңае белән*)

**Спекулянт**

Бер төянеп менеп төшсәң,
Вәт калыр иде файда!
Дефицит булмаган товар
Юк, диләр, әле Айда!

**Хулиган**

Эләксәң бер биш тәүлеккә,
Нишләрсең анда? Ай-яй!
Сузыла диләр тәүлекне
Анда бит почти бер ай!

**Алименттан качучы**

Бер менеп алсам шул Айга,
Җайлар идем бар эшне:
Табыш карасыннар иде
Айда минем адресны!

**Командировка сөюче**

Ыһ та итмим, йөреп кайтам
Хет Айдан, хет Марсыннан,
Тик юллыгын түләсеннәр
Километр башыннан!

**Озын язарга яратучы автор**

Менәргә мин каршы түгел,
Аңламыйм бары шуны:
Әсәрләрем язар өчен
Каян табармын суны?

## Түрә хатыны

Кавказы да бар, ди, Айның,
Ким түгел, ди, Җиреңнән.
Иртәгә үк бер путевка
Алдырттырам иремнән!

*1959*

## КОНФЛИКТ

Шигырь яздым тарих мең дә
Фәләненче елында
Бер хатынның ире белән
Талашуы турында.

Шигырь чыккач, тәнкыйтьчеләр
Бар да шау-гөр килделәр:
— Бу бит совет семьясына
Яла ягу! — диделәр.

Икенче бер шигырь яздым
Шундый тәнкыйть соңында,
Бер егетнең бер кыз белән
Сөешүе турында.

Тагын шул ук тәнкыйтьчеләр
Күз ачарга бирмиләр:
— Бу бит лаклау! Син тормышны
Конфликтта бир! — диләр.

Инде яңа шигырь язам,
Шуларга яраштырып:
Башын башлыйм талаштырып,
Бетерәм ялаштырып!

*1954*

## МИНЕМ ИРКӘМ

Минем иркәм — бригадир кыз,
Күкрәгендә медале.
Казанда да, Мәскәүдә дә
Белмәгән юк инде аны!

Минем иркәм иртән тора,
Таң йолдызы шикелле.
Үзе уңган, үзе булган,
Үзе шундый сөйкемле!

Минем иркәм узган чакта
Ал гөлләрне карата.
Эшкә оста, сүзгә кыска,
Һәркем аны ярата.

Минем иркәм ялкын кебек,
Яндырмый кемне генә!
Яндырса да кемне генә,
Ярата берне генә!

*1947*

# НИШЛИМ ИКӘН?

Чәчәкләргә тиңли шагыйрь сезне,
Шомыртларга — кара күзегезне,
Чылтырап аккан чишмә тавышына —
Сезнең әйткән һәрбер сүзегезне.
Әллә шагыйрь түгел микән соң мин?
Чәчәкләргә сине тиңләштермим.
Карап торам — күзең нәкъ күз төсле,
Сүзләрең дә бик гади сүз төсле,
Ала алмыйм ләкин күзләремне,
Туя алмыйм тыңлап сүзләреңне.
Әйтче миңа, дустым, нишлим икән?
Башкалардан шулай син ким микән?
Әллә сине чәчәкләргә түгел,
Чәчәкләрне сиңа тиңлим микән?

*1938*

## УОЛЛ-СТРИТТА ТЕТРӘҮ

Уолл-стриттагы[1] мистерлар
Бар да дер-дер калтырыйлар:
Ике сәгать инде менә
Бөтен Уолл-стрит селкенә.

Селкенәләр стеналар,
Тәрәзәләр калтырый.
Нәрсә булган? Ни булган?
Беркем белми, аптырый.

Сорыйлар сейсмологлардан[2],
Алар берни белмиләр:
— Сейсмографлар[3] тыныч бездә,
Бернәрсә дә юк! — диләр.

Күршедәге урамнарда
Берни юк — тып-тыныч бар да.

Мистерлар, куркып бу хәлдән,
Сорашалар бөтен илдән.
Беркем бернәрсә белми:
Имеш, берни селкенми!

Ә Уолл-стритта менә
Бөтен нәрсә селкенә!

Ниһаять, әйтә бер мистер:
— Белдем ни булганын, — ди. —
Сыныйлар атом бомбасын
СССРда тагын! — ди.

---

[1] Уолл-стрит — Нью-Йоркның иң зур банклары урнашкан урам; эре финансистлар төркеменең ерткыч империалистик интереслары символы.

[2] Сейсмолог — җирнең тетрәвен теркәүче.

[3] Сейсмограф — җир тетрәвен терки торган аппарат.

Бар да куркыныш калалар,
Күгәрәләр, агаралар,
Калтырыйлар, тирлиләр:
— Инде нишлибез? — диләр.

Кайсы әйтә: — Хәзер үк
Тревога ясыйк, — ди.
Кайсы әйтә: — Уолл-стриттан
Тизрәк чыгып качыйк, — ди.

Кайсы әйтә: — Бүген үк
Сугыш башларга кирәк, — ди.
Кайсы әйтә: — Хәзер үк
Бомба ташларга кирәк, — ди.

Кайсы әйтә: — Тәрәзәнең
Бикләгез һәммәсен, — ди. —
Берәребез, Форрестол күк,
Сикерә күрмәсен! — ди...

Алар шулай шаша торсын,
Без килик чынбарлыкка.
Кызыклы бер вакыйганы
Сөйләп бирик халыкка.

Нәкъ шул көндә, шул чакта
Безнең «Кызыл маяк»та
Колхоз җыелыш үткәрде
Бик зур уңыш бәйрәме,
Бик мул итеп хәзерләп
Аш-суны, чәй-мәйләрне...

Ә безнең колхоз быел
Бөртекләләрне генә
Өчәр кило ярым бүлде
Һәрбер хезмәт көненә.

Колхоз төзелгәнгә быел
Тулды егерме ике ел.
Аның юбилеен да
Үткәрдек шул бер көндә.

Аннан утыз бәби туган
Җәй буена авылда.
Шул көнгә туры китердек
Аларның туйларын да.

Алты егет, җиде кыз
Китә вузга укырга.
Карар бирдек аларны да
Шул көнне озатырга.

Кунаклар да күп килде
Районнан һәм үзәктән.
«Победа»дан, «Кызыл юл»дан,
Аннан «Азат хезмәт»тән.

Шул бәйрәмне үткәрдек,
Бөтен колхоз гөр килеп.
Уен-көлке, җыр-биюдән
Бар җир торды дер килеп.

Биедек шундый иттереп,
Бөтен җиренә җиткереп!

Әхмәди карт шул чакта,
Карап торып бер якта,
Әйткән иде: — Егетләр, сез
Җирне бит түгәрәк, дисез.
Аның теге ягында бит
Америка бар, дисез.

Шул Америка җирендә
Яши мистерлар, дисез.
Шулай булгач, абайлагыз,
Бик артык сикермәгез:
Җир селкетеп, мистерларны
Бик куркыта күрмәгез!..

Димәк, карт бик дөрес әйткән,
Уолл-стритны шул тетрәткән.

Ә үзегез беләсез,
Безнең халык бик таза.
Бер биергә тотынса,
Шундый иттереп баса!

Тормый, кайда нәрсә бар, дип,
Курыкмасын мистерлар, дип!

*1953*

## КОЛОНИЗАТОРЗАРЫ

*(Тукайга ияреп)*

И Ходаем, бәндәңә әүвәлдә хөрмәт бар иде,
Булмаганда булдырырга кулда кодрәт бар иде.

Кай халыкка нәрсә әйтсәм, алдана торган иде,
Каптырырга алдалап мең ау һәм элмәк бар иде.

Каршы килсә кем дә кем, яный идем бармак кына,
Андыйларга гүрдә һәм зинданда чермәк бар иде.

Бар эшемне эшли идем, башны салып изгегә,
Кап-кара эшләрне дә эшләргә мең рәт бар иде.

Баш күтәрсә кайсы ил, шундук баса торган идем,
Коммунистлар коткысы, дип, шау-шу килмәк бар иде.

Чыкты соң кайдан гына бу мөстәкыйльлек фетнәсе?
Бәндәңә коллык итүче күпме дәүләт бар иде!

Кайда китте бу гарәпләр? Кайда һинд? Кайда кытай?
Барсының да бер заман башын идермәк бар иде.

Үтте-китте ул заманнар, булмый инде кайтарып,
Кайтарырга, һай, күңелдә шундый зур дәрт бар иде!

*1961*

# КҮҢЕЛЛЕ СӘХИФӘЛӘР

*(Мәктәптән соңгы яшьтәге сакаллы сабыйлар өчен шигырьләр)*

## Елның дүрт фасылы

### Яз

Көннәр якты, аяз,
Көлеп карый кояш,
Җылысын арттыра,
Кырларга чакыра.
Бөтен җир нурланган,
Кош-кортлар уянган.
Күршеләр ашыга
Чыгарга басуга.
Тик безнең идарә
Селкенми, бичара!

### Җәй

Күкрәп һәм шаулап
Үтеп китте яз.
Көннән-көн ныграк
Кыздыра кояш.
Кояш пешерә,
Искә төшерә:
— Ашлык урырга
Җитә бит вакыт!
Ә машиналар
Түгелме ватык?
Узган елгы хәл
Чыкмасын истән!..
Тик бер җавап та
Юк Эртеэстан.

## Көз

Кырысланды һава,
Көн-төн яңгыр ява.
Каралдылар кырлар,
Баткакланды юллар.
Ята һаман кырда
Урган-суккан ашлык.
Шул ашлыкны ничек
Өлгерергә тапшып?
Бөтен район безнең
Вата шул хакта баш...
Ни файда бар ләкин
Алдан кайгыртмагач?!

## Кыш

Килеп җитте кыш.
Салкын, саф һава.
Күбәләк кебек
Матур кар ява.
Күңелле кырга
Чыгып карарга:
Бар җир күмелгән
Ап-ак карларга...
Эчне пошыра
Калкып аз гына
Җыелмый калган
Кукуруз гына!

# КИҢӘШМӘДӘН КИҢӘШМӘГӘ

(*Алдынгылар җыры*)

Озак киңәштек
Элек авылда.
Киңәшеп алдык
Аннан районда.
Берничә генә
Сәгать булса да,
Кордык киңәшмә
Куст буенча да.
Булды киңәшмә
Районара да.
Озак сөйләштек
Барыш аңа да.
Аннан өлкәгә
Алдылар дәшеп.
Озак утырдык
Анда киңәшеп.
Йөрибез шулай
Гел киңәшмәгә...
Ничек калсын соң
Вакыт эшләргә?!

# БЕЗНЕҢ ӘТӘЧ

(*Кайбер администраторларга багышлана*)

Күр син безнең әтәчне,
Күр син кызыл кәпәчне:
Иртә таңнан тора ул,
Торуга кычкыра ул:
— Кикрикүк! Кикрикүк!
Ник бер җирдә тәртип юк?
Кабарыныш, очыныш
Йөри башлый кычкырыш:
— Ул эш ник эшләнмәгән?
Бу эш ник эшләнмәгән?
Нәрсә карап ятасыз,
Җир ник тиресләнмәгән?
Салкын карыйсыз эшкә!
Күрсәтермен мин сезгә!..
Куныш койма башына,
Канат кага, ярсына,
Бармак яный ансына,
Шелтә бирә монсына,
Шпорларын шалтыратыш,
Аяк тибә кайсына.

Көн буе шулай йөреп,
Бар нәрсәне кыдырыш,
Кичкә арып бетә дә,
Кетәгенә китә дә,
Табыш бирәр кунача,
Йоклый шунда таңгача...

Шундый ул безнең әтәч,
Башында — кызыл кәпәч.

## ПЕСИ-ПЕСКӘЕМ!

— Песи-пескәем,
Мамык өскәем!
Ачыш бакмыйсың
Нигә күзкәең?
Көн дә йоклыйсың,
Төн дә йоклыйсың,
Ник төшеп берәр
Тычкан тотмыйсың?
Шактый зур инде
Синең бит яшең.
Син бит бер эш тә
Белми үсәсең!..

— Нәрсәгә миңа
Эш өйрәнергә?
Ник азапланыш
Төшеп йөрергә?
Болай да минем
Ашым — алдымда.
Табыш китерә
Әнкәм барсын да.
Шуны да әйтим:
Киләсе җәйгә
Мин Мыраужанга
Чыгам кияүгә!
Тычкан аулауда
Ул бит бригадир.
Димәк, зур эштә
Эшли торган ир.
Ә андый эштә
Эшләүче ирләр
Хатыннарыннан
Эш эшләтмиләр!..

*1957*

## КАРТ ИМӘН БЕЛӘН ЯШЬ ЕГЕТ

Үзләренең йортлары тирәсендә,
Моннан йөз еллар чамасы элек
Бабасы утырткан Имән күләгәсендә
Ята иде яшь кенә бер Егет.
Ята торгач карап агачка,
Шундый уй туды аның башында:
«Нигә кирәк булган инде картлачка
Имән утыртырга монда?
Нинди файда бар андый агачтан?
Инде утырткачтан,
Утыртырга иде алма агачы.
Булыр иде, ичмасам, алмасы,
Ягъни кешеләргә файдасы...»
Егетнең нәрсә уйлаганын белеп,
Телгә килеп,
Әйтте шунда аңа ачуланып Имән:
— Ә нинди файда бар кешеләргә синнән?
Дөрес, мин
Алма бирмим.
Ләкин мин якын-тирәгә
Бирәм күләгә.
Бабаң мине утыртты шуның өчен дә.
Ял итәсең бит менә син дә
Ул утырткан агачның күләгәсендә.
Ә инде үзеңә килсәк,
Синең бит хәтта
Утыртканың юк кечкенә куак та.
Димәк,
Калмас синнән бераүгә дә
Күләгә дә!..

*

Бу мәсәлнең морале
Бик үк яңа түгелдер, бәлкем.
Ләкин кайберәүләргә карата әле
Кабатларга кирәк аны һәр көн!

*1956*

## ФӘННИ ХЕЗМӘТ

Бар әле бездә шундый кешеләр дә:
Тормыштан
Тәмам аерылганлыктан,
Белмичә кайвакыт нәрсә эшләргә,
Тотыналар бер дә кирәкмәгән эшләргә.
Шуңа бөтен көчләрен салалар
Һәм көлкегә калалар.

*

Эшли иде бер фәнни институтта
Яшь кенә бер галим,
Ниндидер фән кандидаты
Иптәш Сәфәргалин.
Уйлады ул бер заманны
Шаккатырырга дөньяны.
Юыну урыннарында
Ни эшләргә икәнлеге турында,
Фәнгә нигезләп,
Язарга булды ул зур гына бер хезмәт.
Моның өчен
Кызганмады ул бөтен көчен:
Бу хакта
Нинди китапта
Нинди мәгълүмат тапса,
Нинди белешмә очратса,
Калдырмый берсен дә,
Укып чыкты шуларның һәммәсен дә.
Аннары бу эшен

Практика белән ныгыту өчен
Хәтта
Үзе эшли торган институтта,
Куйдырып ваннасын һәм душын,
Ясаттырды махсус лабораториясен.
Һәм шунда
Өйрәнде ул барысын да:
Ягъни юыну урынына нинди очракта керергә,
Кергәч, ничек чишенергә,
Өстеңнән иң элек нәрсәне салырга,
Тасны кайсы кул белән алырга,
Тәнне кай җиреннән башлап юарга,
Арканы ничә тапкыр уарга,
Сабынны күпме сыларга,
Суны кай җиргә, күпме коярга,
Юынып бетергәч, ничек кибенергә
Һәм ничек киенергә...
Кыскача әйткәндә,
Аныклап һәрберсенең хасиятен
Һәм әһәмиятен,
Өч ел дигәндә,
Тәмам итте бу үзенең хезмәтен.
Тәмам итте
Һәм комиссиягә илтте.
Ә комиссиядә әйттеләр аңа:
— Төгәлләнеп җитмәгән әле бу эшең.
Аны тагын да тулыландыру өчен,
Бар син, коллега, гади бер мунчага.
Кешеләрнең кара ничек юынганын,
Шуннан соң килерсең тагын...
Һәм күрде ул барып:
Аның хезмәтен укымаган булса да,
Мунчада
Нәкъ ул язганча юынып ята бөтен халык.
Шунда ул нишләгәнен аңлады
Һәм комиссиягә кабат бармады.

*1955*

## ИКЕ ЙОРТ

Кыйммәтле ташлар белән тышланган,
Алтын шпильләр белән очланган
Әллә ничә манаралы,
Меңәрләгән баганалы
Башы белән болытларга орыныш
Тора торган мәһабәт бер йорт,
Янындагы кечерәк йортны күреп,
Карап югарыдан,
Әйтте аңа беркөнне, көлеп:
«Кызганам мин сине, туган!
Ничек түзәсең син мондый хәлеңә?
Бит әле генә
Иң шәп йортларның берсе идең син шәһәрдә.
Һәрхәлдә,
Бөтен халык
Карый иде бит сиңа сокланыш.
Ә бүген?
Кая китте синең элекке шәплегең?
Караучы да юк бит хәзер сиңа!
Бетен кеше соклана миңа.
Минем янымда бит син,
Ничек кенә дип әйтим:
Бөтенләйгә чүп булып калдың,
Югалдың!
Бер залыма гына да бит син минем
Бөтен этажларың белән сыяр идең!
Шуның өстенә
Кереп карасаң иде минем эчемә,
Күреп андагы зиннәтләрне,
Бизәкләрне,
Язар идең бөтенләй акылдан:
Барысы да мәрмәрдән бит анда,
Барысы да алтыннан!
Аңлый алмыйм мин сине һаман да:
Ничек төштең син мондый хәлгә?

Нигә теләмисең минем күк үсәргә?..»
        Кечерәк йорт шунда
Болай дип җавап бирде мәһабәт йортка:
        «Минем турымда
Хәсрәтләнәсең син, туганкай, юкка!
Дөрес, синең буең да зур,
        Сының да бик матур,
        Үзең күкләргә үрелеп,
Торасың әллә кайлардан күренеп.
        Манараларың да,
        Баганаларың да,
        Зиннәтләрең дә,
        Бизәкләрең дә,
Чыннан да, һәркем таңга калырлык,
Минем күк биш йорт салырлык.
        Ләкин мин
Яшермичә генә шуны әйтим:
        Синең эчеңдә
Юк миндә торучыларның өчтән берсе дә.
        Димәк,
Булсаң да син зуррак
        Һәм матурrак,
Халыкка файда китерәсең миннән кимрәк.
        Менә шуңа,
Хәсрәтләнгәнче минем язмышыма,
Үз турында уйла син бигрәк!..»

*

Бу мәсәлдән бүген
Йортлар гына түгел,
Кешеләр дә алсын иде гыйбрәт!

*1955*

## АЮ ЯҢА УРЫНДА

Аюны күчерделәр яңа постка —
Күрше урманга, бүтән лесхозга.
Яңа түрә,
Күчеп килсә, күрә:
Лесхозда бухгалтер да юк, секретарь да,
Эш йөртүче дә,
Утын кертүче дә, —
Иске түрә белән күчеп киткән бар да.
Мәсьәлә ачык!
Озак тормый маташып,
Аю, ишекне киң итеп ачып:
— Керегез! — диде үзе белән күчеп килүчеләргә,
Ягъни бергә сыйлашкан,
Бергә сыйпашкан,
Бөтен яктан «үз кешеләр»гә.
Шунда ук тулыландырылды бөтен штат.
Барысы да риза, барысы да шат.
Нәкъ элекке урындагы төсле
Корып җибәрделәр болар эшне:
Тагын сыйлаштылар,
Тагын сыйпаштылар,
Макташтылар,
Яклаштылар,
Кыскасы, яңа урында искечә алдаштылар...

*

Нинди дисәгез бу мәсәлнең морале?
Әйтим:
Шундый күчүчеләр
Һәм шуңа түзүчеләр,
Кызганычка каршы, һаман да бар әле.

*1952*

## БАЛЫК ҺӘМ БАЛЫКЧЫЛАР

Иделдәге бер балыкның
(Ә ул шактый аңлы балык иде)
Бервакытны
Өстәлгә эләгәсе килде.
«Нигә, — диде ул, — болай мыскыллыйлар мине?
Әллә мин диңгез балыгыннан кимме?
Нигә балыкчылар мине тотмыйлар,
Йоклыйлар?
Ә бит төрләндерергә кирәк халыкның ашын,
Ягъни чат бертөрле генә ашамасын:
Ашаган кебек тавыгын да,
Сарыгын да,
Ашасын балыгын да...»
Шундый уйлар белән дулкынланып,
Яр буена таба йөзеп китте балык.
Һәм күрде ул шунда,
Яр буенда
Хәтсез балыкчыларны:
Кайсылары аларның план төзеп ята,
Кайсы приказ яза,
Инструкция яза кайсылары,
Ә кайберләре үткәрә утырыш.
Кыскасы, күренми бернинди җанлы эш.
Ә үзләрен торсаң карап,
Ашаганнары — камбала да краб.
Идел балыгын күрмиләр дә,
Аның дөньяда бар икәнен белмиләр дә.
Шулай бераз
Карап торгач,
Тотылудан өметен өзеп,
Китте мескен балык кирегә таба йөзеп.

*

Шундый балыкчылар
Әле бездә һаман да очрыйлар:
Аларга балыгың ни,
Халыгың ни!

*1952*

## ПОПУГАЙ—ЛЕКТОР

Һәрбер ишеткәнне
Төгәл кабатлый белгәне өчен
Тапшырдылар
Попугайга беркөнне
Лекторлык эшен.
Беркетеп шуннан соң үзенә
Бар урмандагы кошларны:
— Аудиторияң шушылар менә,
Агарт, — диделәр, — шуларны!
Попугай
Хәзерләнде бу эшкә нәкъ бер ай:
Кем нәрсә укый һәм сөйли,
Шуларның ул барысын да тыңлап йөри.
Аңламаса да үзе мәгънәсен,
Беркетә бара күңеленә һәммәсен.
Үтүгә бер ай,
Аннан алып,
Моннан чәлеп,
Цитаталар җыйды бу шулай
Кимендә ун лекциялек.
Бүлеп чыкты аннары
Темаларга аларны.
Һәм кошларның лекция бюросында
Раслаттырды шуларның барысын да.
Шулай
Җәеп җибәрде безнең Попугай
Кошлар арасында лекторлык эшен,
Ягъни нәрсә ишеткән
Һәм күңеленә беркеткән,
Кабатлый башлады шуларның һәммәсен.
Шундый оста сөйли,
Теле йокмый хәтта теленә,
Тыңлыйлармы да дими,
Цитаталарны бер-бер артлы сибә генә.

Копшлар лекцияләрне тыңлап карадылар,
Ләкин берни дә аңлый алмадылар.
(Коры цитаталар гына тыңлап
Нәрсә булсын, ди, аңлап!)
Ә Попугайның эше юк анда:
Сөйли бирә лекцияләрен һаман да.
Сөйли ул кай көнне икешәрне,
Ә кай көнне — хәтта бишәрне.

Ләкин бара торгач,
Бер-ике ай узгач,
Аудиториясе аның кими башлады,
Кайберәүләр йөрүне бөтенләй ташлады.

Килгәннәре дә,
Утыра торгач тыңлап,
Утырган җирләрендә
Йоклый башладылар гырлап...

*

Бу мәсәлне
Кирәк болай дип аңларга:
Андый зур эшләрне
Ташлырмагыз попугайларга!

*1954*

## КОТКАРУЧЫЛАР

Утырышларны бик яратучы икәү
Күл буеннан үтеп баралар икән,
Күргәннәр шунда,
Күлнең уртасында
Ниндидер бер баланың
Батып барганын.
Шунда ук алар,
Утырып ярга,
Киңәшә башлаганнар
Ничек ярдәм итү турында аңарга:
Ягъни
Кай җирдән башлап җибәрергә эшне?
Балага якынрак ярның кай төше?
Эзләп торыргамы көймә?
Керергәме әллә шул көйгә?
Чишенергәме?
Әллә чишенми генә керергәме?
Кергәч, балага ничек кул бирергә
Һәм кай җиреннән эләктерергә?..
Шулай алар,
Таба алмый карар,
Киңәш корып утырган арада,
Юкка чыккан бала да.
Әллә инде баткан,
Әллә чыгып чапкан!

*

Бәлки, әйтерләр кайберәүләр:
— Булмый бит тормышта андый хәлләр!
Булмаганны язасың, — диярләр, — нишләп?
Ә мин әйтәм:
Булмаса, бик шәп!

*1957*

## КҮРКӘ БЕЛӘН САНДУГАЧ

Күркә уйлады бер заман
Язарга шигырь белән бер роман.
Яза да башлады,
Бер атнада язып та ташлады.
Һәм әйтте ул шунда бер агачта
Сайрап утырган Сандугачка:
— Әй, син, эшлексез!
Утырганчы сызгырып, бер эшсез,
Укы әнә минем романны
Һәм әйт: шәп язылганмы?
Сандугач,
Бик җентекләп укыгач,
Әйтеп аңа әлеге романның
Бу хәлдә берничә дә ярамаганын,
Кушты аны өр-яңадан эшләргә,
Баштанаяк үзгәртеп төзергә.
Күркә, бик кәефсезләнеп кенә,
Кайтып китте үзенең кетәклегенә,
Ә бер айдан ул тагын килде:
— Мә! — диде, —
Хәзер укып кара инде!..
Сандугач,
Романны тагын бер кат укыгач,
Әйтеп Күркәгә романның
Бу юлы шактый ук яхшырганын,
Кушты тагын бик нык төзәтергә,
Бик күп урыннарын үзгәртергә,
Бик күп җирен кисәргә,
Ә кайбер җирләренә яңа бүлекләр өстәргә.
Өч айдан Күркә тагын килде.
Сандугач аңа тагын бик күп киңәш бирде:
Бик күп урыннарын төзәттерде,

Бик күп урыннарын үзгәрттерде,
Артыгын — кыскарттырды,
Җитмәгәнен өстәттерде,
Кыскасы,
Романны тагын бик нык эшләттерде.
Күркә белән Сандугач
Бергәләп шулай тырыша торгач,
Бер заман
Килеп чыкты ярыйсы гына бер роман.
Басылып чыкты ул хәтта
Булып китап та.
Кайберәүләр чыктылар аны мактап та.
Мондый хәлне күреп,
Йөри башлады Күркә бик нык күпереп.
Калмады аңарда һичбер төрле шик:
— Булам мин, — диде ул, — тиздән классик!
Ә Сандугач,
Беренче тапкыр укыгач,
Ярамый, дигән иде, бернигә бу романың.
Ярый әле аның сүзенә карамаганмын!
Ә бит килеп чыкты нинди роман!..

*

Андый Күркәләр
Безнең арада очрый әле һаман.

*1954*

## ИКЕ БАШАК

Ике колхозның иген басуы
Кушылган җирдә бергә
Сөйләште ике башак,
Килеп беркөн адәмнәрчә телгә:
— Әйт әле, күрше, —
Диде шунда башакларның берсе, —
Күпме генә баш ватсам да мин,
Бер нәрсәне һаман да аңламыйм:
Синең белән без
Үсәбез,
Үзең беләсең, бер үк якта,
Бер төслүк туфракта
Һәм бер үк климатик шартта.
Шуның өстенә күзен
Күреп тордым үзем —
Бертөсле иде орлыклар да безнең.
Шулай булгач, нигә мин симерәм,
Ә син ябыгасың?
Аңлатырга моны ни белән?
Сәбәбе моның нәрсәдә соң?
— Эх, — диде шунда башакларның ябыгы, —
Читен түгел сиңа аңлатуы моны:
Дөрес, без үсәбез бер үк якта,
Бер төслүк туфракта
Һәм бер үк климатик шартта.
Ләкин
Бертөсле түгел безнең җитәкчеләр,
Ягъни безнең өчен җаваплы кешеләр.
Кара син үз председателегезгә:
Нинди генә кадер күрсәтми ул сезгә!
Ниләр генә ашатмый,
Эчертми
Һәм нинди генә ашламалар кертми!
Шулай булгач, сез
Симерми ниш лисез!

Һәм син кара безнекенә:
Ул бит кайгырта гел үзен генә:
Безнең янга ул килеп тә карамый.
Аңа ни!
Ябык булса да кырдагы башак,
Ята ул өендә эчеп һәм ашап.
Күп булса, кабинетында утыра,
Алдашып, төрле сводкалар тутыра.
Кыскасы, колхозчылар сөйлиләр:
— Уңмадык без председательдән! — диләр.

*

Колхозчы иптәшләр!
Шуны әйтим сезгә мин монда:
Чыгарыгыз бу мәсәлдән нәтиҗәне
Колхоз җыелышында!

*1955*

## КУЯН—РЕДАКТОР

Бер заманны,
Ничектер, гайрәте җитеп,
Ризалык бирде дә, Куянны
Билгеләделәр
Урман газетасының редакторы итеп.
Һәркемгә билгеле, әлбәттә:
Җитезлектә Куянның юк тиңе!
Керештe ул эшкә шул ук сәгатьтә,
Сызганып җиңне.
Кыска гына вакыт эчендә
Әзерләп өлгерде ул һәммәсен дә:
Ясаттырды газетаның башын,
Бик күп итеп хәбәрләр җыйды,
— Ә баш мәкаләсен,
Анысын, үзем язам! — диде.
Ләкин шунда
Килеп чыкты көтелмәгән бер кыенлык:
Күз салып урмандагы җитешсезлекләргә,
Кирәк иде кемнедер тәнкыйтьләргә!
Мондый хәл алдында
Редакторыбыз төште тәмам коелып.
«Әгәр дә, — диде ул, — тәнкыйть итсәм Аюны.
Ничек итеп квалификацияләр ул моны?
Ул бит бик тупас нәрсә,
Башыңа китереп бер бәрсә?..
Әгәр тел тиерсәң Төлкегә,
Алдан ук беләм:
Төрле хәйлә белән
Үзеңне генә калдырачак көлкегә!
Ә инде Бүре турында?..
У-у-у!
Уйларга да ярамый бу урында!
Нәрсә генә соң эшләргә?..»
Тотынды мескен шунда дерелдәргә.
Шуннан

Башына ниндидер фикер килеп,
Шатлыгыннан
Җибәрде ул хәтта биеп.
— Таптым! — диде ул, —
Арттырганчы дөньяда дошманны,
Иң яхшысы шул —
Тотам да тәнкыйть итәм Сукыр Тычканны.
Ул бит сукыр!
Неужели минем газетамны укыр?..

*

Шундый бер газетаны укып мин кичә,
Ясадым
Куяндыр моның редакторы дигән нәтиҗә.

*1955*

## МӨХӘММӘТ ҺӘМ ТАУ

Бөтен төше
Төзү чималлары белән тулган,
Ләкин район үзәгеннән ерак торган
Зур гына Тауларның берсе,
Мөхәммәтнең килүен бик озак көткәч,
Көтә-көтә тәмам арып беткәч,
Аның янына
Карар бирде беркөнне үзе барырга.
«Каршысына Тау хәтле Тау баргач,
Һичшиксез, игътибар итми калмас,
Бөтен байлыгымны казытып алыр
Һәм производствога файдаланыр!»
Шулай уйлап ул эченнән генә,
Килеп җитте район үзәгенә.
Ләкин Мөхәммәтнең секретаре
Җибәрмәде аны бусагадан ары:
«Кертә алмыйм, — диде ул аңарга. —
Бүген аның
Үзенә кирәкле төзү чималларын
Үзәктән җибәртүен сорап,
Елап-елап,
Ялвара торган көне Аллага».
Рөхсәт итмәде хәтта көтәргә:
«Андый көнне
Кабул итми ул, — диде, — беркемне.
Килегез сез, — диде, — иртәгә!..»
Һәм Тауга,
Буйсынып секретарьга,
Туры килде акрын гына кайтып китәргә.

*

Мондый Мөхәммәтләрне
Безнең заманда да хәтта
Очратырга мөмкин әле
Кайбер промкомбинатта.

*1956*

## ЯЛАГАЙ БЕЛӘН БЮРОКРАТ

Чыкмасмы, диц, берәр файдалы эш,
        Пешереп бик зур бәлеш,
        Чакырып үзенә кунакка,
Язу җибәрде Ялагай бер Бюрократка.
        Ә Бюрократ,
Күз дә салмыйча аның хатына,
Берәр гаризадыр дип уйлап,
Тыгып куйды сукно астына.
Ялагай аны бик озак көтте.
        Бер көн дә үтте,
        Ике көн дә үтте,
Ул арада бәлеш тә катып бетте...

*

        Бу мәсәлдән моральне
        Эзләп тә торма хәтта:
Нинди мораль булсын ди тагы
        Ялагай белән Бюрократта?

*1954*

## БЮРОКРАТ ҺӘМ ХАТ

Яшь кенә, ләкин бик өметле бюрократ
Алды бер кыздан кыска гына бер хат.
Кыз язган үзенең хатында
Аңа гашыйк булуы хакында.
«Телим, — дигән, — сезнең белән танышырга,
Ләкин белмим ничек очрашырга».
Бюрократ, укыгач кызның хатын,
Китереп бюрократлыкның бөтен шартын,
Гашыйк чибәргә
Алты битле анкета җибәрә:
Ягъни ничәнче елда ул туган,
Кайда укыган,
Укый-яза белә нинди телләрдә,
Булмаганмы чит илләрдә,
Катнашканмы гражданнар сугышында.
Катнашкан булса, ничәнче елда,
Бармы ул кызның ата-аналары
Һәм... балалары?
Аннары,
Өстәп ул шушы анкетага,
Җибәрә уналты битле инструкция аңа:
Нинди урында,
Ничек очрашырга
Һәм ничек танышырга икәнлеге турында.
Шуннан соң, хатны аерым папкага беркетеп,
Йөри башлый ул кыздан җавап көтеп.
Ләкин туры килми көтәргә бик күп:
Җавап килеп төшә икенче көнне үк;
Җавапны укыгач бер заман,
Бюрократның күзләре була шакмак —
Анда бер генә сүз язылган:
«Ах-мак!»

*1953*

## ЭШЛЕКЛЕ ӘТӘЧ

Бик эшлекләнеп,
Йөргәндә тиреслектә чүпләнеп,
Шундый уй төште Әтәчкә беркөн:
«Дөньяда, — диде ул, —
Минем кадәр эшлекле кем?
Кем бар миннән дә иртә торучы,
Кычкыручы,
Барлык җан иясен уятучы,
Тавык-чебешләргә азык табучы?
Ә тавыклар —
Ялкау һәм булдыксыз алар:
Ашый торып та гел әзерне,
Күкәйне дә салалар көнгә тик берне.
Чебешләрне дә бит алар
Унарлап кына чыгаралар.
Ышаныш булмый аларга бер эшне дә.
Бүгеннән
Үзем чыгара башлыйм чебешне дә,
Башка эшләрне дә үз өстемә алам,
Күкәйне дә үзем салам!..»
Шуннан соң ул
Тавыклар салган йөзләп күкәйне җыеп,
Менеп утырды, барысын бергә өеп.
Хәзер бөтен эш Әтәчнең үз өстендә:
Бер эшкә якын китерми беркемне дә,
Иртүк тора,
Кычкыра,
Тиреслекне казып,
Тавык-чебешләргә эзли азык.
Ул арада шалт-шолт атлап,
Шпорлы аяклары белән таптап,
Күкәйләр өстенә дә менеп ята,
Кайсын сыта,
Кайсын вата,

Үзе һаман кычкыра:
— Кикрикүк тә кикрикүк!
Янәсе, минем эшем күп,
Эшләгез сез дә нәкъ минем күк!..
Тавыклар янына барырга вакыты да юк.
Ә үзенең,
Үтүгә карамастан җәй дә,
Салганы юк бер генә күкәй дә,
Исән калган күкәйләр дә бетте бозылып,
Чебешләрнең дә эзе юк!

*

Андый әтәчләрне
Илтер идем мин базарга
Яки салыр идем казанга.

*1953*

## АЮ БЕЛӘН ЧЫПЧЫК

Октябрьдә кереп яткан җиреннән
Аю тик май җиткәч чыкты өненнән.
Йөри иде шул тирәдә очып
Таныш Чыпчык.
Аюның ул чыкканлыгын күреп,
Әйтте аңа көлеп:
        — Ай-һай!
Бүсәсең дә икән син йокыны, агай!
Ятып шулай үз өнеңдә,
Сизмәдең син кышның үтүен дә.
Син бит аның
Күрми калдың
Михнәтен дә
Һәм шулай ук рәхәтен дә.
Шул булдымы инде, дускай, тормыш?..
— Ә соң нинди була ул кыш? —
Диде Аю, исе китми генә.
Ләкин Чыпчык, кыш турында
Сөйләсә дә аңа күпме генә,
Бирә алмады аңлатып.
        Һәм Аю да
Сорашып тормады артык.

*

Кешеләрнең дә шундый кайберләре:
        Аю кебек,
        Өннәренә кереп,
Йоклап үтә ярты гомерләре.

*1958*

## КИСКӘ БЕЛӘН ЧӨЙ

Юан гына бер нарат Кискәсе,
Күреп янындагы имән Чөйне,
Чын күңелдән кайгырып, янәсе,
Әйтте аңа: «Кызганам мин сине.
Шундый бәләкәй син минем янда!
          Кайсы дурак
Ташлагандыр сине шулай турап.
Кешеләргә синнән нинди файда?
Яшермичә генә әйткән чакта,
Чыкмый синнән хәтта чыралык та.
          Мин, ичмасам,
          Мичтә янсам,
Никадәрле җылы бирәм!
Ә кешеләр нишләр синең белән?..»
Җавап биргән кебек бу сорауга,
          Килде дә бер утынчы урманга,
          Шул Кискәнең ярыгына
Кыстырды да Чөйне җайлап кына,
Суккалаган иде берничә кат,
Ярылды да китте Кискә шартлап.
          Мескен Кискә
Килә алмый калды хәтта искә.
Ә утынчы, бер тотынган көйгә
Шундый бик күп кискәләрне ярып,
          Китеп барды бүтән җиргә,
Теге Чөйне үзе белән алып.

*

Уйласагыз, укучылар, ныклап,
Бу әкияттән мондый мәгънә чыгар:
Арабызда куя әле очрап,
Охшап теге нарат Кискәсенә,
Бу дөньяда бары бер мин генә
Эш кырам, дип уйлаучылар.

*1958*

## ЧУАРКАЙ

Көннәрнең берендә
Рекорд куйсын өчен дөнья күләмендә,
Фермадагы тавыкларның берсен,
Иң эресен
Һәм шәп нәселлесен,
Башка тавыклардан аерып алып,
Үзенә бер иркен кетәк салып,
Ябып куйдылар да берьялгызын шунда,
Күчерделәр махсус рационга.
Ә рацион дигәненә
Кертелмәде ниләр генә!

Калмады яшелчәсе дә, бодае да,
Ите дә һәм хәтта ак мае да.
Ә суны эчерделәр чиншмәдән генә,
Көншәләр үткәреп кетәгенә.
Куйдылар аннан ике карауччы,
Бер күкәй санаучы.
Һәм чынлап та
Үтмәде озак та,
Шундый тырышлык нәтиҗәсендә
Күкәй сала башлады Чуаркай көн дә.
Ә кай көнне оясында
Табалар иде ике сарылысын да.
Күргәч моны,
Кәефе бик килеп,
— Менә, ичмасам, бу рекорд! — диеп,
Тагы да көчәйтте мөдир рационны.
— Кызганмагыз, — диде өстәп, — әйдә,
Бирегез үзенә көн дә бер күкәй дә!
Янәсе, түл җыю өчен
Юкка әрәм итмәсен үзенең көчен!
Ләкин бик дәртләнеп,

Инде күргәзмә турында өметләнеп
Йөргән чакта мөдиребез шулай,
Көннәрдән бер көнне,
Гаҗәпләндереп һәркемне,
Күкәй салудан туктады Чуаркай.
Ул артык симереп киткән иде
Һәм күкәй сала алмас хәлгә җиткән иде.

*

Кайвакытны без дә
Кайберәүләрне нәкъ шулай менә
Артык иркәләп җибәрәбез дә
Калдырабыз Чуаркай хәленә.

*1958*

## МӘЧЕ ҺӘМ РӘСЕМ

Художникның йокы бүлмәсендә
Тәрбияләнеп үскән Мәче,
Ниндидер кошны күреп бер рәсемдә,
Булды аны тәнкыйть итмәкче.
Рәсем
Аңа ошамады, күрәсең:
— М-да! —
Диде ул, бераз уйлап торгач. —
Бу турыда
Хуҗаның үзенә әйтмичә булмас.
Ә ул үзе бит
Талантлы гына художник.
Күр, нинди җанлы итеп ясаган!
Ләкин кай җире моның әтәчкә охшаган?
Минем бит тәрәзәдән күргәнем бар:
Әтәчләр алар
Чын тормышта
Бөтенләй якын да килмиләр бу кошка.
Булмасалар да бу чаклы зур,
Булалар бик матур:
Кикрикләре була тарак шикелле,
Койрыклары була урак шикелле.
Ә моның әтәче?!
(Ризасызлыктан ярсыды хәтта Мәче.)
Менә бит ул тормышны белмәү нәтиҗәсе!
Җитмәсә, куйган әле шуны иң түргә!..
Ә дөресендә
Ясалган иде рәсемдә
Әтәч түгел... Күркә.

*

Тормышны үзе белмәүче
Шундый Мәче
Була бездә кайвакыт рецензияче.

*1955*

## ШТУРМЧЫ ӘТӘЧ

Беркем дә килеп әйтмәгәч,
Йөдәтмәгәч,
Бик озак кузгалмыйча ятты Әтәч.
Тормады да,
Кычкырмады да,
«Өлгерермен әле барысына да!» — диде,
Чөнки әле айның башы гына иде.
Ә беркөнне торып караса,
Ни күзе белән күрсен:
Айның азагы җитеп килә ләбаса!
Шунда ул, уа-уа күзен,
Тиз генә коймага очып кунды
Һәм берьюлы бөтен ай өчен
Сузып-сузып кычкырырга тотынды.
Ләкин күпкә җитмәде мескеннең гайрәте,
Көн ахырына бөтенләй бетте рәте:
Никадәр тырышып ачса да авызын,
Чыгара алмый башлады тавышын.
«Кикрикүк!» дияргә тырыша да бик,
Бары тик
Чыга башлады: «Кик...»
Кычкыра торгач кагынып-кагынып,
Беткән иде чөнки тамагы карлыгып...

*

Моны яздым мин шуның өчен генә:
Син дә, иптәш,
Соңгы декада килеп җиткәч,
Кала күрмә шул Әтәч хәленә!

*1956*

# ТӨЛКЕ ҺӘМ ВИНОГРАД

*(Крылов буенча диярлек)*

Теләп беркөнне виноград ашарга,
Төлке-кодача барды базарга.
Ә анда
Барлык ларекларда
Виноградлар өелеп торалар:
Шундый пешкәннәр,
Шундый житешкәннәр,
Просто күзләрне яндыралар!
Кодачаның килде хәтта авыз сулары.
Ләкин шунысы бәла — бәясе бик югары:
Утыз сум, диләр, килосы!
Төлкенең килсә дә сатып аласы,
Бик озак торгач башын ватып,
Алмыйча гына китте кире кайтып.
Киткәндә, әйтте ул, кесәсен капшап:
— Әле пешмәгәннәр,
Җитешмәгәннәр,
Эчең бозылуы бар мондыйларны ашап...

*

Бу очракта мин
Төлкене һич тә гаепләмим,
Гаепле түгел шулай ук кыйбат сатучылар.
Гаепле монда бары
Сәүдә оешмалары,
Ягъни авыз ачып тик ятучылар!

*1955*

## МАЙМЫЛ ҺӘМ РАКЕТА

Маймылның башына беркөнне
Шундый уй керде:
«Кешедән, — диде ул, — минем кай төшем ким?
Дөресен әйткәндә, үзләре бит алар
Бездән яралганнар.
Димәк, алардан өстенрәк тә әле мин!
Шулай булгач,
Ракета җибәрәм мин дә галәмгә!..»
Һәм вакытын уздырмый әрәмгә,
Нәкъ кешеләрчә иттереп,
Бөтен фасонын китереп,
Уйлап йолдызларга юл ачарга,
Керешге өч буынлы ракета ясарга.
Менә бер заман
Ракетасы моның булды тәмам.
Шунда ул өч буынны бергә җыеп,
Чыгарып утыртты да старт мәйданына,
Аларга «Көнбатыш» дигән исем куеп,
Кардәш-ыруларын җыйды үз янына.
Һәм әйтте аларга карап:
— Безнең бу тарихи кораб
Әйләнеп кайтырга тиешле бирегә,
Ягъни күтәрелеп киткән җиренә,
Айны кимендә җитмеш тапкыр урап!..
Шуннан соң ул бик нык дәртләнеп,
Утырды да ракетасына атланып,
Эре генә тотып башын,
Басты бер кнопкасын.
Кинәт шунда нәрсәдер сызгырды,
Нәрсәдер ыжгырды,
Дерелдәде,
Дөбердәде,
Нәрсәдер бик каты шартлады
Һәм бөтен җирне куе төтен каплады.
Ә төтен беткәч таралып,

Ырудашлары карасалар барыш,
Мескеннәр,
Ни күрсеннәр!
Ракетасы тегенең өчкә таралыш,
Ята, пыскып кына янып,
Шунда старт мәйданында ук.
Ә маймылның әсәре дә юк.
Әллә инде бөтенләй янып беткән,
Әллә ракета урнына үзе очып киткән.

*1961*

## АРЫСЛАН МАСКАРАДТА

Арыслан,
Туеп беркөнне ялагайлардан,
Ял итим булмаса үзләреннән, диеп,
Яңа ел маскарадына барган,
Болан битлеге киеп.
Ләкин ул мәһабәтлеген саклап,
Эре генә атлап,
Килеп керүгә
Һәм үкерүгә,
Тегеләр аны шундук танып алып,
Керешкәннәр тирәсендә бөтерелергә,
Төрлечә ялагайланып.
Арысланның моңа кәефе кырылып,
Чыгып киткән тиз генә борылып.

*

Мин аңарга бары шундый киңәш бирәм:
Котылыйм дисәң ялагайлардан,
Иң алдан
Үзеңне тотарга өйрән!

*1962*

## ҮЛӘН АШАУЧЫ БҮРЕЛӘР

Ничектер, үзләре башлапмы,
Яки үлән ашаучылар йогынты ясапмы,
Йә булмаса, аңлапмы үз гаепләрен,
Сүзен тыңлапмы ваграк җәнлекләрнең,
Кыскасы, сәбәп беләнме,
Сәнәк беләнме,
Беркөнне Бүреләр ит ашауны ташлаганнар
Һәм үлән белән туена башлаганнар.
Бу хактагы хәбәр, әлбәттә,
Таралган дөньяга шул ук сәгатьтә.
Көндәлек матбугатта
Басылган бу хакта
Бүреләрнең хатлары да хәтта.
Ә телевизор экраннарында
Күрсәткәннәр ул Бүреләрнең
Ничек итеп болында
Тыныч кына утлап йөрүләрен.
Ишетмәгәннәр бу турыда
Бары тик кайсыдыр бер районда.
Һәм, белмәгәнлектән мондый хәлне,
Кайбер артель идарәләрендә
Бишәр сарыкка акт төзиләр ди көн дә
Һаман да әле
Гаепләп Бүреләрне.

*1963*

## БЫЛАГАЙ КУЯН

Очраттылар урманда бер Куянны.
Курыкмыйча берсеннән дә,
Тырнагыннан да берсенең, тешеннән дә,
Ду китереп йөри бөтен урманны.
Әле барып керә Бүре оясына,
Әле менеп утыра Аюның иңбашына.
Тартып үтә йә Төлкенең койрыгын,
Йә Юлбарысның мыегын;
Анысына сугыла,
Монысына кагыла,
Тегесенә бәйләнә,
Кыскасы, теләгәнчә былагайлана.
Тик ни генә эшләсә дә,
Берсе дә әйтми моңа бернәрсә дә.
«Ай-һай, безнең бу Куян
Бигрәк тә шаян!»
Дип калалар арттан карап кына,
Иреннәрен ялап кына.
Күршеләре исә калалар таңга,
«Ник сүз әйтмиләр, — дип, — бу Куянга?»
Ә әйтмәүләренең сәбәбе шул:
Гади куян түгел ул!
Аның апасының ире —
Арысланның иң җитез курьеры!

*1961*

## ТИЛГӘН БЕЛӘН ЧЕБЕШ

Зур гына бер Тилгән
(Булган аның табышсыз кайтыш килеше.)
Беркөнне тырнагына эләктергән
Бәләкәй генә бер Чебешне.
Ә Чебеш, тормыйча бер дә каушап,
Бик җитди итеп аңарга әйткән:
«Ни файда сиңа, абзыкай, мине ашап?
Мин бит әле, күрәсең, бик кечкенә,
Ә ояда менә
Бар минем әткәм белән әнкәм.
Алар инде түгел минем хәтле генә!
Чыгарыйм, булмаса, шуларны синең янга.
Юкса аларны барыбер суячаклар
Һәм табынга куячаклар...»
Бик ачыккан булганга,
Риза булыш шундук моңарга,
Әлеге Тилгән,
Ычкындырыш Чебешне тырнагыннан,
Оясына җибәргән.
Чебеш тиз генә ояга кереп,
Борнын гына тыгыш бер ярыгыннан,
Әйткән тегеңәргә, көлеп:
«Эх, син, беркатлы!
Ярыймыни артта калырга шулчаклы?
Белмисеңмени яшәвеңне нинди чорда?
Бу ояда минем
Каян булсын ди әтием, әнием?
Безне чыгаралар бит хәзер инкубаторда!..»

*1962*

# БӘЛӘКӘЙ МӘСӘЛЛӘР

## Ишәк белән Тинтәк

Бер Ишәк,
Көне-төне күшәп,
Булырга уйлаган зур Фил тикле.
Нәкъ шулай ук менә,
Укытсаң да күпме генә,
Акыллы итеп булмый Тинтәкне.

## Куян белән Арыслан

Куян,
Каушап куркуыннан,
Куйган Арысланга ялгышып мат.
Һәм иткән ант
Шахмат уйнамаска икенче кат.

## Геометрик көнләү

Туры сызык
Түгәрәк сызыктан көнли:
Яшерә, имеш, ул очын шулкадәр нык, —
Кая яшергәнен һичкем белми!

## Мактанчык Төп

— Яшим мин, — дигән, ди, бер Төп
Икенче бер Төпкә, —
Беләмсең нәрсәгә?
Тамырларым күпкә!..
Ә карасаң төптән,
Череп беткән, ди, күптән.

## Паникачы Яфрак

Ышаныш киләсе елга
Давыл булачак дигән хәбәргә,
Тотынган Усак Яфрагы
Быел ук дерелдәргә.

## Беркатлы Әтәч

Бер Әтәч уйлаган,
Карап таңга,
Ата, дип, көн дә таң
Мин кычкырганга!

## Ялагай Керпе

Борчымасын өчен түрәләрен,
Керпе, парикмахерга кереп,
Тәнендәге барлык инәләрен
Чыккан бөдрәләттереп.

## Гайрәтле Тычкан

— Килеп кенә кара минем янга! —
Дип кычкырган Тычкан Песигә
Һәм күрсәткән йодрыкларын аңа,
Идән астында яткан көйгә.

Син дә, туган,
Шуның сыман
Гайрәтләнмә кайтып яткач өйгә!

## ЭЧТӘЛЕК

### Кычытмаган башка — тимер тарак

Кычытмаган башка — тимер тарак . . . 5
Әлфе нәһар вә нәһар, ягъни мең дә бер көндез Яхуд Шәһәрзадә Мөхәммәтҗанова белән «Сөремсиндикат»ны тазарту комиссиясе хикәясе . . . 13
Сынатты . . . 21
Мин әнине сайлыйм! . . . 24
Шулпалы бәлеш Магнитстрое . . . 26
Һаман шул бер ярлыга! . . . 32
Хәзрәт агитациясе . . . 35
Делегат . . . 37
«Чаян» телевизоры . . . 40
Кискен чара . . . 43
Сәер вакыйга . . . 48
Балыкчы газабы . . . 54
Хуҗа Насретдин һәм әдәбият . . . 62
«Гөлстан»нан . . . 65

### Көзгегә үпкәләмә

Килеп җитәр хисап бирер чагың... . . . 68
Куян һәм Председатель . . . 69
Ни ултара, ни пултара . . . 72
Гайфи агай һәм кибернетика . . . 75
Динсез дүртьюллыклар . . . 78
Мин җәннәтне күрдем . . . 80

Ахыр заман . . . 82
Карт скульпторга . . . 84
Гыйбрәтле дүртьюллыклар . . . 85
Мин курыкмыйм шелтәдән . . . 86
Минем дустым — зур галим . . . 88
Җиңгинең чире . . . 89
Беркатлылык корбаннары . . . 91
Фил, Бүре һәм Ташбака . . . 92
Тугры дус . . . 94
Җиде егет . . . 95
Өч егет . . . 96
Сабир . . . 98
Кичке җиләс җил исә... . . . 100
Кала егетләре . . . 100
Миләш . . . 101
Ике яра . . . 102
Көзге . . . 102
Шаян сонетлар . . . 103
Атом гасыры лирикасы . . . 104
Алка турында баллада . . . 105
Октябрь әлифбасы . . . 106
Кем нәрсә уйлый? . . . 108
Конфликт . . . 109
Минем иркәм . . . 110
Нишлим икән? . . . 111
Уолл-стритта тетрәү . . . 112
Колонизатор зары . . . 116
Күңелле сәхифәләр . . . 117
Киңәшмәдән киңәшмәгә . . . 119
Безнең әтәч . . . 120
Песи-пескәем! . . . 121

**Мәсәлләр**

Карт Имән белән яшь Егет . . . 122
Фәнни хезмәт . . . 123

Ике йорт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Аю яңа урында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Балык һәм балыкчылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
Попугай — лектор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Коткаручылар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Күркә белән Сандугач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Ике башак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Куян — редактор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Мөхәммәт һәм Тау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Ялагай белән Бюрократ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Бюрократ һәм хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Эшлекле Әтәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Аю белән Чыпчык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Кискә белән Чөй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Чуаркай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Мәче һәм рәсем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Штурмчы Әтәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Төлке һәм виноград . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149
Маймыл һәм ракета . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Арыслан маскарадта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Үлән ашаучы Бүреләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Былагай Куян . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Тилгән белән Чебеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Бәләкәй мәсәлләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

Литературно-художественное издание

*Ахмет Исхак*
(*Исхаков Ахмет Абдуллович*)

***Веселые страницы***

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *И.И.Нәфиев*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Г.Х.Сундукова, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.04.2005. Форматы 70×108 $^1/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 7,0 + форз. 0,18. Шартлы буяу-оттиск 8,05.
Нәшер-хисап табагы 6,8 + форз. 0,29. Тиражы 2000. Заказ А-215.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.